# ШУРА

№ 29

2020

2020 — ТУГАН ТЕЛ ЕЛЫ

2000999959318

ДИНИ АЛЬМАНАХ
1908 елдан бирле нәшер ителә

ЭЧТӘЛЕК

Җомга хотбәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5

ВӘГАЗЬЛӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11

Мөселман хатын-кызы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12

Зөлхиҗҗә ае – хаҗ ае . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20

Гарәфә көне өстенлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26

Корбан гаете хотбәләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30

Корбан гаете вәгазе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41

Корбан чалу көннәре – мәрхәмәтлелеккә юл . . . . . . . . . 49

Гаилә әһелләренә гыйлем бирү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55

Мөхәррам ае фазыйләтләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59

Тел – Аллаһының нигъмәте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65

Гашурә көне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71

Бүгенге көн «сәләфләре» – кемнәр алар? . . . . . . . . . . . 76

Туган илне яратып яшәүнең мөһимлеге . . . . . . . . . . . . 80

Яшьләр мохитендә экстремизм . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83

Зыян китермә, сиңа да зыян булмас . . . . . . . . . . . . . . . 89

Гаилә таркалуның балаларга йогынтысы . . . . . . . . . . . 95

ФӘТВАЛАР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 100

Ахшам намазының ике рәкәгать сөннәте әүвәбин намазы саналамы? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 101

Намаздагы сүрәләрнең озынлыгы хакында . . . . . . . . . 102

Тәсбих: фарыз яки сөннәт намаздан соңмы? . . . . . . . . 104

ҮРНӘК ЗАТЛАР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108

Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһе . . . . . . . . . . 109

«НӘРСӘ? КАЙДА? КАЙЧАН?» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117

ТАРИХ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122

Ни өчен Казахстанда татарлар күп яши? . . . . . . . . . . 123

«Япониядә Исламия Мәктәбе»: японлыларның мөселман-татарларына мөнәсәбәте . . . . . . . . . . . . . . 126

МИРАС . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131
Ислам безнең тарихыбызда һәм мәдәниятыбызда . . . . . . . . . . . 132

И, ТУГАН ТЕЛ! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
Телебез – милләтебез язмышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150

ТӘФСИР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Муса галәйһиссәлам кыйссасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155

ХАҖ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 181
Хаҗ кылуга кагылышлы мәсьәләләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 182

КОРБАН ЧАЛУ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 195
Корбан чалуның мәгънәсе һәм тарихы . . . . . . . . . . . . . . . . . 196

НӘСЫЙХӘТ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 204
Олы гөнаһлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 205

**«ШУРА» дини альманах, №29**

*июль – сентябрь 2020*
*зөлкагъдә 1441 –сафәр 1442*

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420021 Казан, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бәясе ирекле
2013 елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
**12+**

**БАШ РЕДАКТОР:**
Камил Искәндәр улы Сәмигуллин
Телефон: +7 (843) 237-94-53 (кабул итү бүлмәсе)

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Булат Мөбарәков
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**ДИЗАЙНЕРЛАР:**
Рөстәм Даутов
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Раушан Сәйфетдияров

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Гүзәл Гыйззәтуллина

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: shura@huzur.ru
Сайт: www. huzur.ru

*Типографиянең адресы:*
*«ОТ Принт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420030, Казан шәһ., Жуковка ур., 2.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 08.07.2020
Чыгу көне: 22.07.2020

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание на татарском языке

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللّٰهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللّٰهِ۞ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللّٰهُ۞ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللّٰهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ۞ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللّٰهِ۞ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ۞ دَاعِينَا إِلَى اللّٰهِ۞ صَلَّى اللّٰهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ۞ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ۞ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ۞ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ۞ رِضْوَانُ اللّٰهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللّٰهِ! ۞ اِتَّقُوا اللّٰهَ وَ أَطِيعُوهُ۞ إِنَّ اللّٰهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ۞

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللّٰهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ:

۞_______________________________

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ۞ كَلَامُ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللهُ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ۞ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللهِ الْإِسلَامُ۞

Соңыннан кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:

اَلْحَمدُ لِلّه حَمْدَ الْكَامِلِيَن وَالصَّلَوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِيَن وَ الْآخِرِينَ۞ مُحَمَّدٍ وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ۞ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:

إِنَّ اللهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً۞

اَللّٰهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞ اَللّٰهُمَّ بارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا بَارَكْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞

اَللّٰهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ۞ سَيِّدِنَا أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُمْ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللّٰهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللّٰهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللّٰهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ[1] ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاةِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وهَوَائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:

إِنَّ اللهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ

1 Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ۞ وَلَذِكْرُ اللهِ أَكْبَرُ وَاللهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ۞

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләҙии һәдәәнә лиһәәҙәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләә ән һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләҙии каалә фии китәәбиһил- кәриими әстәгыйҙү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә ән йәшәә-әллаһ». Нәшһәду ән ләә иләәһә илләллаһу. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин гаҙәбилләһи. Вә нәшһәду әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдиййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мү’миниинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъде: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһу. Иннәллаһә мәгал-ләҙиинәт-тәкау, вәл-ләҙиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыыйҙү билләһи: ______________________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ______________________________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгеләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмуллаһил мәликил газиизил галләәми, кәмәә каалəллаһу тәбәәракә вә тәгаалә филкәләәми. Вә иҙәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әңсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйҙү билләһи: «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил Исләәм».

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак, киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәлләҙиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибраһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ӟәвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галиййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәййидинәл Хәсәни вә сәййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин[1]. Вәхӟүл мән хәӟәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфириинә вәл мукыыймиинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгуузӱ» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

«Иннәллаһә йә’мүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ӟил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәӟәккәруун. Вәләӟикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

---

1 Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

# Вәгазьләр

*10 июль вәгазе,*

*Зөлкагъдә аеның 19 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Мөселман хатын-кызы

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн.

Җир йөзендә күп тереклек бар. Күзгә күренә торганыннан алып күзгә күренми торганына кадәр – Аллаһы Тәгалә һәрбарчасын хикмәт белән дөньяга китергән. Шул тереклек арасында Аллаһы Тәгаләгә буйсынучылар бар, буйсынмаучылар бар. Буйсынмаучылар арасында җеннәр һәм адәм балалары аерылып тора. Аллаһы Тәгалә кешеләрне ир һәм хатын итеп яраткан, алар бер-берсенә пар булып торалар.

وَاللَّهُ جَعَلَ لَكُم مِّنْ أَنفُسِكُمْ أَزْوَاجًا وَجَعَلَ لَكُم مِّنْ أَزْوَاجِكُم بَنِينَ وَحَفَدَةً وَرَزَقَكُم مِّنَ الطَّيِّبَاتِ ۚ أَفَبِالْبَاطِلِ يُؤْمِنُونَ وَبِنِعْمَتِ اللَّهِ هُمْ يَكْفُرُونَ ﴿٧٢﴾

**«Аллаһы сезнең үзегездән сезгә хатыннар бар итте, ул хатыннарыгыздан исә сезнең өчен балалар һәм оныклар яратты һәм сезне ризыкландырды. Әллә алар [һаман да потлардан файда өмет итү кебек] ялганга ышаналар, Аллаһының исә [моның кадәр] нигъмәтен [күрә торып] инкяр итәләрме?»**

«Нәхел / Умарта кортлары», 16:72

Чыннан да, Аллаһы Тәгалә башта ир кешене – Адәмне балчыктан бар кылды. Аллаһы Тәгалә кешеләрне балчыктан күпме тели шуның кадәр ясый алыр иде, ләкин Ул Адәмнең парын аның кабыргасыннан бар итте.

Әгәр хатын-кыз ир кешенең кабыргасыннан ясалмаган булса, ирләр хатын-кызларны шуның кадәр ярата алыр идеме, ә хатын-кыз ирне ир итәр идеме?

Шулай ук Аллаһы Тәгалә кешеләрнең балаларын да балчыктан булдырмады, аларның үзләреннән чыгарды. Кан, сөт белән балаларны ата-аналарына бәйләп куйды. Әгәр алай булмаса, әле туган балаларыбызны шул кадәр яратыр идекме? Һәр нәрсәдә Аллаһының хикмәте бар.

Ир – ир булып, хатын – хатын, бала бала булып калсын өчен, фитрабызны саклар өчен, Аллаһы Тәгалә динне бирде. Шушы тәрбия вакытында иң мөһим рольне уйнаучы зат – ул, мөгаен, хатын-кыздыр. Хатын-кыз гаиләнең үзәге, бәлки, нигезе булып торадыр, чөнки ул – өйдәге тынычлыкны, чисталыкны булдыручы. Аның кулы аркылы өйдәге ризыклар үтә. Ул бала таба, аларны тәрбияли, бала аның аркылы дөньяны танып белә. Ир кешенең кәефе, пөхтәлеге, дәрәҗәсе хатын хезмәте белән булдырыла. Шулай итеп, хатын-кыз гаилә тормышында, ә димәк, җәмгыятьтә дә зур роль уйный, чөнки җәмгыять – ул гаилә, гаиләдән шул җәмгыятькә балалар чыга: алар нинди тәрбия алсалар, җәмгыять тә шундый булачак. Әгәр хатын-кыз үзенең шушы вазифаларын онытса яки үтәмәсә, нәрсә буласын күз алдына китерергә дә авыр, чөнки тормыш тәртибе югалачак. Хәер, күз алдына китерү авыр түгел: тирә-якка карау да җитә. Бүген без гаилә нигезләренең җимерелгәнлеген, туганлык җепләре өзелгәнлеген, ир белән хатынның урыннары алышынганын күрәбез. Монда күп нәрсәдән гаеп табарга, төрле катлам кешеләрен гаепләргә булыр иде, тик без бу проблеманың асылына карыйк әле. Шушы тормыш арбасында хатын-кызның урыны нинди икән?

Хатын-кызларга карата күп аятьләр һәм хәдисләр бар. Гәрчә Исламда хатын-кыз изелгән, чикләнгән дигән сүзләр ишетсәк тә, Ислам дине хатын-кызны бик югары бәяли. Хатын-кызга дәрәҗә биргән беренче дин – ул Ислам дине. Урта гасырларда Аурупада «хатын-кыз – кеше түгел»

дигән фикерләр йөри. Аларны фәрештә димиләр, хайван, шәйтан диләр. Ә Ислам дөньясында мондый уйны башка да китереп булмый, чөнки аять-хәдисләрдә хатын-кыз ир кеше белән бер яссылыкта карала. Ул гыйлем ала, малга ия була, сүзен әйтә ала, яклауга һәм тәэмин ителүгә лаеклы. Дөресен генә әйткәндә, бу хакларга бүгенге көндә дә хатын-кыз ирешә алмый.

Ислам дине таралу белән, динне тоткан хатын-кызлар да күбәя. Урамда, бүген кая гына барсаң да, яулык бәйләгән хатын-кызларны күрергә була, шөкер. Берәр җирлектә Ислам диненең таралганлыгын мәчетләрдән һәм яулыклы хатыннардан күрергә була. Яулык бәйләгән хатын-кыз зур корбан кылучы ул, чөнки безнең җирлектә яулык бәйләү – башкалардан аерылу булып тора. Ә бит беркемнең дә аерыласы килми. Шуның өстенә хатын-кызның үз матурлыгын да күрсәтәсе киләдер. Мөслимә хатын боларның барысын корбан итә. Ирләр җиңел генә хатын-кыз яулык бәйләргә тиеш, дип кычкыра, ә үзләре көндәлек тормышта түбәтәй дә киеп йөри алмыйлар. Мәчеткә кергәндә, кесәләреннән чыгарып кияләр дә намаз беткәч, кире тыгып куялар. Ә хатын-кыз яулыгын бөтен җирдә бәйләп йөрегә мәҗбүр. Бу адымга кыю, ихлас кеше генә бара ала. Әлбәттә, яулык – гаурәтне каплый һәм аны кию мәҗбүри булып тора, ә түбәтәй – әдәплелек билгесе. Шул ук вакытта яулык хатын-кызның төп сыйфатын ассызыклый: ул – оялчанлык. Шулай ук яулык хатын-кызның матурлыгын чит кеше күзеннән саклый. Зиннәтле әйбер бервакытта да аяк астында ятмый, еракка, пәрдә артына яшерелгән була. Яулык-хиҗапның максаты – шул. Яулык ул иреклек билгесе дә: диндә булмаган хатын-кыз матурлыгын каплап йөри алмый, ул аны бөтен кешегә күрсәтергә мәҗбүр. Ә мөслимә хатын-кыз теләгән кешесенә генә күрсәтә, димәк, ул – ирекле һәм ихтыярлы. Тик бүген кайбер мөслимә кызлар да хиҗаптан йөрүгә карамастан, матурлыкларын күрсәтергә тырышалар. Бу яулыкны артка бәйләп колакларын, муенны күрсәтүдә чагыла. Кайберләре исә урамга чыкканда ис-

лемай куллана, бизәнә, ә бит бу дин тарафыннан тыелган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хатын-кызларга төнге намазларга йөрергә ярый, ди, ләкин урамга чыкканда ислемай кулланыны һәм бизәнүне тыя, чөнки бу гамәл чит күзләрне җәлеп итә һәм оят төшенчәсенә каршы килә. Шулай ук мөслимәләр арасында тырнак буяу да таралган. Буялган тырнакка су эләкми, димәк, тәһарәт тә дөрес булмый. Мөселман булмаган хатын-кызларга охшатып тырнак үстерү дә күрергә була. Тырнак үстерү кыргыйлык билгесе булып тора. Шуңа да сөннәт буенча тырнак кисү, төкләрне кыру каралган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, тырнак астында шәйтаннар оялый, ди.

Кызганычка, кайчак мөслимәләрнең күлмәкләре дә шәригатькә туры килеп бетми. Артык сыланып торган күлмәкләр хатын-кызны яшерәсе урынга, киресенчә, аларның буй-сынын ачып сала. Аннан соң хиҗапның максаты – хатын-кызны яшерү, аңа игътибарны киметү. Тик хәзер, киресенчә, хиҗапның игътибар билгесенә әйләнгәнен күрергә була. Хәтта махсус мөселман модалары үткәрелә. Жюри әгъзалары ирләр, алар алдына чыккан хатын-кызларны карап утыралар. Бу очракта хиҗап үзенең максатын югалта.

Мөслимә хатын-кызның төп бизәге – ул оялчанлык. Үзеңне иркен тоту оялчанлыкка каршы килә. Моңа егетләр белән иркен аралашу да керә. Кайвакыт мөслимә кызлар егетләр белән икәүдән-икәү кала. Әти-әниләре белән киңәшләшмичә кияүгә дә чыгарга мөмкиннәр. Егетләргә бу кулай, артык мәшәкать булмый, ләкин бу очракта хатын-кыз кыйммәтен югалта. Кайвакыт социаль челтәрдә дә мөслимәләрнең үзләрен иркен тотканын күрергә була. Эш белән шөгыльләнсәләр бер хәл, тик үзләрен төшереп кую, тормышын тасвирлауны күрәбез. Бу да оялчанлыкка каршы килә. Динебез хатын-кызны чит күзләрдән яшерергә тырыша. Шуның өчен аңа урамга чыгып йөрү, көндез мәчеткә бару, ирләр белән бер мәҗлестә утыру киңәш ителми. Әгәр инде кыз бала өйдә утырган килеш фотоларын

интернетка куя икән, бу тыюларның мәгънәсе калмый. Шулай ук егетләр белән аралашкан вакытта да интернет, телефон аша аралашуны тере аралашу дип кабул итәргә була. Кызның туганнары алдында артык әйбер сөйләшеп булмый, ә телефон аркылы кирәкмәгән сүзләргә кереп китәргә мөмкин. Күргәнебезчә, яулык – ул баш каплау гына түгел, ул күңел халәте икән. Яулык бәйләгән кызлар моны күбесе аңлый, әлхәмдүлилләһ.

Хатын-кызның төп урыны – ул гаиләдә. Аллаһы Тәгалә безгә гаилә корырга әмер бирә:

وَأَنكِحُوا الْأَيَامَىٰ مِنكُمْ وَالصَّالِحِينَ مِنْ عِبَادِكُمْ وَإِمَائِكُمْ ۚ إِن يَكُونُوا فُقَرَاءَ يُغْنِهِمُ اللَّهُ مِن فَضْلِهِ ۗ وَاللَّهُ وَاسِعٌ عَلِيمٌ ﴿٣٢﴾

**«Арагыздан буйдакларны, колларыгыздан һәм җарияләрегездән иман һәм тәкъвалык иясе булган кешеләрне никахлагыз. Әгәр алар фәкыйрь булсалар, Аллаһы аларны Үз рәхмәтеннән [ризык белән] бай итәчәк. Аллаһы [белеме һәм мәрхәмәте мәңгелек киң булган] һәрнәрсәне Чолгап алучы, [һәрнәрсәне] Белүче».**

«Нур», 24:32

Никахсыз мөнәсәбәтләрне динебездә күз алдына китереп тә булмый, бу зина була. Аллаһы Тәгалә:

وَلَا تَقْرَبُوا الزِّنَىٰ ۖ

**«Зинага якын килмәгез”,** – дип әйтә.

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:32

Ир белән хатын никах укытып кына бергә тора ала. Никахтан соң аларның тормышын гаилә кануннары көйли. Никахсыз ялгыз тормыш Ислам диненә, сөннәткә туры килми. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Никах минем сөннәтем, кем минем сөннәтемнән баш тарта, шул миннән булмас», – дип әйтә. Егет-кызларны яшь чакларыннан ук ни-

кахка әзерләп үстерәләр. Шушы никах тормышында зур урынны хатын-кыз алып тора. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә: «Дөнья – ул ләззәт, ә иң зур ләззәт – ул яхшы хатын». Чыннан да, яхшы хатын – тормышны гаять бизәргә, начар хатын гаять авырайтырга мөмкин. Бүгенге көндә җәмгыятьтә гаиләләрнең күп таркалуын күрәбез. Бу мөселман гаиләләрен дә урап узмый, алар арасында да аерылу күп. Димәк, дин гаиләне саклауга ярдәм итми булып чыга. Егетләр-кызлар динне гаилә тормышына күчерә алмыйлар. Гаеп, әлбәттә, ирләрдә дә бар, тик бу очракта хатын-кыз тырышса, гаиләне саклап калыр иде. Күп очракта аерылышу турында сүзне хатын-кыз кузгалта, ирләрнең еш кына аерылышасы килми. Шулай ук гаиләдә дә тынычлык хатын-кыз гаебе белән югалырга мөмкин. Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَمِنْ آيَاتِهِ أَنْ خَلَقَ لَكُم مِّنْ أَنفُسِكُمْ أَزْوَاجًا لِّتَسْكُنُوا إِلَيْهَا وَجَعَلَ بَيْنَكُم مَّوَدَّةً وَرَحْمَةً ۚ إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَاتٍ لِّقَوْمٍ يَتَفَكَّرُونَ ﴿٢١﴾

**«Бергә яшәвегез өчен үзләрегездән сезнең өчен хатыннар яралтуы һәм арагызда сөю [нәтиҗәсендә хасил булган бердәмлек] белән бер шәфкать [чарасы булган бала] бирүе дә – Аның билгеләреннән. Һичшиксез, монда уйлаганнар өчен [аңлатылып бетерә алмаслык дәрәҗәдә зур] билгеләр бар».**

«Рум», 30:21

Ир кеше өйләнеп, кайчагында тынычлык тапмый, аның тормышы тагын катлаулана, ул күбрәк борчыла башлый. Димәк, хатын-кыз аңа эзләгән тынычлыгын бирә алмый. Хатында матурлык, байлык, нәсел-нәсәп булса әйбәт, әлбәттә, тик тынычлык булмаса, гаиләдә боларның берсе дә кирәк түгел. Бүген бик еш: «Чын ирләр хәзер юк», – дигән сүзне ишетергә туры килә. Чын ирләр һавадан төшми, аларны хатын-кыз тәрбияли: башта –

әни, аннан соң – хатын. Халык мәкале “Ирне ир иткән дә хатын, ирне җир иткән дә хатын”, – дип әйтә.

Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләм: «Хатын һәм балалар ир кешене харамга да кертергә мөмкин», – дип әйткән. Ничек итеп? Артык таләпләр куеп. Сәхабә хатын-кызлар ирләрен эшкә шундый сүзләр белән озатканнар: «Без хәерчелеккә түзәрбез, әмма тәмуг газабына түзә алмабыз, шуңа да хәләл мал алып кайтыгыз». Мөслимә хатын өчен мал беренче урында түгел, хәләллек беренче урында торырга тиеш.

Кайбер егетләр: «Хатыннарыбыз өйдә эшләми», – дип тә зарланалар. Имеш, алар эшләргә тиеш түгел. Чыннан да, гаиләне ир кеше тәэмин итәргә тиеш. Ләкин өйдәге эшләрне хатын-кыз эшләмәү очраклары билгеле түгел. Гомәр, Гали, Зөбәйр радыяллаһу ганһүмнәрнең хатыннары бөтенесе дә өйдә авыр эшләрне башкарган, хәтта Фатыйма радыяллаһу ганһә, әтисе Мөхәммәд саллэллаһу галәйһи вә сәлләм янына килеп, авыр тормышына зарлана һәм ярдәмгә хезмәтче сорый. Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләм Гали радыяллаһу ганһене “Ник эшләтәсең”, – дип ачуланмый, ә, зикер кылыгыз дип, киңәш бирә.

Бала тәрбиясе дә яхшы хатыннан тора, чөнки ир кешенең бала тәрбияләргә вакыты юк. Шуңа әниләр әтиләргә карата балада ихтирам булдыралар: “Әтиегез сезне ярата; әтиегездән рөхсәт сорагыз; әтиегезгә әйтәм; әтиегез кайта” сүзләре белән игелекле балалар тәрбияләнә.

Күргәнебезчә, хатын-кыз тормышта нинди зур роль уйный. Шуңа да иманлы, тәкъва мөслимә хатын-кыз җәмгыятьне тамырдан үзгәртеп кора ала. «Һәрбер бөек ир артында бөек хатын тора» дигән сүз дә бар бит.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*ТҖ МДНнең Дәгъват бүлеге*

*17 июль вәгазе,*

*Зөлкагъдә аеның 26 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Зөлхиҗҗә ае – хаҗ ае

Мәрхәмәтле һәм Рәхимле булган галәмнәрнең Раббысы Аллаһы Тәгаләгә хәмедләребезне, олуглауларыбызны һәм шөкераналарыбызны җиткерәбез. Аллаһы Тәгаләнең Расүле, хаклыкны җиткерүче, Раббыбызның Мостафасы Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-сәламнәребезне ирештерәбез.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, җомга көне мөбарәк булсын! Бу көннең дәрәҗәсен аңлап, аның фазыйләтләренә ирешергә насыйп итсен. Шушы көннең фазыйләтләренең иң мөһимнәре – ул госел алып, тәһарәтләнеп, чиста һәм матур киемнәр киеп җомга хотбәсен тыңлау, намазын уку, пәйгамбәребезгә күбрәк салаватларыбызны җиткерү, догада булу. Җомга көнендә кылына торган шушы билгеле гамәлләр безнең дөнья һәм Ахирәтебез өчен хәерледер.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِذَا نُودِيَ لِلصَّلَاةِ مِن يَوْمِ الْجُمُعَةِ فَاسْعَوْا إِلَىٰ ذِكْرِ اللَّهِ وَذَرُوا الْبَيْعَ ۚ ذَٰلِكُمْ خَيْرٌ لَّكُمْ إِن كُنتُمْ تَعْلَمُونَ ﴿٩﴾

**«И, иман китерүчеләр! Җомга көнне намаз өчен [азан әйтелеп] чакырылгач, Аллаһыны искә алырга ашыгыгыз һәм сәүдәне ташлагыз. Бу – [сәүдәнең вакытлы файдасыннан] сезнең өчен яхшырак. Әгәр дә белсәгез иде [мәңгелек алыш-бирешне сайлар идегез]».**

«Җомга», 62:9

Белгәнебезчә, динебез биш әйбергә, гамәлгә таяна. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мәшһүр хәдисендә болай дип әйткән: «Дин биш әйбердән тора, ягъни нигезләнә: Аллаһыдан башка илаһ юк һәм Мөхәммәд Аллаһының Расүле икәнлегенә шәһадәт бирү, намаз уку, зәкят чыгару, Рамазан аенда ураза тоту, мөмкинлегең булса, хаҗ гамәлен кылу».

Һәм шушы гамәлләр һәрбер мөкәлләф (йөкләнелгән, кушылган) кеше өчен билгеле бер шартлар үтәлгәндә фарыз хөкемендә була. Ягъни, шушы гамәлләрне кылу безгә Аллаһы Тәгалә каршында олы дәрәҗәләргә ирешүдә һәм дөнья һәм Ахирәтебездә бәхетле булуда сәбәп булып тора, ә аларны калдыру олы гөнаһ була.

Гамәли яктан динебездә Исламның бишенче баганасы булган хаҗ гамәле билгеле бер шартлар үтәлгәндә, кешенең мөмкинлеге булганда, һәрбер мөкәлләф өчен гомерендә бер тапкыр булса да кылу фарыз булып тора. Ягъни, кешенең балигълыкка ирешкән, акыллы мөселман булуы тиешле. Шулай ук матди һәм физик яктан бу гамәлне үти алу кирәк. Болардан тыш, үзең сәфәргә чыгып киткәч, синең өеңдә булган кешеләрнең, ягъни гаиләңнең мохтаҗлыкта калмавы мөһим. Һәм юлның сугыштан, юлбасарлардан, йогышлы авырулардан һ.б. имин булуы шарт булып тора.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

وَلِلَّهِ عَلَى النَّاسِ حِجُّ الْبَيْتِ مَنِ اسْتَطَاعَ إِلَيْهِ سَبِيلًا

**«Юл үтеп аңа [җитәргә] көч тапкан кешеләр Аллаһы өчен [Әл-Харам мәчете булган] Бәйткә хаҗ кылырга тиеш»,**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:97

ذَٰلِكَ وَمَن يُعَظِّمْ شَعَائِرَ اللَّهِ فَإِنَّهَا مِن تَقْوَى الْقُلُوبِ

**«Менә шулай! Кем дә кем [Сафа-Мәрва кебек] Аллаһының [диненең] билгеләрен [бигрәк тә корбанлык хайваннарын]**

**олыласа, һичшиксез, ул – күңелләрнең [Аллаһы Тәгаләгә карата булган] тәкъвалыгыннан».**

«Хаҗ», 22:32

Хаҗ гамәлләре Аллаһының әмере белән һиҗрәтнең 9 нчы елында фарыз кылынды.

Хаҗ сүзенең телдәге мәгънәсе олы, зур максат дигәнне белдерә, ә динебездәге мәгънәсенә килгәндә, билгеле бер вакытта, урында, гыйбадәт кылу максаты белән изге урыннарга сәфәр кылу. Киңрәк тукталып әйтсәк, билгеле бер вакытлар – ул шәүвәл, зөлкагъдә, зөлхиҗҗә айлары. Ягъни, бу айлар – хаҗ айлары: хаҗга җыену, аны көтү һәм башкару вакыты. Зөлхиҗҗә – нәкъ менә шушы гамәлләрне кылу ае. Билгеле бер урыннар – ул Харам җирлеге, изге булган Гарәфәт, Мина үзәнлеге, Мөздәлифә җирлеге, Кәгъбәтулла. Билгеле бер гыйбадәтләр – ул ихрам кию, тәваф кылу, Сафа белән Мәрва арасында йөгереп үтү, шәйтанга таш ату, Гарәфәт тавында тәүбә-истигъфар, догада булу, корбан чалу һ.б. Шушы гамәлләрне аерым бер вакытта, изге җирләрдә, билгеле бер тәртиптә кылу хаҗ гамәле булып тора.

Хөрмәтле җәмәгать! Изге булган җирләргә бару – ул Аллаһы Тәгаләнең кунагы булу. Ә галәмнәрнең Раббысы, Тәрбиячесе булган Рәхимленең кунагы булу – олы дәрәҗә, зур бәхеттер. Хаҗ кылучыларны Аллаһы Тәгалә Рәхимленең кунаклары, дип әйтте, чөнки, алар Ибраһим пәйгамбәр галәйһиссәлам җиткергән Аллаһының чакыруын ишетеп килделәр.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَأَذِّنْ فِي النَّاسِ بِالْحَجِّ يَأْتُوكَ رِجَالًا وَعَلَى كُلِّ ضَامِرٍ يَأْتِينَ مِن كُلِّ فَجٍّ عَمِيقٍ

**«[Иске нигезләр өстенә Кәгъбәне төзеп бетергәннән соң, аңа әмер иттек] «Кешеләр арасында хаҗны [фарыз буларак] игълан ит, [аталарының билләрендә, аналарының аналыкларында булганнарга чакыруны ишеттерим дә анда тәлбия китергәннәр дөньяга килгәннән соң] җәяү һәм һәр ерак юлдан килгән арык [һәм алҗыган] дөя өстендә сиңа килсеннәр».**

«Хаҗ», 22:27

Өстәп әйтергә кирәк: бу – Аллаһының бер могҗизасы, чөнки, Аллаһы Тәгаләнең бу чакыруы гасырлар үтү белән онытылмый, киресенчә, ел саен миллионлаган кешеләр хаҗ һәм гомрә гыйбадәтен башкара.

Шулай ук, хаҗ кылуның тагын бер фазыйләте – ул гөнаһларның кичерелүе. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Хаҗ кылганда сүгенмичә, гөнаһ кылмыйча бу гамәлне башкаручы кеше хаҗдан анасы тудыргандагы кебек, гөнаһсыз булып кайта». Гайшә анабыз радыяллаһу ганһә тапшырган бер хәдистә болай дип әйтелгән: «Аллаһы Тәгалә хаҗ вакытында, Гарәфәт көнендә арып-талчыгып, ихластан кичерү сораучыларны, иң кимендә, күңелендә иман бөртеге булучыны да кичерер, җәһәннәмнән азат итәр». Шул сәбәптән, шәйтан бу көнне үзенә урын таба алмас, борчылыр. Гомер буе адаштырырга, юлдан яздырырга тырышкан, әмма Аллаһының ярлыкавын өмет итеп, гөнаһтан тыелып килгән бәндәләрнең бер мизгелдә гөнаһлары кичерелүе шәйтанга авыр булыр.

Ихластан, тырышып, хәләл булган малларыбыз белән хаҗ кылып, ул гамәлебез кабул булса, аның әҗере – җәннәт. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Ике кече хаҗ кылу арасында кеше барлык гөнаһларыннан котыла, ә зур хаҗ өчен бүләк булып оҗмах тора».

Җәннәт – үз чиратында, Аллаһының ризалыгы билгесе. Изге җирдә кылган гамәл-гыйбадәтләребезнең дә дәрәҗәсе күп тапкырга арта.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Әл-Харам мәчетендә укылган намаз башка мәчеттә укылган намазга караганда йөз мең мәртәбә артыграк»[1].

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Һәркөн Кәгъбәтуллага Аллаһының 120 рәхмәте иңә, шуның 60 ы тәваф кылучыга, 40 ы анда гыйбадәт кылучыга, 20 се Кәгъбәтуллага караучыга бирелер», – дип әйткән.[2]

Хаҗга барганда, гамәли һәм физик яктан да әзерлекле булу мөһим. Барыр алдыннан әлеге гыйбадәтне башкарганда белергә тиешле булган гыйлем алу, юлда һәм хаҗ кылган вакытта кирәкле булган әйберләрне алдан әзерләү дә хаҗ кылуны җиңеләйтә. Шулай, ук кем белән бару, яки үзеңә хәерле юлдаш табу да – бик мөһим мәсьәлә. Бу мәсьәләләрдә җирле имамнар, хәзрәтләр белән киңәшләшү яхшы булыр.

Аллаһы Тәгалә гамәл-гыйбадәтләребезне, кылган хаҗ һәм гомрәләребезне кылган изгелекләребезне, биргән садакаларыбызны кабул итеп, һәрбарчаларыбызга да изге җирләргә барып кабул булырдай хаҗ, гомрә гамәлләрен кылып кайтырга насыйп итсен һәм һәрбарчаларыбыздан да разый булсын, хата-кимчелекләребезне гафу иләп, күңелләребездә булган изге теләкләребез, уй-ниятләребез белән ике дөнья бәхет-сәгадәтенә ирештерсен. Ил көннәребезгә иминлек, бәрәкәт насыйп булсын.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының

---

[1] Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

[2] Әбү Зарр риваятендә килә.

саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Инсаф хәзрәт Ибатуллин,*

*«Динислам» мәчете имам-хатыйбы*

*24 июль вәгазе,*

*Зөлхиҗҗә аеның 3 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Гарәфә көне өстенлеге

Галәмнәрне юктан бар кылып, безләрне халык иткән, тәрбияләгән Аллаһыга барча хәмде-сәналәребез, олуглау-мактауларыбыз булсын. Һәм дә Аллаһының хак илчесе, тугры пәйгамбәре, шәриф булган колы – пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифләребез ирешсә иде.

Корбан бәйрәме алдыннан булган Гарәфә көне зөлхиҗҗә аеның 9 нчы көне булып санала.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм моның хакында: «Гарәфә көне иң хәерле көн булып тора. Ул җомга көненә охшаган. Гарәфә көне җомга көнне башкарылмаган 70 хаҗдан да яхшырак. Иң хәерле дога – ул Гарәфә көнендә кылынган дога. Мин һәм миңа кадәр булган пәйгамбәрләр әйткән иң хәерле сүзләр – «Ләә иләәһә илләллааһу вәхдәһү ләә шәрикә ләһ» («Тиңдәше булмаган Аллаһыдан башка илаһ юк», – дип әйткән.[1]

Адәм баласы, Гарәфәт тавында торганда, кулларын күтәреп дога кылганда, үзенең никадәр дәрәҗәдә Аллаһыга якын икәнен тоя. Бу, чыннан да, сүзләр белән генә тасвирлап биреп булмый торган көчле рухи халәт. Хаҗ кылучы кеше, күпме чакрымнар үтеп, ихлас йөрәктән Ислам баганасы фарызларының берсен башкарырга килгән. Ул Аллаһы йортында кунакта. Кунак кеше мәртәбәле булган кебек, биредә дә Раббыбыз колына карата аеруча да рәхмәтле. Мәрхәмәтлеләрнең иң Мәрхәмәтлесе булган Аллаһы кызу кояш астында кулларын күтәреп Раббысына мөрәҗәгать иткән колының кулларын буш калдырмый. Аллаһы Тәгалә Гарәфәт тавында басып торган колларын күреп, фәрештәләр каршында алар

[1] «Мүвәттә» хәдисләр җыентыгыннан, «Хаҗ», 246.

белән горурлана: «Сез Минем колларыма карагыз әле. Алар ерак юллар үтеп Миңа килгәннәр. Тузанга баткан, чәч-башлары таралмаган халәттә биредә басып торалар. Сез Минем шаһитларым булыгыз: Мин аларның догаларын кабул кылам, яманны яхшыга үзгәртеп, үзара булган бурычларыннан тыш, һәр сораганнарын үтәячәкмен», – дип әйтә.

Гайшә радыяллаһу ганһә Расүлебезнең әлеге сүзләрен риваять иткән: «Гарәфә көнендәге кебек бер көнне дә Аллаһы шул хәтле колларын җәһәннәм утыннан коткармас. Ул Үзенең барлыкка китергән затларына мәрхәмәтен ирештерә һәм аларны фәрештәләр алдында мактый».[1]

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Гарәфә көнен хөрмәтләгез, чөнки Аллаһы аңа үзенчәлекле кыйммәт бирде», – дигән хәдисе белән безгә бу көннең бөеклегенә игътибарыбызны юнәлтергә куша. Бу көнне уразада, догада булып, гөнаһларның кичерелүен сорау мөһим.

Атабыз Адәм белән анабыз Хавва җәннәттән җир йөзенә төшерелгәннән соң бер-берләрен югалтканнар. Һәм бик күп еллардан соң аларның очрашулары Гарәфәт дип исемләнгән тауда булган. Гарәфә көне алдыннан булган көн Тәрвия дип атала. Хәдисләрдә Расүлебез: «Тәрвия көнне ураза тотучы һәм гөнаһка илтә торган сүзләрдән ерак торучы җәннәткә керер», – дип әйткән.

Бу көнгә кагылышлы бик күп хәдисләрне беләбез. Гарәфә көне уразасы турында исә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Гарәфә көнне ураза тотучы кешегә Адәм галәйһиссәламнән алып, сурга өрелгәнче җир йөзендә яшәгән кешеләр санынча савап язылыр»;

«Гарәфә көне уразасы мең көн нәфел уразасы тотуга тиң»;

«Гарафә көне уразасы ике мең колны азат итүгә, ике мең дөяне корбан чалуга һәм Аллаһы юлындагы көрәш өчен ике мең атны корбан итүгә тиң», – дип әйткән.

[1] Мөслим хәдисләр җыентыгыннан, «Хаҗ», 436.

Әмма белү генә аз, боларны белеп гамәл кыла алсак иде. Яңа ел башлану белән, календарьләребездә, менә бу көнне әлеге бәйрәм, менә бу айда монысы, дип билгеләп куйыйк. Ураза тота торганнарында ураза тотып, нәфел намазлары укылганнарында намазлар укыйк, күп итеп зикер һәм догалар кылыйк. Моның бер кыенлыгы да юк, чөнки мондый мәртәбәле көннәр 365 көнгә берничә көн генә туры килә. Алар бармак белән санарлык кына. Бу изге кичәләрне гафләттә үткәрү дөрес булмас. Беребез дә аларны киләсе елларда да каршы алу-алмау турында бер сүз дә әйтә алмый. Барысы да – Аллаһы ихтыярында. Күпме гомеребез калганын, күпме кыласы гамәлләребез язылганын да белмибез.

Кайбер галимнәр Гарәфә көнендә мең тапкыр «Ихлас» сүрәсен укуны киңәш итә. Бер хәдистә «Ихлас» сүрәсен уку барлык гөнаһларны бетерүе хәбәр ителә, әмма бу очракта бер гөнаһ искәрмә булып тора, ул – башка колларның хокукларын кысу. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр берәү Гарәфә көнендә «Бисмилләһ» әйтеп, «Ихлас» сүрәсен укыса, аның барлык гөнаһлары ярлыканыр һәм догалары кабул булыр», – дип әйткән.

Әлеге көнне хөрмәтләргә һәм аны тиешенчә үткәрергә кирәк. Без ул көнне хаҗда түгел, ә йортларыбызда булсак та, Гарәфәт тавында кулларын күтәреп, догалар белән Раббыбызга ялварган кардәшләребез белән бердәмлекне тоябыз. Бу көнне без гөнаһка илтергә мөмкин булган һәр гамәлдән ерак булырга тиешбез. Корбан бәйрәме алдыннан булган бу көннәр елның иң кадерле көннәре булып санала. Алар – гыйбадәт һәм мәгъфирәт көннәре.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисендә: «Гарәфә көнендә Аллаһы Тәгалә Үзенең колларына карый һәм йөрәкләрендә кечкенә генә бөртек кадәр иман булса, аларны гафу итә», – дип әйтелә.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*

*«Саләх» мәчете имам-хатыйбы*

# Корбан гаете хотбәләре

## خُطْبَةُ عِيدِ الاَضْحَى

## الْخُطْبَةُ الاْولَى

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ تَقَدَّسَ ذَاتُهُ عَنِ الشِّرْكِ وَالزَّوَالِ وَنَطَقَتِ الْاَدِلَّةُ بِاَوْصَافِهِ الْجَلاَلِ وَالْجَمَالِ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ تَحَيَّرَ فِي كُنْهِ ذَاتِهِ الْعُقُولُ وَالْاَفْهَامُ وَعَجَزَ عَنْ اِدْرَاكِ صِفَاتِهِ الرَّاسِخُونَ الْاَعْلَامُ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ اَكْرَمَ عِبَادَهُ الْمُؤْمِنِينَ بِالشُّهُورِ وَالْاَيَّامِ فِصَالِ. وَاَوْجَبَ فِي هَذِهِ الْاَيَّامِ عَلَى الْاَغْنِيَآءِ الْحَجَّ وَالطَّوَافَ بِالْبَيْتِ الْمُكَرَّمِ عِنْدَ الْكَبِيرِ الْمُتَعَالِ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. نَحْمَدُ اللَّهَ الَّذِي لَمْ يَتَّخِذْ صَاحِبَةً وَلاَ وَلَدًا وَلَمْ يَكُنْ لَّهُ شَرِيكٌ فِي الْمُلْكِ وَلَمْ يَكُنْ لَّهُ وَلِيٌّ مِّنَ الذُّلِّ وَكَبِّرْهُ تَكْبِيرًا وَاَشْهَدُ اَنْ لَّا اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ

وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَاَشْهَدُ اَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ شَفِيعُ الْعُصَاةِ فِي يَوْمِ الْجَزَاءِ بِاَمْرِ اللَّهِ الْكَرِيمِ الْمُتَعَالِ.

صَلَّى اللَّهُ تَعَالَى وَسَلَّمَ عَلَيْهِ وَعَلَى ءَالِهِ وَاَصْحَابِهِ الْمَوْصُوفِينَ بِاَحْسَنِ الْاَخْلَاقِ وَاَطْيَبِ الْاَحْوَالِ.

يَا اَيُّهَ النَّاسُ. اِعْلَمُوا اَنَّ يَوْمَكُمْ هَذَا يَوْمٌ شَرِيفٌ وَعِيدٌ لَّطِيفٌ لِّلْخَوَاصِّ وَالْعَوَامِّ يَوْمٌ عَظِيمٌ قَدَرُهُ لِلْاَنَامِ، عَظِّمُوا هَذَا الْيَوْمَ بِالْاِنْعَامِ وَالْاِحْسَانِ وَاِيْصَالِ الْاَرْحَامِ. اِنَّ اللَّهَ تَبَارَكَ وَتَعَالَى اَوْجَبَ عَلَيْنَا النَّحْرَ بِقَوْلِهِ وَانْحَرْ، وَاَمَرَ خَلِيلَهُ بِذَبْحِ وَلَدِهِ الْاَشْهَرِ وَاُفْدِيَ بِكَبَشٍ مِّنَ الْجَنَّةِ بِوَاسِطَةِ الْمَلَكِ الْمُقَرَّبِ وَلاَ يَجِبُ عَلَى الْفَقِيرِ عَلَى الْقَوْلِ الْمُعْتَبَرِ الْبُدْنَةُ عَنْ سَبْعَةٍ وَالضَّأْنُ وَالْمَعْزُ عَنْ وَاحِدٍ مُجْزِأَةٌ وَلاَ يَجُوزُ الْعَجْفَآءُ وَالْعَرْجَآءُ وَمَقْطُوعَةُ الْاُذُنِ وَالْاِلْيَةِ وَالَّذِي لاَ يَمْشِي عَلَى الْمَنْسَكِ عِنْدَ الْمَذْهَبِ الْمُعْتَبَرِ.

ضَحُّوا عَنْ اَطْيَبِ اَمْوَالِكُمْ وَعَظِّمُوهَا امْتِثَالاً لِّاَمْرِ رَسُولِ اللَّهِ الْمُقَرَّرِ كَمَا قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: عَظِّمُوا ضَحَايَاكُمْ فَاِنَّهَا عَلَى الصِّرَاطِ مَطَايَاكُمْ. وَاِنَّ اللَّهَ تَعَالَى اَوْجَبَ عَلَيْنَا تَكْبِيرَ التَّشْرِيقِ عَقِبَ الْفَرْضِ مِنْ فَجْرِ يَوْمِ عَرَفَةَ اِلَى اخِرِ اَيَّامِ التَّشْرِيقِ بِقَوْلِهِ تَعَالَى: وَاذْكُرُوا اللَّهَ فِي اَيَّامٍ مَّعْدُودَاتٍ. اَعُوذُ بِاللَّهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ، بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَنِ

الرَّحِيمِ: يَآ اَيُّهَ الَّذِينَ ءَامَنُوا اتَّقُوا اللَّـهَ وَلْتَنْظُرْ نَفْسٌ مَّا قَدَّمَتْ لِغَدٍ وَاتَّقُوا اللَّـهَ اِنَّ اللَّـهَ خَبِيرٌ بِمَا تَعْمَلُونَ.

بَارَكَ اللَّهُ لَنَا وَلَكُمْ فِي الْقُرْءَانِ الْعَظِيمِ وَنَفَعَنَا وَاِيَّاكُمْ بِالْاَيَاتِ وَالذِّكْرِ الْحَكِيمِ وَاَسْتَغْفِرُ اللَّـهَ الْغَفَّارَ لِي وَلَكُمْ وَلِسَائِرِ جَمَاعَةِ الْمُسْلِمِينَ الْحَاضِرِينَ اَجْمَعِينَ اِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ الْجَوَادُ الْكَرِيمُ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ.

## الْخُطْبَةُ الثَّانِيَةُ

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ نَحْمَدُهُ وَنَسْتَعِينُهُ وَنَسْتَغْفِرُهُ وَنُؤْمِنُ بِهِ وَنَتَوَكَّلُ عَلَيْهِ وَنَعُوذُ بِاللَّهِ مِنْ شُرُورِ اَنْفُسِنَا وَمِنْ سَيِّئَاتِ اَعْمَالِنَا مَنْ يَهْدِهِ اللَّـهُ فَلاَ مُضِلَّ لَهُ وَمَنْ يُضْلِلْهُ فَلاَ هَادِيَ لَهُ. وَاَشْهَدُ اَنْ لَا اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَاَشْهَدُ اَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ.

اِنَّ اللَّـهَ وَمَلاَئِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ. يَآ اَيُّهَا الَّذِينَ ءَامَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا.

اَللَّـهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى ءَالِ مُحَمَّدٍ بِعَدَدِ مَنْ صَلَّى وَصَامَ.

اَللَّـهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى ءَالِ مُحَمَّدٍ بِعَدَدِ مَنْ قَعَدَ وَقَامَ.

صَلِّ وَسَلِّمْ عَلَيْهِ وَعَلَى جَمِيعِ الْاَنْبِيَاءِ وَالْمُرْسَلِينَ وَعَلَى مَلَائِكَتِكَ الْمُقَرَّبِينَ وَعَلَى اَهْلِ طَاعَتِكَ اَجْمَعِينَ مِنْ اَهْلِ السَّمَاوَاتِ وَالْاَرَضِينَ. وَارْحَمْنَا وَاحْشُرْنَا مَعَهُمْ بِرَحْمَتِكَ يَا اَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

اَللّٰهُمَّ اغْفِرْ لِلْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ الْاَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْاَمْوَاتِ اِنَّكَ اَنْتَ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ وَمُنْزِلُ الْبَرَكَاتِ وَرَافِعُ الدَّرَجَاتِ وَقَاضِيُ الْحَاجَاتِ بِرَحْمَتِكَ يَا اَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

اَللّٰهُمَّ ارْحَمِ الْخُلَفَاءَ الرَّاشِدِينَ وَالْاُمَرَاءَ الْمَاضِينَ الَّذِينَ قَضَوْا بِالْحَقِّ وَكَانُوا يَعْدِلُونَ.

اَللّٰهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ وَاهْدِ مَنْ خَذَلَ الدِّينَ.

عِبَادَ اللّٰهِ، اِنَّ اللّٰهَ يَاْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْاِحْسَانِ وَاِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَالْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ.

اُذْكُرُوا اللّٰهُ الْعَلِيَّ الْعَظِيمَ الْحَيَّ الْقَيُّومَ يَذْكُرْكُمْ وَاشْكُرُوهُ يَزِدْكُمْ وَاسْتَغْفِرُوهُ يَغْفِرْ لَكُمْ وَلَذِكْرُ اللّٰهِ تَبَارَكَ وَتَعَالَى اَعْلَى وَاَوْلَى وَاَعَزُّ وَاَجَلُّ وَاَعْظَمُ وَاَتَمُّ وَاَكْبَرُ.

## Корбан гаете хотбәсенең кириллицага транскрипциясе

### Беренче хотбә

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллаһү әкбәр вә лилләһил-хәмд. Сүбхәәнә мән тәкаддәсә ҙәәтүһү ганиш-ширки вәззәүәәл. Вә нәтакатил-әдилләтү би әүсаафиһил-җәләәли вәлҗәмәәл.

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр, вә лилләһил-хәмд. Сүбхәәнә мәң тәхәййәра фии күнһи ҙәәтиһил-гукуулү вәл-әфһәәм, вә гаҗәзә ган идрааки сыйфәәтиһир-раасихуунәл-әгъләәм.

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр вә лилләһил-хәмд. Сүбхәәнә мән әкрамә гыйбәәдәһүл-мүэминиинә бишшүһүүри вәл-әййәәмил-фисааль. Вә әүҗәбә фии һәәҙиһил-әййәәми галәл-әгънийәәил-хәҗҗә вәт-тауәәфә бил-бәйтил-мүкәррами гыйндәл-кәбиирил-мүтәгааль.

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр вә лилләһил-хәмд. Нәхмәдүллааһәл-ләҙии ләм йәттәхыйҙ саахибәтәү-үә ләә вәләдә, вә ләм йәкүнләһү шәриикүң фил-мүлки, вә ләм йәкүнләһү вәлиййүн-минәҙ-ҙүлли вә кәббирһү тәкбиираа. Вә әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһү вәхдәһүү ләә шәриикә ләһ. Вә әшһәдү әннә сәййидәнәә Мүхәммәдән габдүһүү вә расүүлүһү шәфиигуль-гусаати фии йәүмил-җәзәә’и би әмрилләәһил-кәриимил-мүтәгааль. Салләллааһү тәгааләә вә сәлләмә галәйһи вә галәә әәлиһи вә әсхәәбиһил-мәүсууфиинә би әхсәнил-әхъләәкый вә әтъйәбил-әхүәәл.

Йә әййүһән-нәәс! Игъләмүү әннә йәүмәкүм һәәҙәә йәүмүн шәриифүн вә гыйидүн ләтыйифүн лил-хаүәәссый вәл-гаүәәмм. Йәүмүн гаҙыймүң кадәруһү лил-әнәәм. Гаҙҙыймүү һәәҙәл йәүмә бил-ингаами вәл-ихсәәни вә

иисаалил-әрхәәм. Вә иннәллааһә тәбәәракә вә тәгәәлә әуҗәбә галәйнән-нәхра би каулиһи вәнхәр. Вә әмәра халииләһүү би ҙәбхи вәләдиһил-әшһәри вә үфдийә би кәбәшин минәл җәннәти би вәәситатил-мәләкил-мукарраб, вә ләә йәҗибү галәл-фәкыйри галәл-каулил-мүгьтәбәр. Әл-бүднәтү ган сәбгатин вәд-да’нү вәл-мәгъзү гән вәәхидин мүҗзиәтү вә ләә йәҗүүзүл-гаҗфәәә’ү вәл-гарҗәәә’ү вә мәкътуугәтүл-үҙүни вәл-илйьәти вәлләҙии ләә йәмшии галәл-мәнсәки гыйндәл-мәҙһәбил-мүгътәбәр.

Даххүү ган әтъйәби әмүәәликүн вә гаҙҙыймүүһәә-мтиҫәәлән лиәмри расүүлилләәһил-мүкаррар. Кәмәә каалә расүүлүллааһи салләллаһү галәйһи вә сәлләм: «Гәҙҙыймүү дахәәйәәкүм фә-иннәһәә галәс-сыйраати мәтаайәәкүм». Вә иннәллааһә тәгаалә әуҗәбә галәйнәә тәкбиират-тәшриикый гакыйбәл-фәръдый мин фәҗри йәүми гарафәтә иләә әхыйри әййәәмит-тәшриикый би каулиһи Тәгаалә: «үәҙкүруллааһә фии әййәәмим-мәгъдүүдәәт». Әгүүҙү билләәһи минә шәйтаанир-раҗиим: Йәә әййүһәлләҙиинә әәмәнүт-тәкуллааһә вәлтәңҙур нәфсүм-мәә каддәмәт ли-гад. Вәттакуллааһә иннәллааһә хабиирум бимәә тәгъмәлүн.

Бәракәллаһу ләнәә вә ләкум фил-Куръәнил-гаҙыйм, вә нәфәганәә вә ийәкүм бил-әәйәәти вәҙ-ҙикрилхәкиими вәәстәгъфируллаһәл-гаффәәралии вә ләкүм вә лисәә’ири җәмәәгатил-мүслимиинәл-хәәдыйриинә әҗмәгыйн. Иннәһү һүәл-гафуурур-рахиимүл-җәүәәдүл-кәриимүс-сәмиигуль-гәлиим.

## Икенче хотбә

Әлхәмдү лилләәһи нәхмәдүһү вә нәстәгыйнүһү вә нәстәгъфируһү вә нү’минү биһи үә нәтәүәккәлү галәйһи вә нәгууҙү билләәһи мин шүруури әңфүсинәә вә мин сәййиәәти әгъмәәлинәә мән-йәһдиһил-лләәһү фәләә мүдыйллә ләһү вә мән-йүдълилһү фәләә һәәдийә ләһ. Вә әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһү вәхдәһү ләә шәриикә ләһү вә әшһәду әннә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһ.

Иннәллаһә вә мәләәикәтәһүү йүсаллүүнә галән-нәбий. Йәә әййүһәлләҙиинә әәмәнү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимәә. Аллаһүммә салли галәә Мүхәммәдин вә галәә әәли Мүхәммәдин бигадәди мән салләә вә саам. Аллаһүммә салли галәә Мүхәммәдин вә галәә әәли Мүхәммәдин бигадәди мән кагәдә вә каам.

Саллии вә сәллим гәләйһи вә галәә җәмиигыйль-әнбийәә'и вәл-мүрсәлиин. Вә галәә мәләәикәтикәл-мүкаррабиинә вә галәә әһли таагәтикә әҗмәгыйн мин әһлис-сәмәәүәәти вәл-әрадыйн. Вәрхәмнәә вәхшүрнәә мәгаһүм бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимин.

Аллаһүммә-гъфир лилмү'миниинә вәл-мү'минәәт, вәл-мүслимиинә, вәл-мүслимәәт, әл-әхъйәә'и минһүм вәл-әмьүәәт, иннәкә әнтә мүҗиибүд-дәгаүәәт вә мүнзилүл-бәракәәт, вә раафигуд-дәраҗәәт, вә каадыйүл-хәәҗәәт, бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин.

Аллаһүммәр-хәмил хуләфәә'әр-раашидиинә вәл-үмәраа'әл-мәдыйнәл-ләҙиинә кадау билхәккый вә кәәнүү йәгъдилүүн. Аллаһүммән-сурмән нәсараддиинә вәһди мән хаҙәләддиин. Гыйбәәдәллааһ, иннәллааһә йәъ'мүрү бил-гадли вәл-ихсәәни вә ийтәәәи ҙил-курбәә вә йәнһәә ганил-фәхшәәәи вәл-мүнкәри вәл-бәгъйи йәгыйиҙукум ләгәлләкүм тәҙәккәрүүн. Үҙкүруллааһәл-галиййәл-гаҙыымәл-хәййәл-каййүүм, йәҙкүрүкүм вәшкү-рүүһү йәзидкүм, вәстәгъфирууһүү йәгъфир ләкүм вә ләҙикруллааһи тәбәәракә вә тәгәәләә әгъләә вә әүләә вә әгәззү вә әҗәллү вә әгҙамү вә әтәммү вә әкбәр.

## Корбан гаете хотбәсенең тәрҗемәсе

### Беренче хотбә

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Ширек һәм юкка чыгу кебек сыйфатлар каршында мөкатдәс булган Аллаһының заты барча кимчелекләрдән пакьтер. Аллаһының матурлыгына һәм олуглыгына барлык мәхлүкъләр дәлил булып тора.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Аллаһының үзенчәлегенә (Аның рәхмәтле Зат булганына) акыл ияләре хәйран калды.

Аның сыйфатларына төшенүдән тирән белем ияләре гаҗиз калды.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Мөэмин колларына карата айлар һәм көннәр аша юмартлык күрсәткән Зат барча кимчелекләрдән пакьтер. Бу көннәрдә байларга хаҗны, Олуг Аллаһы каршында изге йорт булган Кәгъбәтулланы тәваф кыларга йөкләгән Зат барча кимчелекләрдән пакьтер.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Үзенә тормыш иптәше алмаган, балалар тудырмаган, падишаһлыгында тиңдәше булмаган, кимсетелүдән коткаручы дустына мохтаҗ булмаган Аллаһыны мактыйбыз һәм Аңа тәкбир әйтегез. Аллаһыдан башка бернинди илаһ булмаганлыгы турында гуаһлык бирәм, Ул — бердәнбер, Аның тиңдәше юк, пәйгамбәребез Мөхәммәд – Аның колы һәм расүледер. Ул (Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм) җәза алу көнендә гөнаһлылар өчен юмарт булучы һәм олуг Аллаһының әмере белән шәфәгать кылучыдыр.

Аллаһы Тәгалә аңа, анының гаиләсенә, иң күркәм әхлак һәм иң яхшы әхвәл белән сыйфатланган сәхабәләренә салават һәм сәлам ирештерсен.

Әй кешеләр! Белегез ки, сезнең бу (бәйрәм) көнегез — хөрмәтле көндер, байлар һәм ярлылар өчен юмартлык бәйрәмедер, бу көннең кадере – халыклар өчен бөектер, бу көнне изгелек, ихласлылык, туганлык мөнәсәбәтләрен ныгыту аша бөекләгез. Чынбарлыкта, безгә Аллаһы Тәбәракә вә Тәгалә Корбанны «Корбан чал!» дип йөкләде. Шулай ук Үзенең хәлиленә (Ибраһим галәйһиссәламгә) иң танылган баласын корбан итәргә боерган. Якын фәрештә (Җәбраил галәйһиссәлам) аша җәннәттән куй бирелгән. Иң могтәбәр сүзгә таянсак, фәкыйрь корбан чалырга тиеш түгел. Эре терлек җиде кешедән һәм бәрән вә кәҗә бер кешедән йөкләмәне төшерә. Могтәбәр мәзһәб буенча, сукыр, аксак, колагы киселгән, җенес әгъзасы өзелгән, мөгезе сынган һәм корбан чалу урынына үзе бара алмаслык дәрәҗәдә хәлсез булган терлек корбанга ярамас.

Корбаннарыгызны иң яхшы малларыгыздан чалыгыз, һәм Аллаһы Расүленең әмеренә буйсынып, корбаннарыгызны хөрмәт итегез (чалганда йомшаклык күрсәтегез). Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Корбанлыкларыгызны хөрмәт итегез, ник дисәгез, алар Сират күперендә сезнең утырып чыга торган хайваннарыгыздыр». Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә безгә фарыз намазларыннан соң тәкбир-тәшрикне Гарәфәт көненең иртәнге намазыннан алып, Тәшрик көненең ахырына кадәр Үзе йөкләгән: «Саналган көннәрдә Аллаһыны искә алыгыз», – дигән. Таш белән атылган шайтаннан Аллаһыга сыгынам. Рәхимле, Шәфкатьле Аллаһы исеме белән.

Аллаһы Коръәндә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَلْتَنظُرْ نَفْسٌ مَّا قَدَّمَتْ لِغَدٍ ۖ وَاتَّقُوا اللَّهَ ۚ إِنَّ اللَّهَ خَبِيرٌ بِمَا تَعْمَلُونَ ﴿١٨﴾

**«Әй иман китергән кешеләр! Аллаһыдан куркыгыз һәм һәр җан иясе иртәгәсе көн өчен нәрсә әзерләгәнен күрсен. Аллаһыдан куркыгыз, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә эшләрегездән хәбәрдар».**

«Хәшер / Сөреп чыгару», 59:18

Аллаһы безгә һәм сезгә бөек Коръән аша бәрәкәт бирсен. Барыбызга да аятьләр һәм хикмәтле зикер аша файда китерсен. Гөнаһларны гафу итүче Аллаһы каршында үзем һәм сезнең өчен, шулай ук башка мөселман җәмәгатьләренең бөтенесе өчен, Аллаһы каршында истигъфар кылам (ярлыкау сорыйм). Чынбарлыкта Ул (Аллаһы) — Гафу итүче, Рәхимле, Данлы, Юмартлык иясе, Ишетүче һәм Белүче.

## Икенче хотбә

Аллаһыга мактау булсын, без Аны мактыйбыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, истигъфар кылабыз, Аңа иман китерәбез, Аңа таянабыз. Нәфесләребезнең начарлыгыннан һәм гамәлләребезнең кабахәтлегеннән Аллаһыга сыгынабыз. Кемгә Аллаһы һидаять бирсә —аны адаштыручы булмас, кемне адаштырса — аңа беркем дә һидаять бирә алмас. Аллаһыдан башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд — Аның колы һәм хак илчесе булуына гуаһлык бирәм.

«Шик юктыр ки, Аллаһы да, фәрештәләр дә Пәйгамбәргә күп салаватлар әйтә. Әй, иман китергән адәмнәр, сез дә аңа салават әйтегез һәм сәламнәрегезне күндерегез».

Аллаһым, Мөхәммәдкә һәм Мөхәммәднең гаиләсенә намаз укучыларның һәм ураза тотучыларның саны кадәре салават ирештер.

Аллаһым, Мөхәммәдкә һәм Мөхәммәднең гаиләсенә утырган һәм басып торган кемсәләрнең саны кадәре салават ирештер.

Аңа салават һәм сәлам ирештер, шулай ук бөтен пәйгамбәрләргә һәм илчеләргә (расүлләргә), якын булган фәрештәләреңә, шулай ук күкләрдә һәм җирләрдә яшәүче Сиңа итагать әһелләренә салават һәм сәлам ирештер. Шулай ук, безгә карата рәхимле бул һәм безне алар белән бергә мәхшәр мәйданында җый. Синең рәхмәтең белән, йә рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

Аллаһым, мәгъфирәтең белән мөэминнәрне вә мөэминәләрне, мөселманнарны вә мөслимәләрне, аларның исәннәрен дә, үлгәннәрен дә гафу ит. Чынбарлыкта, Син догаларны кабул итүче, бәрәкәт индерүче, дәрәҗәләрне күтәрүче, хаҗәтләребезне үтәүче. Синең рәхмәтең белән, йә рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

Аллаһым, тугры хәлифәләргә һәм хак белән казыйлык иткән вә гаделлек кыла торган булып үткән әмирләргә карата рәхимле бул.

Аллаһым, кем дингә ярдәм итә, шуңа ярдәм ит һәм кем динне кимсетә, шуңа һидаять бир.

Аллаһының коллары! Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә гаделлек, ихсан, якыннар белән йөрешүне әмер итә һәм фәхешлекне, кире кагылган нәрсәләрне, чиктән чыгуны тыя. Аллаһы сезне вәгазьли, шаять, сез искә алырсыз.

Бөек, Олуг, Тере, Уяу булган Аллаһыны зикер итегез – Ул сезне зикер итәр, Аңа карата шөкер итегез – Ул арттырыр. Аның каршында тәүбә-истигъфар кылыгыз – Ул мәгъфирәте белән гафу итәр. Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләне зикер итү исә – иң бөек, иң гүзәл, иң олуг, иң җәлаләтле, иң камил, иң зур гамәл.

*31 июль вәгазе,*

*Зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Корбан гаете вәгазе

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн, әммә бәгъд: барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз, хәмде-сәналәребез галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһы Тәгаләгә һәм дә салават-шәрифләребез Аның сөекле хәбибе, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән, мөселманнарга һидаять юлын күрсәткән Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә булса иде. Аның әһле-бәйтенә, сәхабәләренә, табигыйн һәм тәбге-табигыйннәргә, галим-голәмәләргә, имамнарга, остазларга, шәехләргә, ислам юлында булган бәндәләргә Аллаһының рәхмәте һәм мәгъфирәте ирешсә иде. Безгә тәүфыйк-истикамәттә булып, киләчәктә дә шөкеранә һәм изгелек кылучылардан булырга Аллаһы Раббым нәсыйп итсә иде.

الله أكبر، الله أكبر، لا إله إلا الله، والله أكبر، الله أكبر، ولله الحمد

Газиз дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Мөселманнар бүген бөтен ислам дөньясы мәчетләрендә Гыйдүл-Әдха – Корбан бәйрәме көнен билгеләп үтә. 2020 елның Корбан бәйрәме көне җомга көненә туры килде – “нур өстенә нур” бу. Раббыбызның рәхмәтендә буларак, яңадан безгә ачык мәчетләр һәм тыныч вәзгыять биргәне өчен, күркәм бәйрәм көннәрендә күбрәк дога кылып, рәхмәт-шөкерләребезне әйтсәк иде, Раббыбыздан бер-беребезгә изгелек теләп, мәгъфирәт сорасак иде.

Исебезгә төшерик әле: шундый вакытлар да булды ки, коронавирус пандемиясе сәбәпле, мәчетләр ябык иде; бер-беребездән «куркып», туганнардан да ерак тордык. Ул вакытларда кул биреп сәламләшү дә вакытлыча юкка чыкты кебек. Аллаһы Тәгаләнең бу сынавы – ул тормышыбызда ярамаган харам эшләр белән шөгыльләнүдәндер бәлки. Аллаһы, хикмәте белән, безгә бу авырлыкны дөньяда ук иңдерде: Ул безне чистартты, пакьләде.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә ил-көннәребезгә, җаннарыбызга тынычлык, тәннәребезгә исәнлек-саулык, күңелләребезгә тәүфыйк-һидаять биреп, һәркайсыбызга хәерле һәм бәрәкәтле тормышлар насыйп итсен.

الله أكبر، الله أكبر، لا إله إلا الله، والله أكبر، الله أكبر، ولله الحمد

Корбан бәйрәме көннәрендә ихлас күңелдән изге гамәл-гыйбадәтләр кылып, корбаннарыбызны чалып, Аллаһы Тәгаләнең иксез-чиксез рәхмәтләренә барчабызга да ирешергә насыйп булсын, чалган корбаннарыбыз бәрабәренә, Аллаһы Тәгалә безгә Кыямәт көнендә Сират өстеннән яшен тизлеге белән үтәргә насыйп итсә иде!

Корбан – Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әмер иткән әҗер-саваплы, Раббыбыздан бүләк буларак иңгән олуг гыйбадәт. Әлеге гыйбадәт вәҗиб (тиешле) гамәл булып санала – чиксез нигъмәтләре белән куандырып торган Раббыбызга шөкераналар кылып, итагать итү билгесе.

Матди яктан тиешле нисабы булган теләсә кайсы мөселман кешесе корбан чалу йоласын үтәргә тиеш. Ул – Корбан бәйрәме көннәрендә (10, 11, 12 нче зөлхиҗҗә) хайванны чалу белән башкарыла (аңа хәтле чалынган корбан гади ит булып саналыр).

Корбан – Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә, Аның ризалыгына, хайванны (кәҗә, сыер, сарык, үгез, тәкә яки дөя) бугазлап якынаю (әҗер-

саваплы эш) дигән мәгънәне анлата. Корбан хайваны үзе нинди сыйфатта һәм ничә яшьтә, нинди рәвештә булырга тиешлеген, бу йоланы кемнәргә башкарырга кирәклеген – барысын да безгә шәригать ачыклый.

الله أكبر، الله أكبر، لا إله إلا الله، والله أكبر، الله أكبر، ولله الحمد

Кайбер кешеләр корбанны: «Бу корбанны мәрхүм әти-әни өчен чалам», – дип ниятли. Онытмыйк: корбан бары тик Аллаһы ризалыгы өчен генә башкарыла, ләкин әҗер-савабын мәрхүм «әти-энигә»дә багышлап була, Раббыбызның рәхмәте киң. Иң мөһиме ихласлык белән Аллаһы Тәгалә рызалыгы өчен булсын. Һәм инде үзеңнең гаиләң исеменнән башкарганнан соң, башка кеше өчен дә бугазларга рөхсәт ителә. Коръәни Кәримдә Раббыбыз болай дип боера:

فَصَلِّ لِرَبِّكَ وَانْحَرْ ﴿٢﴾

**«Раббың өчен намаз укы һәм (Анын исеме белән) корбан чал (да, корбан итләрен юксыларга тарат)».**

«Кәүсәр», 108:2

Аяти кәримәдә «Раббың өчен корбан чал» дип китерелә. Гали бине Әби Талибтан хәдис китерелә, Расүли Әкрам: «Аллаһы Тәгалә Үзеннән башкага корбан чалган кешегә ләгънәт кылды!»[1] – дип әйткән.

Мәшһүр хәдистә Расүли Әкрам Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең гамәли сөннәте китерелә: ул үзе һәм бөтен мөселманнар исеменнән берәр корбан чалган иде. Корбан чалган вакытта: «Бисмилләһи, Аллаһу Әкбәр (Аллаһының исеме белән, йә Аллаһы). Бу корбанны Мөхәммәдтән, аның гаиләсеннән һәм аның өммәтеннән кабул ит», – дип әйтте. Шуннан соң ул ике корбан чалды».[2]

---

1 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан, 1978.

2 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

Теләгән кешегә шәригать ике корбан чалырга да рөхсәт итә: ихласлык белән үз исеменнән һәм башкалар исеменнән дә башкара ала.

Хәзрәти Гали радыяллаһу ганһе ике корбан чалып, шуның берсен Аллаһы Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә багышлый торган була. Моның сәбәбен сораганнарга: «Аллаһы Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Үзең исән чакта, минем өчен дә корбан чал», – дип, васыять әйтеп калдырды. Аның бу васыятенә бервакытта да хилафлык китермәм», – дип җавап биргән[1].

Шушы хәдисләр безгә түбәндәгеләр өчен дәлил булып тора: 1) Корбан бары тик Аллаһы ризалыгы өчен генә бугазлана; 2) өстәмә сарыкны чалу, яки башка хайванны корбан китерүнең әҗер-савабын мәрхүм «әтиәнигә» дә багышлап була, Раббыбызның рәхмәте киң.

الله أكبر، الله أكبر، لا إله إلا الله، والله أكبر، الله أكبر، ولله الحمد

Гает намазыннан соң, гадәттә, без корбан чалырга ашыгабыз, ләкин корбан чалган вакытта да үзебезнең мөселман икәнлегебезне онытмасак иде, сабырлык белән бәйрәм көнендә башка бәндәләрнең дә хакларына кермәсәк, бәйрәмне – бәйрәм итеп үткәрсәк идек.

Иң мөһиме – Аллаһы Тәгаләнең әмерен үтәү, корбанның хикмәтенә ирешү. Коръәни Кәримдә Раббыбыз болай дип әйтә:

لَن يَنَالَ ٱللَّهَ لُحُومُهَا وَلَا دِمَآؤُهَا وَلَٰكِن يَنَالُهُ ٱلتَّقْوَىٰ مِنكُمْ ۚ

**«Аларның итләре дә, каннары да Аллаһыга ирешәчәк түгел. Аңа сездән бары такъвалыгыгыз гына ирешә».**

«Хаҗ», 22:37

Тәкъвалык – калебтә, тәкъвалык – Аллаһы Тәгаләдән курку, Аның кушкан әмерен үтәү, үзеңне эчке яктан тәрбияләү һәм яхшырту. Пәйгамбәребезнең хатыны Гайшә радыяллаһу ганһә хәбәр иткән:

1 Мөстәдрәк, 4/255; Әбү Давыд, Әдахи, 1; Хәким, Тирмизи.

«Гаиләдә ничә кеше булуга карамастан, гаилә исеменнән бер корбан чалсаң да була», – дигән хәдис бар. Безгә йөкләнгән бер корбан чалу – тиешле (вәҗиб) булып тора, икенчесе – нәфел.

الله أكبر، الله أكبر، لا إله إلا الله، والله أكبر، الله أكبر، ولله الحمد

Корбан бәйрәменең нигез-тарихы Ибраһим һәм Исмагыйль галәйһүмәссәлам белән бәйле. Бу вакыйгада зур гыйбрәт бар: беренчедән, нинди генә авыр боеру булмасын – Раббыбызның әмеренә буйсыну; икенчедән, кешенең җаны, калган мәхлүкъларга караганда, Раббыбыз хозурында күпкә өстенрәк. Өченчесе: авырлыктан соң, җиңеллек килә; дүртенчесе: шәйтан вәсвәсәсенә бирелмәсәк, дөньяви ва ахирәви бәхетрәхәткә ирешә алырбыз; бишенчесе: әти белән баланың мөгамәләсе һ.б.

الله أكبر، الله أكبر، لا إله إلا الله، والله أكبر، الله أكبر، ولله الحمد

Корбан бәйрәменең хикмәте бары тик гает намазы һәм корбан чалу белән генә чикләнми:

1. Бәйрәмдә очрашып, туганлык җепләрен ныгыту;

2. Халыкка ярдәм күрсәтү (фәкыйрь-мескеннәргә, мохтаҗларга корбан итен тарату, саранлыктан саклану);

3. Корбан чалу аркылы Раббысының әмерен үтәү, итагать итү;

4. Бәйрәмнәрнең иң олысы, пәйгамбәрләрдән килгән бәйрәм, аны саклап, башкаларга җиткерү;

5. Корбан чалу аркылы Раббысының ризалыгына ирешү мөмкинлеге;

6. Корбан сәбәпле Раббыбыз биргән нигъмәтләргә шөкеранә белдерү;

7. Корбан – гөнаһлардан пакьләнү.

Агымдагы 1441 һиҗри ел үзенчәлекләре белән узып бара. Без, мөселманнар, бу зөлхиҗҗә аенда, гадәттә, хаҗда була идек. Аллаһы Раббыбызның әмерен үтәүчеләр, маллары һәм тәннәре белән, Аның хозурына килеп, Бәйтүл-Харамда тәваф кылып, Гарәфәттә дога кылып, ва-

кытыбызны гыйбадәттә һәм тырышлыкта үткәрә идек. Бүген, гадәттә, Мина җирлегендә җәмарәт урынында шәйтанга таш атар идек. Ләкин бу ел хаҗ юк, шуңа күрә хаҗ соңга калдырылмас. Расүли Әкрам: «Әл-хәҗҗү ләә йүәҗҗәл», – дип әйткән, – «Хаҗ соңга калдырылмас».

Тирә-яктагы дусларыбызга карасак, күпме кеше дөньядан бәрзах (кабер) тормышына күчеп китте. Алар арасында мәчет салучылар, хаҗ кылучылар, корбан чалучылар, садака-зәкят биреп, намаз укучылар булса – сөенербез. Аллаһы Тәгалә кылган гыйбадәтләребезне кабул итсен, бөек җәннәтләренә керергә насыйп итсен. Ләкин араларында намаз уку авыр эш булып күренгән кешеләр дә бар иде. Яки аны шәйтан кыен бер эш итеп күрсәтте: «Намазның тәртибен дә белмисең, син мәчеткә йөрмә», – дип, икенче берсенә: «Әле сиңа монда килергә иртәрәк, картайгач, яки эчүеңне ташлагач барырсың», – дип вәсвәсә кыла иде.

Мөхтәрәм җәмәгать! Үлем – ул хак, Аллаһы хак, җәннәт-җәһәннәм хак. Изгелектә бер-беребезгә ярдәм күрсәтик. Үзебез белән бары тик эшләгән изгелекне генә ала алабыз, башкасы – кала.

Мөхтәрәм җәмәгать! Мөмкинлеге була торып та, кеше намаз укымаса яки корбан чалмаса, зур гөнаһлы булыр. Мәхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кем дә кем (Корбан чалырга) мөмкинлеге була торып корбан чалмаса, безнең намаз укый торган җиргә якын килмәсен»,[1] – дип әйткән.

الله أكبر، الله أكبر، لا إله إلا الله، والله أكبر، الله أكبر، ولله الحمد

Корбан чалганда тәртипне сакларга кирәк. Хәдисләр җыентыгында Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе риваять итә: «Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер көнне мөгезле, таза ике сарыкны корбан итеп чалды. Ул сарыкны суйганда, аягы белән сарыкның сыртына басып: «Бисмилләһи Аллаһу әкбәр», – дип суйганын күрдем».[2]

---

1 Имам Әхмәд, Ибне Мәҗе хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан, 1966.

Өстәмә дога кылып, корбан чалуны җиренә җиткереп башкарсак, Аллаһының бәрәкәте иңәр. Хәдисләр җыентыкларының берсендә Әбү Давыд радыяллаһу ганһедән түбәндәге риваять килә: Җәбир бине Габдулла радыяллаһу ганһе исемле сәхабәдән хәбәр ителә: «Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм корбан итеп ике мөгезле, ак төстәге, печелгән тәкәне чалды. Ул аларны чалырга, дип яткыргач, түбәндәге сүзләрне әйтте:

«Инни вәҗҗәһтү вәҗһиилил-ләҙии фәтарас-сәмәәвәәти вәл әрдъ галәә милләти Ибраһиимә хәниифәә вә мәә әнә мин әл-мүшрикиин. Иннә саләәтии вә нүсүүкии вә мәхъяйә вә мәмәәтии лилләһи Раббил гааләмиин. Ләә шәриикәләһ. Вә биҙәәликә үмиртү вә әнәә минәл-мүслимиин».

**Мәгънәсе:** «Дөреслектә, мин йөземне, Аллаһыга тиңдәш кылмыйча, Ибраһим пәйгамбәр динендә булган килеш, күкләрне, җирне барлыкка китергән Затка юнәлттем. Һәм мин Аллаһыга тиңдәш кылучылардан түгел. Дөреслектә, минем намазым да, корбаным да, тормышым һәм үлемем дә дөньяларның Раббысы – Аллаһы өчен. Аның тиңдәше юк. Мөселманнардан булган хәлдә, миңа шуны эшләү әмер ителде. Йә Аллаһы! Бу (корбан) Синнән (килгән ризык иде) һәм ул Синең өчен Мөхәммәдтән һәм аның өммәтеннән (чалына). Аллаһының исеме белән. Ул Аллаһы – иң бөек». Соңыннан ул аларны чалды.

الله أكبر، الله أكبر، لا إله إلا الله، والله أكبر، الله أكبر، ولله الحمد

Хәзер безнең янәшәдә бәйрәм намазында төрле шәһәр, илләр, хәтта төрле континентлардан килгән мөселманнар катнаша. Тышкы аерымлыкларыбыз – тел, тән төсе һ.б. булса да, без бер-беребезне ихластан сәламлибез һәм бер Аллаһыга итагать итеп гыйбадәт кылабыз. Ислам безнең йөрәкләрне берләштерде һәм барлык мөселманнарны бер-берсенә карата дин-кардәшләр итте. Киләчәктә дә дус яшик.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем, татарстанлылар! Изге бәйрәмебез мөбарәк булсын! Раббыбыз һәммәбезгә дә иман байлыгы, саулык-

сәламәтлек, гаилә бәхете бирсен. Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*
*Татарстан Республикасы мөфтие*

*31 июль вәгазе,*

*Зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Корбан чалу көннәре – мәрхәмәтлелеккә юл

Раббыбыз вакытның хуҗасы булып тора. Без яшәгән дөнья тирәли үткән еллар, айлар, атналар, көннәр, сәгатьләр, хәтта мизгелләр булсынмы – барысы да Аллаһы Тәгаләгә буйсынып, Аның кушкан тәртипләре белән баралар. Күп очракта сәгате – сәгатькә, минуты минутка туры килгән һәм Бөек Хуҗабызның Үзе тарафыннан сайланып куелган билгеле бер вакытлар бар. Һәм әлеге вакыт өзекләре, җәдвәлебезнең калган көннәреннән аеруча бәрәкәт вә уңыш дәрәҗәсе белән аерылып тора.

Аллаһы Тәгалә елдагы унике айның дүртесен (зөлкагъдә, зөлхиҗҗә, Рамазан, раҗәб) башкалар өстендә Коръән аяте белән олугласа, шулар арасыннан Ул Рамазанга карата тагын да ныграк басым ясый. Аерым көннәр арасыннан Раббыбыз җомганы бөекләсә, тулы бер сүрәдә төннәрдән Кадер кичәсеннән дә хәерлерәге булмавы хакында сөйли. Шулай ук динебез Исламда декадалар (ункөнлекләр) турында да хәдис-аятьләр аз түгел. Алар арасында иң дәрәҗәле төннәр декадасы итеп Рамазан аеның ахыргы ун төне билгеләнсә, көндезге вакытлар арасында Раббыбыз зөлхиҗҗә аеның беренче ун көнен бөекли. Моның хакында Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَالْفَجْرِ ﴿١﴾ وَلَيَالٍ عَشْرٍ ﴿٢﴾

**«[Иртән агарып килгән] Таң белән ант итәмен! [Зөлхиҗҗәнең башындагы] Ун төн белән дә [ант итәмен]!»**

«Фәҗер / Таң», 89:1-2

Адәм баласы тарафыннан бу көннәрдә кылынган изгелекләр Раббыбыз каршында иң яхшылары булып исәпләнә. Аларның дәрәҗәсе турында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дип әйтә: «Аллаһы бу ун көндә кылынган игелекле эшләрне башка көннәрне кылынган игелекләргә караганда күп мәртәбә ныграк ярата». Моны ишетеп сәхабәләр аңардан: «Ий, Аллаһының Илчесе, әгәр дә башка көннәрдәге эш Аллаһы юлындагы дошманнар белән көрәш булса дамы?» – дип сораганнар. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларга: «Әйе, хәтта бу эш Аллаһы юлында көрәш булса да. Әмма Аллаһы юлына чыгып, үз-үзен һәм үз мөлкәтен корбан иткән кешеләрдән тыш»,[1] – дип җавап кайтарган.

Ошбу мөбарәк вакытның һәрбер мизгелен изгелектә куллану мөселманга зур бурыч булып тора. Иң баштан фарыз гамәлләребезне (намазларыбызны) тәртипкә салсак, аннары булдыра алган кадәр мөстәхәб гыйбадәтләребезне арттыру тиешледер. Беренчесе күбрәк руза тотса, икенчесе күбрәк садакасын бирсә, өченчесе күбрәк зикер-тәсбихен әйтсә, дүртенчесе күбрәк Коръән укыса, бишенчесе җәмгыятькә карата изгелекләрен арттырса бу, һичшиксез, Аллаһы каршында безнең дәрәҗәне үстерүдә зур бер өлеш кертү булачак.

Олуг хаҗ гыйбадәтен кылу да мөселманнарга шушы мөбарәк вакытта кушылган. Безнең дин кардәшләребез зөлхиҗҗә аеның сигезенче көнендә Мәккә шәһәре тирәли җыелып, тугызынчы көндә Гарәфәт тавы дип аталган изге җирлеккә юнәләләр. Ошбу урында бөтен хаҗилар кояш баеганчыга кадәр кулларын күтәреп, Аллаһыга догалары белән ялваралар. Ә менә без, хаҗга бара алмаганнар, үзебезнең туган якларыбызда махсус Гарәфә көне рузасын тотабыз. Бу гыйбадәт хакында пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең хәдисендә: «Гарәфә көнендә токтан

[1] Имам Әл-Бохари, Имам Тирмизинең хәдисләр җыентыгыннан.

ураза өчен Аллаһы үткән ел һәм киләсе ел гөнаһларын кичерәчәк»[1], – дип әйткән. Ягъни бер көнлек руза, ике еллык хата-гөнаһларыбыздан арыныр өчен, гаҗәеп бик зур бер форсат булып тора.

Шулай ук икенче бер хәдистә Гарәфә көне хакында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһының Үз колларын җәһәннәм утыннан Гарәфә көненнән дә күбрәк коткарган башка көне юктыр. Дөреслектә, Аллаһы бу көннәрдә Үз колларына якынлашып, фәрештәләре каршында алар белән мактана...»[2] – дип әйткән.

Гарәфә көнендә Аллаһыга кылган дога күп мәртәбә дәрәҗәлерәк һәм кабул булу ихтималы да зурractыр. Моның хакында Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Гарәфә көн догасы – иң яхшы догадыр»[3]. Шуңа да хөрмәтле кардәшләрем, бу көндә һәм гомумән зөлхиҗҗә аеның беренче ункөнлегендә (декадасында) истигъфар (Аллаһыдан кичерү сорау) догалары белән ашыгыгыз, чөнки гади вакытта ул бер истигъфар булса, бу көннәрдә исә, Аллаһы теләсә, шул бер истигъфарның йөзләгән истигъфарга әверелү мөмкинлеге бар.

Быел, Аллаһы теләсә, Гарәфә көне 30 нчы июльгә туры килә. Шул сәбәптән, хөрмәтле кардәшләрем, бу көнне бушка уздырмагыз, булдыра алган кадәр күбрәк якын туганнарыгыз белән рузаларын тотып, садакаларын биреп, догалар белән Аллаһыга ялварып уздырырга тырышыгыз!

Зөлхиҗҗә аеның унынчы көнендә Корбан гаете, милади белән ул 31 нче июльгә туры килә. Бу көн шулай ук Раббыбыз каршында бик мөкатдәстер, чөнки шушы вакытта динебездә иң зур гамәлгыйбадәтләрнең берсе – корбан чалына. Иртә белән үк мөселманнар мәчетләргә ашыгалар, анда гает намазларын кылып, җәмәгать белән тәкбирләр әйтәләр, бер-берләренә бүләкләр тараталар. Соңрак халык

[1] Имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

[2] Имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

[3] Имам Тирмизинең хәдисләр җыентыгыннан.

корбан чалу белән мәшгуль була. Итне гореф-гадәткә туры китереп өчкә бүләләр: бер өлешен авыр хәлле мохтаҗларга, икенче өлешен туганнарга кучтәнәч итеп, өченче өлешен үзенә – корбан ашын уздырырга дип хәзерләп куялар.

Корбан бәйрәменнән соң «әййәмү-тәшрик» килә, ягъни бу көннәрдә әүвәлге мөселманнар чалынган итләрен кояш нурлары астында киптерә торган булганнар. Моның өчен, гадәттә, өч тәүлек җитә торган булган, шуңа да Исламда бу өч көн «тәшрик көннәре» дип атала һәм бу вакытны бөтен дөнья мөселманнары гадәттәгечә ял итеп, бер-берсенә кунакка йөреп күңел ачуда уздыралар.

Югарыда әйтелгәнчә, динебездә бәйрәм көннәрендә тәкбир әйтү йоласы бар. Моның хакында бик күп риваятьләрдә телгә алына һәм алар барысы да Аллаһыны олуглау сүзләренең дәрәҗәсе турында сөйлиләр. Шуларның берсе Гомәр Әл-Фәрук радыяллаһу ганһе белән бәйле. Бохари хәзрәтләре китергән хәдистә: «Гомәр Мина җирлегендә үзенең чатырында еш тәкбир әйтә иде, ә мәчеттә булган кешеләр аның тавышын ишетеп, аның артыннан кабатларга ашыгалар иде. Алар артыннан базарда булган кешеләр дә кабатлый башлап, бар Мина җирлеге тәкбир әйтүдән тетрәп тора кебек иде...» Ягъни, шушы көннәрдә тәкбир сүзләрен «Аллааһу әкбәр! Аллааһу әкбәр! Ләә иләәһә илләллааһу, вәллааһу әкбәр! Аллааһу әкбәр! Вә лилләәһил-хәмде!» әйтү бик тә мөһим йола булып тора. Аны без Гарәфә көненең иртәнге намазыннан соң башлап җибәрсәк, ахыргы тәшрик көненең икенде намазыннан соң тәмамларга тиешбез.

Шулай ук динебезнең күркәм гамәлләреннән саналган корбан итен тарату гадәте бар. Бу изге эш ихлас нияттән башкарылса, Аллаһы каршында бик дәрәҗәледер, чөнки монда күп төрле саваплы эшләр бергә туплана: садака тарату вә аларны ашату, кардәшлек вә туганлык җепләрен ныгыту, кешеләрнең хәлләрен белешү вә алар өчен дога кылу, милләт вә динара дуслыкны арттыру һ.б. Шуңа да хөрмәтле кардәшләрем, чалынган корбан

итләрен фәкать үзебез һәм якыннарыбызга гына түгел, ә бөтенләй таныш булмаган кешеләргә тарату динебездә олуг гамәлләрдән булып хисаплана. Аллаһы Тәгалә Үзенең Китабында болай дип әйтә:

الَّذِينَ يُنفِقُونَ أَمْوَالَهُم بِاللَّيْلِ وَالنَّهَارِ سِرًّا وَعَلَانِيَةً فَلَهُمْ أَجْرُهُمْ عِندَ رَبِّهِمْ وَلَا خَوْفٌ عَلَيْهِمْ وَلَا هُمْ يَحْزَنُونَ ﴿٢٧٤﴾

**«Төнлә һәм көндез, яшерен һәм ачыктан-ачык малларын сарыф иткән кешеләргә – Раббылары катында әҗерләре [әзерләп куелган]. Аларга бернинди дә курку булмас, [дөньяда калдырган нәрсәләре өчен] алар хәсрәт тә чикмәс»[1].**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:274

Хөрмәтле кардәшләрем! Билгеле булганча, изге зөлхиҗҗә аенда бу мөбарәк тәүлекләр мөселманнар өчен зур мөмкинлекләрне үз эчләренә яшерәләр. Раббыбыз Аллаһы каршында зур әҗер-савапларга ирешү өчен, диннең тирән мәгънәләренә төшенеп, шушыункөнлектә үз гамәл-гыйбадәтеңне арттыру хәерле.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

1 Бу аяте кәримә Әбү Бәкер Ситдыйк, Гали бине Әби Талиб һәм Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһүмнәр кебек затлар хакында иңә. Хәзрәти Ситдыйк радыяллаһу ганһе кәсеп иткән кырык мең динарның уң меңен – төнлә, ун меңен – көндез, ун меңен – яшерен, ун меңен ачыктан-ачык тараткан. Гали радыяллаһу ганһе дә төннәрен әсхабе суффәгә (торыр урыннары булмыйча, мәчет түбәсе астында яшәгәннәргә) бер үлчәм хөрмә җибәрә, моннан тыш, кулындагы дүрт дирһәмнең берсен – төнлә, берсен – көндез, берсен – яшерен, берсен ачыктан-ачык садака итеп тараткан. Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһе исә аларга көндезге сәгатьләрдә бик күп динар җибәргән. Аяте кәриmәнең, Аллаһы юлында җиһад кылу өчен атлар үрчеткән мөһаҗирләр турында иңгәне дә белдерелә, чөнки алар көне-төне, яшерен һәм ачыктан-ачык – һәрвакыт ул атларны карау белән мәшгуль булалар. Аяте кәримәдә төнлә сүзенең – көндез, яшерен сүзенең ачыктан-ачык дигәннән алдарак әйтелүе яшерен садаканың ачыктан-ачык күрсәтеп бирелгәннән өстенрәк булганына ишарәли.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Хәбир хәзрәт Ханов,*
*«Ярдәм» мәчете имам-хатыйбы*

*7 август вәгазе,*

*Зөлхиҗҗә аеның 17 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Гаилә әһелләренә гыйлем бирү

Барча мактаулар, хәмде-сәналәр Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә һәм Аның хак хәбибе, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Һәрберегез көтүче һәм һәрберегез үз көтүе өчен җавап бирә», – дип әйткән. Без – гаиләбез әһелләре өчен җавап тотачак кешеләр. Безнең өстә гаиләбезне тәэмин итү: ашатып-эчертү, киендерү генә түгел, ә ике дөнья бәхетенә ирешүдә ярдәм итү бурычы да салынган. Шуңа да гаилә әһелләребезгә гыйлем бирү, балаларыбызга динебез Исламны: Коръәнне, сөннәтне өйрәтү мөһим. Бу мәсьәләләргә җитди карасак иде.

Бала күңеле ак кәгазь кебек. Ул ак кәгазьне матур, мәгънәле бизәкләр, язулар белән баетыйк, чөнки нәкъ менә кечкенә вакытта өйрәнгәннәр хәтергә ныграк сеңеп кала. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм юкка гына, 7 яшь тулу белән үк балаларыгызны намазга бастырыгыз, дип әйтмәгән. Бу зур эшләрне кичектереп, соңрак үзебез үк үкенмәсәк иде. Шау-шулы, ыгы-зыгылы, мәшәкатьле дөньяда гаилә әһелләребезгә дини гыйлем бирүгә вакыт табыйк, хөрмәтле мөселман кардәшләребез!

Әйе, бәлки динне чит кешегә өйрәтү күпкә җиңелрәктер. Башкаларны өйрәткәндә, аларга нәсыйхәт биргәндә без дулкынланмыйбыз, аларга әйткәннәребез ошау-ошамау турында борчылмыйбыз, үз фикерләребезне ирекле рәвештә әйтәбез, чөнки бу кешеләр безне шәхсән белмиләр, алар безнең белән яшәми, безне көнкүрештә күрми. Ә менә үз йортыбызда, гаиләбездә, туганнарыбыз, дусларыбыз, күршеләребез янында эшләр

башкачарак. Без сүзләребезне сайлап кына кулланабыз, аларга нәсыйхәт биргәндә ялгыш кына үпкәләтүдән, артык сүз әйтүдән куркабыз. Моңа өстәп, әлеге кешеләр безне бик яхшы белгәнгә күрә, әңгәмә вакытында безнең элеккеге хаталарыбызны искә төшереп, безне уңайсыз хәлдә калдыруларын уйлыбыз. Әлбәттә, болар барысы да бездән якыннарыбызга нәсыйхәт, гыйлем биргәндә тагын да игътибарлы булуыбызны таләп итә.

Изге Коръәни Кәримебездә китерелгән хикмәтле кыйссалар безне уйланырга мәҗбүр итә. «Мәрьям» сүрәсендә Ибраһим галәйһиссәламнең потлар ясаучы әтисе белән әңгәмәсе бәян ителгән:

إِذْ قَالَ لِأَبِيهِ يَا أَبَتِ لِمَ تَعْبُدُ مَا لَا يَسْمَعُ وَلَا يُبْصِرُ وَلَا يُغْنِي عَنكَ شَيْئًا ﴿٤٢﴾

**«Менә ул атасына әйтте: «И, әтием! Ни өчен (ялваруларыңны) ишетмәгән, (үзләренә баш июләреңне) күрмәгән һәм сине бернәрсәдән дә коткара алмаган нәрсәләргә табынасың?»**

«Мәрьям», 19:42

Күпме хөрмәт, ярату, якын итү, борчылу салынган әлеге сүзләргә! Без якыннарыбыз белән нәкъ менә шул рәвешле аралашырга тиеш. Аларны дингә чакырганда сабыр һәм хикмәтле булу кирәк. Кул селтәп, йөзне бору бик җиңел. Ә менә максатыңа ирешү күп тырышлык, көч куюлар таләп итә. Шушы ук сүрәдә Исмәгыйль галәйһиссәлам хакында искә алына.

وَكَانَ يَأْمُرُ أَهْلَهُ بِالصَّلَاةِ وَالزَّكَاةِ وَكَانَ عِندَ رَبِّهِ مَرْضِيًّا ﴿٥٥﴾

**«Ул халкына намазны һәм зәкятне әмер итә иде. Раббысы аңардан разый иде».**

«Мәрьям», 19:55

«Иде» сүзе кабатланып килә торган гамәлне белдерә. Димәк, ул бу нәсыйхәтләрне иртән дә, кичен дә әйтә торган булган, озак вакытлар

исләренә төшереп яшәгән. Без исә бик тиз үпкәлибез, тиз арада нәтиҗәләр булуын көтәбез. Хатабыз да шунда. Әмма күз алдыбызга китереп карыйк әле: әгәр дә без куйган максатыбызга ирешсәк, нинди зур эш башкарган булабыз. Гаиләбез, якыннарыбыз белән бер юлдан бару зур бәхет бит. Моны башкарып чыккан очракта гаилә әһелләребез белән бер-беребезне бер сүздән аңлап, үзара тагын да дус-тату мөнәсәбәттә яшәячәкбез, иншәАллаһ. Әлбәттә, бу дөньяда бер юлдан барган, бер юнәлештә хәрәкәт иткән кешеләр Аллаһының рәхмәте белән Ахирәт көнендә дә бергә булырлар дигән өмет зур. Коръәни Кәримдә болай дип әйтелгән:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا قُوا أَنفُسَكُمْ وَأَهْلِيكُمْ نَارًا وَقُودُهَا النَّاسُ وَالْحِجَارَةُ عَلَيْهَا مَلَائِكَةٌ غِلَاظٌ شِدَادٌ لَّا يَعْصُونَ اللَّهَ مَا أَمَرَهُمْ وَيَفْعَلُونَ مَا يُؤْمَرُونَ ﴿٦﴾

**«И, иман китерүчеләр! (Әмерләрне тотып, тыюлардан тыелып) Үз-үзләрегезне һәм гаиләләрегезне уттан саклагыз, (башка утларның ягулыгы утын булса) аның ягулыгы (кяфер) кешеләр һәм (бик тиз кабынып, бик күп яндыра торган күкерт) ташлар. Аның өстендә каты табигатьле һәм көчле фәрештәләр бар. Алар үзләренә әмер ителгән нәрсәләрдә Аллаһыга каршы төшмиләр һәм әмер ителгәнне үтиләр».**

«Тәхрим / Тыю», 66:6

Шуның өчен бу мәсьәләләргә җитди карасак иде, җәмәгать.

Әлбәттә, без – бу гамәлләрдә сәбәпче генә. Күңелләргә салучы, йөрәкләрне йомшартучы, хакыйкатьне танытучы – Аллаһы.

Әмма без гаилә әһелләребез белән бергәлектә намазлар укырга, аларга хәдисләр өйрәтергә, белгәннәребез, укыганнарыбыз белән уртаклашырга бурычлы. Ризаэтдин Фәхретдин хәзрәтләре: «Алтыннан кыйммәтле, оҗмах нигъмәтләреннән дә кадерле булган нәрсә – тәрбияле

баладыр», – дип әйткән. Шулай ук аның: «Бала чакта алынган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас», – дигән гыйбарәсе билгеле.

Аллаһы Тәгалә белгәннәребез белән гамәл кылып, гаиләбезгә, якыннарыбызга, әйләнә-тирәдәгеләребезгә үрнәк булып яшәүләребезне һәм изге ниятләребез белән динебез Исламны бары күркәм яктан күрсәтә алуларыбызны насыйп итсә иде. Үзебездән соң да догачы, ихлас, тәкъва балалар калдырып, алар да үз балаларына бездән алган тәрбияне ирештерә алсалар иде.

رَبِّ اجْعَلْنِي مُقِيمَ الصَّلَاةِ وَمِن ذُرِّيَّتِي ۚ رَبَّنَا وَتَقَبَّلْ دُعَاءِ ﴿٤٠﴾

**«И, Раббым! Мине намаз үтәүче һәм минем нәселемне дә (намаз әһеленнән кыл). И, Раббыбыз! Догамны кабул әйлә».**

«Ибраһим», 14:40

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*
*«Саләх» мәчете имам-хатыйбы*

*14 август вәгазе,*

*Зөлхиҗҗә аеның 24 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Мөхәррам ае фазыйләтләре

Барча галәмнәрне юктан бар кылып, тәрбияләп торучы Аллаһы Тәгаләгә мактауларыбыз булсын. Галәмнәргә рәхмәт итеп җибәрелгән, динне аңлаткан, өйрәткән, үрнәк булып яшәп күрсәткән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түребездән чыккан салават-шәрифләребез ирешсен. Аллаһы Тәгалә изге җомга көнендә мәчеткә килеп кылган гыйбадәтләребезне кабул кылсын, атлап килгән һәрбер адымнарыбыз өчен әҗер-савапларын насыйп итсен. Ниндидер җитди сәбәпләр килеп чыгу аркасында гына килеп җитә алмаган мөселман кардәшләребезгә күңелләрендә булган изге ниятләренә, омтылышларына карап әҗер савапларын бирсен. Аллаһы Тәгалә безгә вәгазьләнеп, дөнья өчен, Ахирәт өчен файдалы сүз, файдалы фикер аңларга һәрбарчабызга насыйп кылсын.

Мөселман календареның беренче ае булган мөхәррам ае җитү белән яңа ел башлана. Быел, мөхәррам ае керү белән, һиҗри буенча 1442 ел башланып китә. Ислам барлыкка килгән чорда мөселманнарның үз календаре юк иде, бу шактый мәшәкатьләр тудырды. Хатларны, документларны, мәҗлесләрне (җыелышларны) теркәргә кирәк иде. Хәлифә Гомәр радыяллаһу ганһе шундый мөһим мәсьәләне игътибарсыз калдырмаган. Ул танылган сәхабәләр шурасын җыеп, ел хисабы мәсьәләсен исләренә төшергән. Теләсә кайсы календарьның башлангыч датасы бар. Гадәттә, ул аерым, истәлекле вакыйгага туры килә. Мәсәлән, григориан календаре Гайсәнең туган көненнән башлана.

Катнашучыларның берсе Рум календареннан, ә кемдер фарсы календареннан файдаланырга тәкъдим иткән. Шура әгъзалары ел

исәбен Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең туган елыннан башларга кушкан. Кайберәүләр беренче ел итеп пәйгамбәрлек башланган елны алырга киңәш иткәннәр. Бу тәкъдим кире кагыла, чөнки ул вакытта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән башка әле җир йөзендә мөселманнар юк иде. Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм вафат булган елны сайларга дип әйтүче була. Бу кайгылы елдан башлау дөрес булмас, диләр. Бу тәкъдимнәр кире кагылып, Гомәр бине Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе барлык фикерләрне тыңлаганнан соң, Гали бине Әби Талиб тәкъдиме кабул ителә. Ул ел хисабын һиҗрәт, ягъни Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мәккәдән Мәдинәгә күчү вакыйгасыннан башларга, дигән сүз әйтә. Шул елдан яңа елны саный башларга дигән бер фикергә киләләр, чөнки нәкъ менә һиҗрәттән соң дин тотучылар тормышында яңа этап башлана, нурлы Мәдинәдә кечкенә булса да, беренче ислам дәүләте барлыкка килә, дөньяда беренче мәчет төзелә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мәккәдән Мәдинәгә күчү вакыйгасында безнең өчен зур сабак бар. Монда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дөньяда сәбәбен кылып, уйлап эшләргә өйрәтә. Ул, беренчедән, Аллаһы Тәгаләгә таянса, икенчедән, сәбәпкә дә нык тотына. Расүлебез Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе белән Мәдинә ягына түгел, ә кире якка барып, өч көн тау куышында тора. Әбү Бәкернең улы Габдулла Мәккәдәге хәбәрләрне аларга килеп сөйләп тора, кызы Әсма ашарга алып килә. Сарыклар көтүчесе сарыклар белән таптатып аларның эзләрен югалта.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә дә сәбәбен кыларга әмер итә. Мәсәлән, Мәрьям анабыз Гайсә галәйһиссәламне тудыргач, аңа Аллаһы Тәгалә хөрмә (финик) агачын селкет, хөрмә җимешләре коелыр, шул җимешләрне ашап, сиңа хәл керер, дип әйтә. Әлбәттә, әле бала тапкан хәлсез хатын-кызның таза, нык хөрмә агачын селкетергә көче дә җитми, аны көчле ир

кеше дә селкетә алмый, бәлки ул агачка тотынып кына торгандыр. Аллаһы Тәгалә Кодрәтле, Ул болай да хөрмә җимешләрен төшерә алыр иде, ләкин монда Аллаһы Тәгалә үзеңнән торган сәбәбен кыларга куша.

Муса галәйһиссәлам белән булган вакыйганы беләбез. Ул иманлы кешеләр белән бергә фиргавен гаскәреннән кача һәм диңгез ярына килеп җитә. Шунда Аллаһы Тәгалә аңа таягы белән диңгезгә сугарга куша, Муса галәйһиссәлам шулай эшләгәч, диңгез суы икегә ачыла, алар шул ачылган коры җирдән икенче ярга чыгып котылалар. Диңгез суы таяк белән суккан өчен ачылдымы? Юк! Аллаһы әмер иткәнгә ачылды. Аллаһы Тәгалә таяк белән сукмыйча да диңгез суын икегә ача аламы? Ала, ләкин монда да үзеңнән торганын эшлә, таяк белән булса да сук дип әмер бирә. Ахырзаман алдыннан Гайсә галәйһиссәламне Аллаһы Тәгалә җиргә төшерәчәк, ул, мәчет түбәсенә төшкәч, җиргә төшәр өчен, баскыч сорар. Син әллә кайлардан төштең, моннан төшә алмыйсыңмы дип сорагач, Гайсә галәйһиссәлам: «Анда әмер дөньясы, монда сәбәп дөньясы, биредә баскыч кирәк, сәбәбен кыларга кирәк», – дип җавап бирер. Ләкин сәбәпкә генә таянып, Аллаһыга тәвәккәл кылмасак дөрес булмас. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бөтен сәбәпләрен кылса да, бер бик оста эзтабар тау куышына Расүлебезне эзләүчеләрне алып килә. Шунда ул: «Яки Мөхәммәд бу тау куышында яки моннан күккә күтәрелгән», – дип әйтә. Әмма Аллаһы Тәгалә соңгы ноктаны куючы, Ул аларга аска иелеп карарга ирек бирми. Алар Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне күрсәләр дә, аны тота алмыйлар. Ягъни никадәр генә сәбәбен кылсаң да, Аллаһы теләмәсә, син теләгән нәтиҗә килеп чыкмый. Шуңа сәбәбен дә кыларга, Аллаһыга да тәвәккәл итәргә кирәк, шул вакытта гына яхшы нәтиҗә булачак.

Шулай ук беренче сәхабәләрнең һиҗрәте һәрберебез өчен ныклык һәм какшамаслык үрнәк булып тора. Күп кенә сәхабәләр, Аллаһы ризалыгы

өчен, туган-тумачаларын, өйләрен, байлыкларын калдырып, алар өчен чит-ят булган башка җиргә – Мәдинәгә күченделәр.

Шулай итеп Гомәр радыяллаһу ганһенең идарәсе вакытында мөселман ел хисабын билгеләү барлыкка килде. Анда ел исәбе һиҗрәт кылынудан, ягъни Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мәккәдән Мәдинәгә күченү вакытыннан башлап алып барылды.

Хәдистә әйтелгәнчә: «Ел 12 айдан тора, аларның дүртесе тыелган, өчесе чиратлашып килә: зөлкагъдә, зөлхиҗҗә һәм мөхәррам, ә (дүртенче ай) раҗәб ае җөмәдәл-ахыр белән шәгъбан арасында».

Аллаһы хикмәт Иясе, Ул Үзе теләгән вакытны һәм урынны олылый. Бу айларда кылган эшләр өчен гөнаһ, һәм савабы арттырып бирелә. Гөнаһ кылу теләсә кайсы айларда зур гөнаһ булса да, бу дүрт айда гөнаһ дәрәҗәсе тагын да арта.

Аллаһы Үзе теләгән нәрсәне бөек кылыр. Ул фәрештәләрне түгел, ә пәйгамбәрләрне зурлады. Кеше сөйләменнән Аллаһыны зикер итүне өстен кылды.

Җирдәге урыннардан иң яхшы урыннар булып мәчетләр санала. Аллаһы Тәгалә айлар арасыннан Рамазан һәм мөхәррам айларын сайлады. Аның өчен иң яхшы көн – җомга көне, төннәрнең иң өстене – Кадер кичәсе.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы Тәгалә өчен Рамазан аенда ураза тотканнан соң иң лаеклысы – мөхәррам ае», – дип әйткән. Монда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөхәррам аеның өстенлеген билгеләп китә.

Шулай ук хәдисләрдә Гашурә көнендә ураза тотуның саваплары турында да әйтелә. Ибне Габбас радыяллаһу ганһедән болай дип тапшырылган: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәдинәгә килгәч яһүдләрнең Гашурә көнендә ураза тотуларын күрде. Ул: «Нигә сез ураза тотасыз?» – дип сорады. Алар: «Бу мактаулы көн, бу көнне

Аллаһы Исраил улларын дошманнарыннан коткарган, шунлыктан Муса галәйһиссәлам бу көнне ураза тоткан», – дип җавап бирделәр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Без Мусага сезгә караганда күбрәк лаеклырак», – дип әйтеп, бу көнне ураза тоткан һәм безгә дә әлеге көнне уразада үткәрергә кушкан.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Мин Гашурә көнендәге уразаны Аллаһы бер еллык гөнаһларга кәффарәт буларак кабул итәр дип ышанам». Бу – Аллаһы Тәгаләнең юмартлыгы. Бер көн дәвамында ураза тоту бер еллык гөнаһлар кичерелүгә сәбәп була.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе: «Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөхәррамның унысында, Гашурә көнендә безгә ураза тотарга боерды», – дип әйткән.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе Расүлебезнең әлеге сүзләрен риваять итә: «Аллаһы Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм Гашурә көнендә ураза тотып, барлык мөселманнарга да ураза тотарга кушканнан соң, алар: Әй, Аллаһының Расүле, бу – яһүд һәм насараларның искә алу көнедер», – дип әйттеләр. Аллаһы Расүле болай дип җавап бирде: « Әгәр мин икенче елда да исән-сау булсам, иншәАллаһ, без шулай ук унынчы көндә дә ураза тотарбыз». Ләкин, Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм киләсе ел җиткәнче вафат булды.

Иң хәерлесе – рәттән өч көн ураза тоту. Ул мөхәррам аеның 9 нчы, 10 нчы һәм 11 нче көннәрендәге ураза.

Аллаһы Тәгалә кылган изгелекләребезне кабул кылсын, шуларның файдаларын дөньяда һәм Ахирәттә күрергә, җәннәтләрдә бер-берләребезне күреп сөенергә, шатланырга насыйп әйләсен.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рифат хәзрәт Ибраһимов,*
*Кукмара районының Зур Сәрдек авылы имам-хатыйбы,*
*Кукмара мәдрәсәсе мөгаллиме*

*21 август вәгазе,*

*Мөхәррам аеның 2 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Тел – Аллаһының нигъмәте

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн, әммә бәгъд: барча мактауларыбыз галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһы Тәгаләгә һәм дә салават-шәрифләребез Аның хәбибе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә булса иде.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, без даими рәвештә Аллаһы Тәгаләгә хәмед-сәналәребезне әйтәбез. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, Аның сөекле илчесе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифләребезне җиткерәбез.

Аллаһы Тәгалә кешеләрдән иң беренче булып Адәм галәйһиссәламне яратты:

فَتَلَقَّىٰٓ آدَمُ مِن رَّبِّهِۦ كَلِمَاتٍ فَتَابَ عَلَيْهِ ۚ إِنَّهُۥ هُوَ التَّوَّابُ الرَّحِيمُ ﴿٣٧﴾

**«Адәм Раббысыннан [берникадәр] сүз өйрәнеп, кабул итеп алды [һәм шул сүзләр белән Раббысына ялвара башлады], Ул аның тәүбәсен кабул итте. Һичшиксез, Ул – Тәүбәләрне кабул итүче, Рәхимле».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:37

Һәм Раббыбыз Адәм галәйһиссәламгә зур дәрәҗәләр бирде:

وَلَقَدْ خَلَقْنَاكُمْ ثُمَّ صَوَّرْنَاكُمْ ثُمَّ قُلْنَا لِلْمَلَائِكَةِ اسْجُدُوا لِآدَمَ فَسَجَدُوا إِلَّا إِبْلِيسَ لَمْ يَكُن مِّنَ السَّاجِدِينَ ﴿١١﴾

**«Һичшиксез, без сезне [атагыз Адәмне бер балчыктан] яраттык, аннары сезне [атагызны] шәкелләндердек, аннары фәрештәләргә: «Адәмгә сәҗдә кылыгыз», – дидек, алар исә сәҗдәгә киттеләр, Иблис кенә сәҗдә кылучылардан булмады».**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:11

Раббыбыз Адәм галәйһиссәламгә җан өргәннән соң, аның кабыргасыннан Хавва анабызны яратты. Соңрак аларның балалары туды. Һәм алар Җир шары буенча таралды. Адәм балаларының саны артты. Һәм Аллаһы Тәгалә аларны төрле-төрле милләт итте. Ягъни кешеләрнең төрле милләттә булулары, төрле телләрдә сөйләшүләре, тән төсләренең төрлелеге, төрле язмышка дучар булуы – болар барысы да Аллаһы Тәгаләдән. Кешеләр үзләре телләр уйлап чыгармаган, кавемнәргә бүленмәгән. Бүген дә, фән нинди генә үсеш кичермәсен, бер генә кеше дә кайсы милләт вәкиле булып туачагын хәл итә алмый. Аллаһы Тәгалә әмере белән теге яки бу ата белән анадан билгеле бер милләт баласы булып туабыз.

Шуңа күрә безгә үзебезнең милләтебезнең телен, гореф-гадәтләрен белү мәҗбүри. Бу гамәл диндә вәҗиб гамәл дәрәҗәсендә йөри. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Әгәр дә шушы җирлектәге халыкның гореф-гадәтләре дингә каршы чыкмаса, ягъни ширеккә китермәсә, бу гадәтләр – ислам гадәте», – дип әйткән. Шуңа күрә күп кенә ислам галимнәре туган телне белүне вәҗиб гамәл дип карый. Телне белмәү – зур хилафлык. Аллаһы Тәгалә безгә туган телебезне белергә насыйп итсен иде.

Раббыбыз Үзе «Хөҗерат» сүрәсендә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ إِنَّا خَلَقْنَاكُم مِّن ذَكَرٍ وَأُنثَىٰ وَجَعَلْنَاكُمْ شُعُوبًا وَقَبَائِلَ لِتَعَارَفُوا ۚ إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِندَ اللَّهِ أَتْقَاكُمْ ۚ إِنَّ اللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ ﴿١٣﴾

**«И, кешеләр! Һичшиксез, Без сезне [Адәм исемле] бер ирдән һәм [Хәвва исемле] бер хатыннан яраттык. [Һәммәгезнең дә ата-анасы бер булганга күрә, нәсел-чыгыш белән мактануның ни мәгънәсе бар?] Без сезне, [бер-берегезгә уйламый-нитми теләсә ни сөйләр өчен түгел] танышуыгыз өчен, кавемнәр һәм кабиләләр иттек. Аллаһы хозурында иң кадерлегез – [иң асыл нәселдән булганнарыгыз түгел, Аллаһы Тәгаләнең харамнарыннан сакланган] бик тә тәкъвалык иясе булганыгыз. Һичшиксез, Аллаһы – [һәрнәрсәне] Белүче, [һәрнәрсәдән] Хәбәрдар».**

«Хөҗерат / Бүлмәләр», 49:13

Моны дөрес аңлау бик мөһим. Раббыбыз тарафыннан безнең төрле милләт вәкилләре булып яратылуыбыз шуның белән масаю, башка милләтләрне кимсетү, хурлау өчен түгел. Үз тамырларыбызны белү, тарихта булган хаталарны кабатламау, шушы җирлектәге халыкларның казанышларын тагын да үстерү өчен кирәк. Бүген Татарстаныбыз биләгән җирлектә инде мең елдан артык Ислам динен тоталар икән, безнең бу чынбарлыкны инкяр итәргә, аннан качарга хакыбыз юк.

Онытмыйк: халкыбыз Совет чорында озак вакыт динсезлектә яшәгән. Бүген менә шул вакыттагы вәзгыятьне безгә үрнәк итеп куючылар, безнең әби-бабайлар алай эшләми иде, бу безнең гадәт түгел, дип дәлил китерүчеләр бар. Мондый очракта ничек җавап бирергә? Чыннан да, ул вакытта бала булган кешеләр бүген әби-бабай дәрәҗәсендә йөриләр. Бер караганда, алар динле, намазлы, уразалы булырга тиеш. Ләкин күп очракта бу алай түгел. Һәм алар, үзләрен аклар өчен, безнең әби-бабайлар алай итмиләр иде, бу безгә читтән, гарәптән, төректән һ.б. кертелгән йолалар

дип әйтәләр. Ни өчен шулай килеп чыккан? Чөнки, беренчедән, ул вакытта илдә динсезлек чоры иде. Анда чыннан да халык диннән ерак иде. Башка идеяләр белән яшәде. Икенчедән, намаз укыса да, садака бирсә дә, әби-бабайлар ул вакытта аны яшерен эшләргә тырыштылар. Күрсәтмичә, ишекне ябып, бу турыда ачыктан-ачык белгертми генә, чөнки вакыты шундый булган. Без шуңа күрә ул чорны аерып карыйк. Совет чорында диннең хәле бик авыр булган. Алай да әби-бабаларыбызның күбесе динен дә, милләтен дә сатмаган, ислам дине йолалаларын кулларыннан килгәнчә саклап калырга тырышкан. Аларның рухлары шат булсын, Аллаһы Тәгалә урыннарын җәннәттә итсен иде.

Совет чорында безгә бик күп чит гадәтләр кергән. Милләтләр, халыклар бик буталышканнар, катнаш гаиләләр күп булган. «Милләт» төшенчәсен юк итәргә тырышканнар. Мондый шартларда динне дә, милләтне дә саклап калу бик авыр булган.

Әмма Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә Ислам динен Кыямәт көненә кадәр сакларга Үзе вәгъдә бирә. Шуңа күрә дин ул Ахырзаманга кадәр бетмәс. Ә милләт мәсьәләсендә болай дип әйтеп булмый. Ул бетәргә, юкка чыгарга мөмкин. Дөнья тарихында атамалары гына сакланып калган кавемнәр аз булганмы?! Әле исемнәре безнең чорга кадәр килеп җитмәгәннәре күпме?! Аллаһы Тәгалә бу хакта ачыктан-ачык болай дип әйтә:

وَرَبُّكَ الْغَنِيُّ ذُو الرَّحْمَةِ ۚ إِن يَشَأْ يُذْهِبْكُمْ وَيَسْتَخْلِفْ مِن بَعْدِكُم مَّا يَشَاءُ كَمَا أَنشَأَكُم مِّن ذُرِّيَّةِ قَوْمٍ آخَرِينَ ﴿١٣٣﴾

**«Синең Раббың – Бай [беркемнең дә ярдәменә Мохтаҗ булмаучы] һәм [дини вазифаларына игътибарлы булмауларына карамастан, колларына тәүбәгә килергә вакыт биргән] Рәхмәт иясе. [И, залимнәр һәм баш күтәрүчеләр!] Әгәр Ул теләсә, сезне юк итәр һәм, сезне [Нух галәйһиссәламнең көймәсендә котылуга**

**ирешкән] башка бер җәмәгатьнең нәселеннән чыгарганы кебек, артыгыздан сезнең урынга теләгәннәрен [итагатьле колларын] куяр».**

«Әнгәм / Терлек», 6:133

Үзегез дә игътибар иткәнегез бардыр. Совет чорындагы фотоларны карасак, анда мәчетләрдә – гел татар йөзләре. Ә хәзер мәчетләребездә татарларның саны кими. Башка халык вәкилләре күбрәк. Дин ул милләтсез дә яшәр, югалмас. Ә менә милләт динсез югалыр. Бигрәк тә безнең татар милләтендә телне дә, гореф гадәтләрне дә гомер-гомергә дин саклап килгән.

Шуңа күрә эшләргә кирәкле эшләр әле бик күп. Иң беренче чиратта, динне милләттән аеруны туктатсак иде. Дин аерым, милләт аерым дип, ялгышмасак иде. Инкыйлабка кадәрге вакытны искә төшерик. Милләтнең йөзек кашы булган бөтен татар байлары, галимнәре – дини кешеләр булганнар. Мәчетләр салганнар, мәдрәсәләр тотканнар. Бүген бу матур традицияне кайтару кирәк. Фән кешесе дә, эшкуар да, эшче дә – барысы да милләтен дә сөйсен, динен дә онытмасын.

Әле кайчан гына «глобальләшү» сүзеннән сискәнеп китә идек. Инде аңа да ияләштек. Бүген диндә глобальләшү күбрәк икътисад белән бәйле. Чикләр ачылгач, мөмкинлекләр арткач, без хәзер гарәптән, төректән килгән күлмәкләр, яулыклар сатып алабыз, китаплар укыйбыз, чит илләргә йөрибез. Элек бит болар берсе дә булмаган. «Безнең әбиләр мондый яулык япмаган, мондый күлмәк кимәгән», – дигән сүз шуннан да чыга. Ул вакытта андый мөмкинлекләре булмаган. Әбиләребезнең кешелеккә кия торган матур бер күлмәге, бер яулыгы гына булган. Әйдәгез, бүген дә кызларыбыз, хатыннарыбызның киемнәре арасында шундый милли рухлы, чигелгән яулыклар, күлмәкләр булдырыйк. Моңа бит беркем дә комачауламый. Әгәр дә сорау булса, тәкъдим итүчесе дә табылыр иде.

Милләтебезнең дини гореф-гадәтләре шул киенү әдәбеннән үк башлана. Галәм дәрәҗәсендәге мәсьәләләрдән түгел.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рөстәм хәзрәт Хәйруллин,*

*«Гаилә» мәчете имам-хатыйбы*

*28 август вәгазе,*

*Мөхәррам аеның 9 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Гашурә көне

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән нигъмәтләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең Хәбибе һәм Хак расүле, галәмнәргә рәхмәт булarak җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен, мәчетебезгә җыелган, мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләму галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Ислам тәкъвименең беренче ае – мөхәррам аедыр. Гашурә көне харам булган дүрт айларның берсе – мөхәррам аеның 10 нчы көне.

إِنَّ عِدَّةَ الشُّهُورِ عِندَ اللَّهِ اثْنَا عَشَرَ شَهْرًا فِي كِتَابِ اللَّهِ يَوْمَ خَلَقَ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ مِنْهَا أَرْبَعَةٌ حُرُمٌ ۚ ذَٰلِكَ الدِّينُ الْقَيِّمُ ۚ ﴿٣٦﴾

**«Аллаһы хозурындагы китапта айлар саны унике, җирне һәм күкләрне яраткан көннән бирле, ул унике айдан дүртесе сугышка харам булган айлар: ягъни раҗәб, зөлкагъдә, зөлхиҗҗә, мөхәррам айлары. Ошбу хөкемнәр туры дин».**

«Тәүбә», 9:36

Гарәп теленнән «Гашурә» дигән сүз «унынчы» дип тәрҗемә ителә. Ул быел 28 нче август көненең ахшам намазыннан соң башланып, икенче 29 нчы август көненә туры килә.

Бу көннең тарихи үзенчәлеген, аның мөселманнар өчен ни дәрәҗәдә югары көн икәнен барыбыз да аңлыйбыз, беләбез. Бу көн – пәйгамбәрләр тарихында да үз урынын алган көн. Бүгенге көндә календарьга күз салсак, әллә ничә көннәрнең кызыл белән билгеләнеп куелганнарын күрербез. Гомумән, интернетны ачып карасаң, ике көннең берендә нинди дә булса профессия әһелләре көне, яки берәр төрле күренеш, хәтта ки предмет көннәре дә бар.

Без, мөселманнарның да, үз көннәребез бар, алар – дини бәйрәмнәребез белән бәйле көннәр. Әлбәттә, аларның да үз тарихлары бар. Гашурә көнендә күп гасырлар элек бер зур вакыйга, Аллаһы Тәгаләнең могҗизасы була. Муса галәйһиссәлам үзенең халкы белән артыннан куа килгән гаскәрдән качкан. Ул гаскәрнең башлыгы фиргавен була. Аллаһы Тәгалә Муса галәйһиссәлам халкына диңгездә юл яра, диңгез суы икегә бүленеп, коридор барлыкка килә, ә диңгез төбендәге җир коры була. Бу могҗизаны күрсә дә, үзенең имансызлыгы белән сукырайган фиргавен барыбер шушы коридорга керә. Муса үз халкы белән икенче ярга җитүгә, Аллаһы Тәгалә диңгезне кире куша һәм фиргавен үз гаскәре белән су астында кала. Бу бәладән котылу хөрмәтенә Муса шул көнне ураза тота башлый, аның халкы да аңа иярә. Ибне Габбас радыяллаһу ганһе мондый хәдис тапшыра: «Пәйгамбәребез Мәдинә шәһәренә һиҗрәт кылганнан соң, шушы шәһәрдә яшәгән яһүдиләрнең Гашурәдә ураза тотканнарын күрде. Ул алардан: Нәрсә бу?» – дип сорады. Яһүдиләр: «Бу көнне Аллаһы Тәгалә пәйгамбәребез Мусаны фиргавеннән һәм аның гаскәреннән коткарган. Муса да бу көнне ураза тоткан», – дип җавап кайтардылар. Пәйгамбәребез аларга: «Муса пәйгамбәргә карата минем хокукым беренчедер…(мин лаеклырак)», – дип җавап бирде һәм үзе дә уразага ке-

реп, калганнарга да бу уразаны тотарга кушты», – дип әйткән расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үрнәк итеп шушы көнне ураза-да булган. Ул үзенең өммәтен, мөэмин-мөселманнарны, ягъни безне дә бу көндә ураза тотарга өндәгән.

Бу көндә ураза тотуның фазыйләте турында түбәндәге хәдистә дә әйтелә: «Ул үткән ел гөнаһларына түләү булып тора»[1]. Бу көнне төннең кайсыдыр өлешен намазда үткәрергә, гыйбадәттә булырга кирәк. Пәйгамбәребезнең тагын бер хәдисендә болай дип әйтелә: «Рамазан аеннан соң иң яхшы ай – мөхәррам ае; мәҗбүри (биш вакыт фарыз) намаздан һәм төнге намаздан соң, ягъни тәһәҗҗөд намазыннан соң иң яхшысы – Гашурә көнендә укылган намаз»[2]. Бу көнне шулай ук якыннарына садака бирергә дә була. Пәйгамбәребезнең бер хәдисендә әйтелгәнчә: «Гашурә көнендә үз гаиләсенә юмарт булган кешегә Аллаһы Тәгалә башка елларны да мул һәм хәерле итәр».

Һәр гыйбадәтнең әҗер-савабы булган кебек, бу көндә тоткан уразаның да әҗере бар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән Гашурә уразасы турында сорагач, ул: «Ул узган елгы гөнаһларның кичерелүенә сәбәп була», – дип әйткән. Ягъни бер еллык гөнаһ бит ул, кадерле җәмәгать. Аллаһы Тәгалә – «Әр-Рахмән», «Әр-Рахим», ягъни Иң Мәрхәмәтле, Иң Шәфкатьле. Үзенең колларына нинди бүләкләр, нигъмәтләр биргән. Шуңа да бу көнне һәм шуңа охшаш калган көннәрне дә гафләт чире белән үткәрмәсәк иде, аларның фазыйләтен аңлап, гамәл-гыйбадәттә үткәрергә насыйп булса иде.

Сәхабәләр бу көннәрне әҗер-саваплар эшләп калырга, гөнаһлардан арынырга бер форсат дип кабул иткәннәр. Хәтта балаларын да бу көндә ураза тоттырганнар. Алар балаларына буялган йоннан уенчыклар ясый торган булганнар. Әгәр берәрсенең карыны ачып, елый башласа, балалар-

1 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

га ифтарга кадәр шушы уенчыкларны биреп, ифтарга кадәр ашау турында оныттыра торган булганнар.

Нинди көндә ураза тотасы? Имам Әхмәд рахмәтуллаһи галәйһинең хәдисләр җыентыгында мондый хәдис китерелә: «Гашурә көнендә ураза тотыгыз. Бу эшегездә яһүдиләргә каршы булып, я бер көн алдан, я бер көн арттан уразага өстәгез».

Әлеге хәдисләрдән чыгып, шуны әйтергә була: Гашурә уразасын ике көн тоту хәерлерәк. Иң яхшы ураза булып тугызы һәм унысы тоткан ураза булачак.

Гашурә – бәйрәм көне. «Ислам дине нигезләре» дигән китапта моның турында түбәндәгеләр язылган:

«Гашурә көнендә шактый күп бик әһәмиятле, тарихи, сөенечле вакыйгалар булган. Шуларның аеруча мөһим булганнары Аллаһының пәйгамбәрләре белән бәйледер. Бу көнне Бөек Раббыбыз бу дөньяны, Адәмне яраткан, нәкъ бу көнне Адәм тәүбәсе кабул ителгән; Нух көймәсе тауга килеп җитеп, андагы мөэминнәр туфаннан котылган; бу көнне Ибраһим галәйһиссәлам туган һәм мәҗүсиләрнең учагыннан коткарылган, Гайсә һәм Идрис галәйһиссәламнәр күккә ашкан; Муса галәйһиссәлам һәм аңа ияргәннәр фиргавеннең эзәрлекләвеннән котылганнар, фиргавенне шул көнне диңгез сулары йоткан; Юныс галәйһиссәлам балык карыныннан исән-имин чыгып котылган; Әюб галәйһиссәлам авыр чирдән савыккан; озак елларга сузылган аерылышудан соң Ягъкуб галәйһиссәлам улы Йосыф галәйһиссәлам белән очрашкан; Йосыф галәйһиссәлам зинданнан чыккан; Сөләйман галәйһиссәлам патша булган.

Гашурә көнне ураза тоткан кешеләр саваплы булыр. Бер хәдистә әйтелгәнчә, Гашурә көнендә тотылган ураза мөселман кешене узган елда кылган гөнаһларыннан арындыра. Ә Гашурә көнендә бирелгән бер бөртек садака өчен, Аллаһы Тәгалә Өхед тавы кадәрле әҗер-савабын бирә».

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Гашурә уразасын Мәдинәгә күченгәнче үк тота торган булган. Рамазан аенда ураза фарыз булганчы мөселманнар бу көндә уразада булганнар. Әмма Рамазан уразасы фарыз булгач та, мөхәррам аендагы шушы бөек көн уразасы үзенең фазыйләтен югалтмады. Аллаһы Тәгалә безгә һәрберебезгә дә шул фазыйләтләргә ирешергә насыйп әйләсә иде. Әәмин.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*«Хозур» редакциясе*

*4 сентябрь вәгазе,*

*Мөхәррам аеның 16 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Бүгенге көн «сәләфләре» – кемнәр алар?

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә сәйидинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн.

Галәмнәрне һәм анда булган барлык мәхлүкатны бар кылып, тәрбияләп торучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә мактауларыбыз булса иде. Шушы галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, сәхабәләргә һәм Кыяматкәчә аңа ияргән барлык иман иясенә хәер-догаларыбыз һәм дә сәламнәребез ирешсә иде.

Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ! Хөрмәтле мөселман кардәшләрем, шушы җомга көне бәрәкәтендә Аллаһы Раббыбыз атна дәвамында кылган изгелекләребезне кабул итсә иде, киткән хата-кимчелекләребезне гафу кылса иде. Җомга көне мөбарәк булып, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә, мәгъфирәтенә һәм җәннәтенә якынаючылар җөмләсеннән булырга насыйп булса иде.

Хөрмәтле җәмәгать, бу җомга вәгазендә бүгенге көндә кайбер мөселманнар тарафыннан кулланылган «сәләф» сүзенә тукталып китәрбез. «Сәләф» сүзен кулланып кайберәүләр «гакыйдәң дөрес түгел», «мәзһәбләргә иярү вәҗиб түгел», «Әбү Хәнифәгә хәдис килеп ирешмәгән» яки «бу бидгать» – дигән гаепләүләр дә әйтергә мөмкин. Әмма чынлыкта «сәләф» сүзе нәрсәне аңлата соң?

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Өммәтемдәге иң хәерле чор минем чорым, аннан соң алардан соң килүчеләр, ә аннан соң алардан соң килүчеләр...»[1], – дигән. Пәйгамбәребез бу хәдисендә үзенең өммәтендә булган иң хәерле буыннарны искә алган. Имам Нәвәви рахимәһуллаһи бу хәдистә искә алынган беренчесе сәхабәләр, икенчесен табигыйннәр (сәхабәләргә ияргәннәр) һәм өченчесен тәбге-табигыйн (табигыйннәргә ияргәннәр) буыны дип аңлатма биргән[2].

Шушы бәрәкәтле буыннар Пәйгамбәребездә булган гакыйдәне, шәригатьне һәм рухиятне өйрәнү, саклау һәм алга таба тапшыру өчен зур көч түккәннәр. Пәйгамбәребез бер хәдисендә галимнәрне пәйгамбәрләрнең варислары дип атады, «пәйгамбәрләр үзләреннән соң алтын һәм көмеш калдырмаганнар, ләкин алар гыйлем калдырганнар», – дип әйтте. Бу хәдистә дә пәйгамбәрләрдән турыдан-туры мирас итеп алынган гыйлем турында сүз бара. Шушы безнең өммәтнең пәйгамбәрдән алып безгә гыйлем тапшырган беренче өч буын мөселманнарны галимнәр «Сәләфүс-Салих», ягъни «изге борынгы»ларыбыз дип атаганнар. Аллаһы алардан разый булсын.

Бүгенге көндә исә үз-үзләренә «сәләф» билгеләмәсен бирүчеләр хакыйкатькә туры килми, чөнки әйтеп үткәнебезчә, сәләфләр – ул Расүлебездән соң килгән өч буын. Биредә – сәхабәләр, табигыйннар, тәбге-табигыйннар. Моңа хәзрәтебез Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи да һәм калган мәзһәбләрнең галимнәре дә керә. Тик бүгенге көндә үзләрен сәләф диючеләр, чынлыкта, «сәләф»ләр түгел. Үзләрен «сәләф»ләр дип атаучы ваһаббитлар «ялган сәләфләр» булып санала.

Аллаһы Тәгаләдән пәйгамбәр Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә бирелгән гыйлемне өйрәнеп, гамәлдә куллану юлында

1 Имам Бохари (2652), Имам Мөслим (2533) риваятендә.

2 Мөслимгә Имам Нәвәвинең аңлатмасы 16/85.

сәхабәләр зур тырышлык куйганнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән алган шушы әманәтне тапшыру өчен, сәхабәләр дөньяның төрле тарафларына китеп гыйлем таратканнар. Аларның укучылары табигыйннәр заманында шәригатьнең төрле тармаклары, фәннәр барлыкка килгән: тәфсир, хәдис, гакыйдә, фикһ һ.б. кебек. Табигыйннәр дә сәхабәләрдән алган гыйлемнәрен үзләренең укучыларына ягъни тәбгетабигыйннәргә тапшырганнар. Шушы чорда шәригать гыйлемнәре буенча төрле китаплар язылган, төрле гыйльми үзәкләр барлыкка килгән. Мәдинә шәһәре, Куфә һәм Димәшкъ шәһәрләрендәге кебек, һәр төбәкнең үзенең галимнәре булган.

Ислам динендә гыйлем алуга игътибар зур, бигрәк тә остаз каршында алган гыйлем кыйммәтле. Электән пәйгамбәребездән ишеткән хәдисне тапшырганда да кемнән ишеткәнеңне, гыйлем биргәндә дә кемнән алганыңны әйтү кирәк булган. Бу «иҗазә» (рөхсәт, диплом) яки «иснәд» (хәдис гыйлемендәге шәҗәрә, чылбыр, хәдис сөйләүчеләрнең бер-бер артлы килүләре), ягъни гыйлем чылбыры дип атала, шундый белем генә ышанычлы була. Имам Әгъзам Әбү Хәнифә рахимәһуллаһиның да гыйлем чылбыры пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә барып тоташа. Әбү Хәнифәнең төп укытучысы Хәммәд бине Әби Сөләйман, аның остазы Ибраһим бине Язид Ән-Нәһәги, ул Галькамә бине Кайстан гыйлем алган, ә аның остазы пәйгамбәребезнең сәхабәсе Габдулла бине Мәсгуд радыяллаһу ганһе булган. Шулай итеп безнең көннәргә кадәр килеп җиткән хәнәфи мәзһәбенең гыйлем чылбыры да Мөхәммәд пәйгамбәргә барып тоташа. Шундый ныклы юлга тотынып гамәлгыйбадәт кылганда гына, без кылган гыйбадәтләребезнең пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм өйрәткәнчә булуына ныклы ышаныч барлыкка килә.

Гакыйдә мәсьәләләрен аңлар өчен, Имам Тәхави гакыйдәсе китабында әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать галимнәрендә булган матуриди гакыйдәсе

тупланган. Иман мәсьәләләрендә төрле ялгыш карашларга кереп китмәс өчен, шушы китаптан гыйлем алу яки шундый гыйлеме булган остазларга, имамнарга мөрәҗәгать итеп кызыксындырган сорауларга җаваплар табарга мөмкин.

Бүгенге көндә гыйлем алу ысуллары да төрле, китаплар, журналлар, интернет чыганаклар да бик күп. Ләкин мәчеткә яки мәдрәсәгә барып, остаз каршында алган белем хәерле. Аллаһы Тәгалә төрле адашулардан сакласын, галимнәр юлында булырга, файдалы белемнәр алырга насыйп итсен!

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Илһам хәзрәт Мөһтәров,*
*Кукмара мәдрәсәсе мөгаллиме,*
*Аш-Бужи авылы имам ярдәмчесе*

*11 сентябрь вәгазе,*

*Мөхәррам аеның 23 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Туган илне яратып яшәүнең мөһимлеге

Безнең күңелләребезне иман, ислам нуры белән нурландырган Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә чиксез хәмед һәм шөкераналарыбыз, җир йөзенә рәхмәт өчен җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Аллаһы Тәгалә һәркайсыбызга Үзенең чиксез сәламен, киң рәхмәтен һәм бәрәкәтен ирештерсә иде! Мөхтәрәм җәмәгать, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Ике гаеттән олуграк булган изге җомга бәйрәме барчаларыбызга мөбарәк һәм хәерле булсын! Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә илкөннәребезгә, җаннарыбызга тынычлык, тәннәребезгә исәнлек-саулык, күңелләребезгә тәүфыйк-һидаять биреп, һәркайсыбызга хәерле һәм бәрәкәтле тормышлар насыйп итсен иде. Мөкатдәс җомга көнне ихлас күңелдән изге гамәл-гыйбадәтләр кылып, Аллаһы Тәгаләнең иксез-чиксез рәхмәтләренә барчабызга да ирешергә насыйп булсын!

Төзек һәм дөрес җәмгыятьнең нигезен камиллеккә, яхшылыкка омтылган кешеләр тәшкил итә. Һәр кешенең күңелендә туган җирлегенә, туган иленә карата мәхәббәт, аның белән горурлану була. Ниндидер сәбәпләр белән, кеше моны никадәр генә инкяр итәргә тырышса да, күңеле, йөрәге белән моның шулай икәнен таный. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ватанны сөю – иманнан», – диде. Динебез буенча без һәр адәм баласының фитрый иман белән дөньяга туганын беләбез. Иман – ул күңел

белән ышану. Иманлы кеше Аллаһы Тәгаләнең барлыгына, берлегенә, фәрештәләргә, изге китапларга, Аллаһыдан җибәрелгән пәйгамбәрләргә, тәкъдиргә ышана. Кеше никадәр генә үзен фитрый иман халәтеннән аерып карарга, тәкәбберлек белән үзен болардан өстенрәк куярга тырышса да, аның күңел түрендә яхшылыкка, чисталыкка һәм Аллаһының киң кодрәтенә ышану яши. Шуңа да «Ватанны сөю иманнан» дигән хәдистә кеше барыбер туган илен ярата дигән фикер белән беррәттән, мөселман кешесе Ватанын яратырга, аны кайгыртып яшәргә тиеш дигән фикер уза. Бу бик тә мөһим. Чөнки кеше үзенең бүгенге көне белән генә түгел, ә киләчәген кайгыртып яши. Гаиләсе, балалары, оныклары булган кешене бүгенге көннең уңайлыклары, өстенлекләре генә түгел, ә киләчәк тормышның да камил, төзек, дөрес булуы кызыксындыра. Шуңа да ул бу тормышны, җәмгыятьне яхшы якка үзгәртер өчен үз өлешен кертергә омтыла. Барыбыз да белә: канәгатьсезлек күрсәтеп, шөкерсезлек белдереп кенә уңышка ирешеп булмый. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә:

إِنَّ اللَّهَ لَا يُغَيِّرُ مَا بِقَوْمٍ حَتَّىٰ يُغَيِّرُوا مَا بِأَنفُسِهِمْ ۗ

**«Аллаһы бер кавемгә биргән нигъмәтен үзгәртмәс, хәтта ул кавем үз хәлен үзгәрткәнгә чаклы»,** – диелгән.

«Рәгыд / Күк күкрәү», 13:11

Адәм балаларының табигате шундый: алардан үзгәрешләр телисезме, дип сорасаң, алар, әйе, дип җавап кайтара. Ә үзгәрергә телисезме, дип сорасаң, эндәшүче юк, чөнки канәгатьсезлек белдереп, үзгәрешләр таләп итү җиңел, әмма җиң сызганып шул уңай якка үзгәрешләрне булдырырга тырышу бик авыр гамәл.

Галимнәр әйтүенчә, адәм баласы өчен иң авыр гамәл – ул рәхәтлеккә чыдый алмау. Тарихка күз салсак, кешеләр авыр сугыш елларында, үзәккә үткән ачлык, ялангачлык вакытында да көчле авырлыкларны, сынауларны ерып чыга алган. Ә иң мөһиме авырлыклар белән күзгә-күз очрашса

да, кешелек сыйфатларын югалтмаган: ярдәмгә мохтаҗ булганнарга булышып, булганына шөкер итеп яши белгән.

Менә бүгенге заманның төп бәласе шунда да инде, җәмәгать! Бүгенге көндә безгә – халыкка яшәешебез өчен булдырылган уңайлыкларны күрергә теләмәвебездә, ә һаман зарланып, нидер таләп итеп яшәвебездә. Өстебез бөтен, тамагыбыз тук булганда телебез шөкерне күбрәк әйтергә тиеш булса да, киресен эшләп яши бирәбез.

Илләребез, көннәребез тыныч, имин булып торганда, җитеш тормышта яшәгәндә һаман зарланып, ризасызлык белдереп тору мөселман кешесенең эше түгел. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр кеше иртүк сау-сәламәт булып уянса һәм аның ашар ризыгы, кияр киеме булса, ул иң бай кеше инде», – дигән. Менә болар хакында фикер йөртсәк иде, җәмәгать!

Аллаһы Тәгалә һәрберебезнең күңеленә дә туры юлны – һидаять салып, бу тормышта җәмгыятебез өчен дә, кешеләр өчен дә файдалы булып яшәүләребезне насыйп итсен иде. Ил-көннәребезгә тынычлык, иминлек биреп, һәр яңа туган көнебезгә шөкер әйтеп, Аллаһының нигъмәтләрен күреп яши белсәк иде.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*«Хозур» редакциясе*

*18 сентябрь вәгазе,*

*Сафәр аеның 1 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Яшьләр мохитендә экстремизм

Галәмнәрне юктан бар итүче Аллаһы Раббыбызга дан вә мактаулар булсын вә Расүли Әкрам салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез булса иде.

Адәм баласын Аллаһы Тәгалә акыл белән бүләкләгән, әмма күп кенә кешеләр моны дөрес итеп куллана белмиләр. Аллаһы Раббыбыз безгә, адашмас һәм акылны дөрес кулланыр өчен, динне вә акылны бирде. Әмма гыйлемсезлек, динне үзеңчә аңлау – болар бөтенесе дә аяныч бер хәлгә китерергә мөмкин. Бигрәк тә яшьләр өчен бу бик куркыныч, чөнки нәкъ менә алар – намуссыз, динне дөрес аңламаучылар һәм диннән бер корал ясаучылар өчен җиңел табыш. Яшьләр, күбесенчә, бу тозакка гыйлемсезлек һәм яшьлек көчен кая куя белмәү сәбәпле килеп эләгә. Әмма бу бәндәләр хакында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кисәтеп куя. Кансыз, мәгънәсез, хакыйкатьтә булуларын тәкърарлап, әмма хакыйкатьнең нәрсә икәненә төшенмәгән кешеләрнең барлыкка килүе хакында Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кисәтә һәм каткат искәртеп, бу кешеләрнең хәлләре аяныч булачакларын әйтә. Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا ۚ وَاذْكُرُوا نِعْمَتَ اللَّهِ عَلَيْكُمْ إِذْ كُنتُمْ أَعْدَاءً فَأَلَّفَ بَيْنَ قُلُوبِكُمْ فَأَصْبَحْتُم بِنِعْمَتِهِ إِخْوَانًا وَكُنتُمْ عَلَىٰ شَفَا حُفْرَةٍ مِّنَ النَّارِ فَأَنقَذَكُم مِّنْهَا ۗ كَذَٰلِكَ يُبَيِّنُ اللَّهُ لَكُمْ آيَاتِهِ لَعَلَّكُمْ تَهْتَدُونَ ﴿١٠٣﴾

**«Барыгыз бергә Аллаһының арканына [Китабына һәм диненә] ныклап ябышыгыз һәм [әһле китап кебек ихтилафка төшеп хакыйкатьтән һәм бер-берләрегездән] аерылмагыз. Аллаһының сезгә биргән [игелек һәм] нигъмәтен истә тотыгыз. Сез [җәһилият чорында бик озак еллар буена бер-берсе белән сугышкан] дошманнар булган чакта, Ул [сезне Ислам дине белән шәрәфләндереп] күңелләрегез арасында [татулык һәм бер-берегезгә карата җылылык ятатып] өлфәт бердәмлек барлыкка китерде, һәм сез Аның [бу] нигъмәте белән[1] [бер-берләрен бик якын күргән] кардәшләр булдыгыз. Янә сез [көферлегегез сәбәпле] Ут упкыны ярында чакта, [Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне җибәреп] Ул сезне аннан коткарды. Аллаһы аятьләрен сезгә шулай бәян итә, бәлки, сез һидаять табарсыз».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:103

Ягъни Аллаһы Тәгалә безгә бердәм булып, төрле адашу юлларыннан сакланырга куша. Без һәммәбез дә күп гыйлем туплый алмыйбыз, әмма галим булган кешеләрдән сорый алабыз. Аллаһы Тәгалә безгә бик күп нигъмәтләр бирә. Алар арасында – безгә динне аңлатучы имамнар

1 Мәдинә халкының күпчелеген тәшкил иткән Әүс һәм Хәзрәҗ кабиләләре арасында йөз дә егерме елга сузылган күптәнге дошманлык һәм бәрелешләр була. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең һиҗрәте белән Ислам шәрәфенә ирешкән бу кешеләр бөтен дошманлыкларны бер читкә ташлап кардәш булалар. Берникадәр вакыттан соң беркөн бу ике кабиләнең ике кешесе, үз кабиләләреннән чыккан кайбер дәрәҗәле сәхабәләрнең сыйфатларын санап, бер-берләренә мактанышалар һәм сүз иярә сүз чыгып, берсен-берсе өстенрәк чыгара башлый. Мөселманнарга карата бик зур дошманлык хисләре кичерә торган карт кына бер яһүди, бу форсаттан файдаланып, янында утырган яшь кенә бер егеткә: «Бар, шуларның яннарына барып утыр да элекке дошманлыкларын исләренә төшерәчәк шушы шигырьне үзләренә укы!» – дип, аңа җәһилият дәверендә узган сугышларда җиңгән тарафны данлап язылган шигырьләрне укырга куша. Шулай итеп, бер-берләренә карата ачулана башлаган бу кешеләр, үз кабиләләренә дә хәбәр итеп, эшне зурга җибәрәләр һәм, ахыр чиктә, ике зур кабилә коралланып, бер-берсе каршына киләләр. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу хәлдән хәбәр алыр-алмас алар янына ашыга, киеренкелекне тәмам юк итә, эшне җайга сала. Менә 100-103 нче аяте кәримәләр бу вакыйга сәбәпле иңгәннәр.

һәм галимнәр. Безгә Раббыбыз аларны бер маяк итеп бирде. Алар – безгә хак юлны аңлатып, начар юлдан саклаучылар. Әгәр тарихка күз салсак, Сөләйман галәйһиссәламнең вакыйгасы күз алдына килә. Ул далага үз гаскәре белән кергәч, шушы далада бер кырмысканың калган кырмыскаларга хәбәр биргәнен ишетә һәм шушы кырмыска бүтәннәргә сак булырга, һәлак булмаска өнди. Дингә бәйле карасак, галимнәр дә безне начар юллардан алып калырга тырышалар. Ләкин дин исеме астында начарлыкка өндәүчеләр бик күп. Кайчакта кеше үзенең кыек юлга кергәнен бик соң гына аңлый. Яшь кешеләр бигрәк тә андый йогынтыларга бирелергә мөмкин, чөнки яшь кешедә чиктән ашу (максимализм) көчле була, ул бер мизгелдә бөтен дөньяны үзгәртергә, бөтенесен тиешле рәвештә булдырырга тели. Тормыш тәҗрибәсе булмау сәбәпле, тормышны үзгәртүне иң беренче чиратта үзеңнән башлап, тормышта нәрсәгә дә булса ирешү өчен, күп авырлыклар аша үтәргә кирәклеген ул әле аңлап бетерми. Шушы максимализмга ияргән яшь кешенең башын әйләндерү өчен, күп кирәкми. Кызганыч ки, кайвакыт инде болар бик аяныч хәлләргә китерә. Тормышта төзәтеп булмаслык хаталар кылына, үзеңә генә түгел, якыннарыңа, туганнарыңа зарар килергә мөмкин. Гасырлар буена килгән ислам хокукый мәктәпләрен кире кагып, ниндидер шикле булган юлга кереп китеп адашалар. Безгә Аллаһы тарафыннан яшәү мөмкинлеге бер генә бирелә, ә без шул мөмкинлекне мөмкин кадәр файдалы, Раббыбызның ризалыгына ирешердәй итеп яшәргә тиешбез.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдәге «Мөлек» сүрәсенең түбәндәге аятендә болай дип әйтә:

الَّذِي خَلَقَ الْمَوْتَ وَالْحَيَاةَ لِيَبْلُوَكُمْ أَيُّكُمْ أَحْسَنُ عَمَلًا ۚ وَهُوَ الْعَزِيزُ الْغَفُورُ ﴿٢﴾

**«Ул, сезнең кайсыгыз гамәлләренә күрә күркәмрәк булуын сынар өчен, үлемне һәм тереклекне яратты [сезнең кылачакларыгыз**

**хакында әзәли гыйлемен уртага чыгарачак, соңыннан Үзенең гыйлеменә күрә түгел, кылганнарыгызга күрә әҗерләрегезне бирәчәк]. Ул – Бөек [Җиңелмәс], [гөнаһларны күпләп] гафу Итүче».**

«Мөлек / Патшалык», 67:2

Аллаһы Тәгалә яшәешне һәм үлемне, кешеләрне сынар өчен, ясатты, кайсылары яхшы гамәлләрне кылар икән, без шушыннан нәтиҗә ясыйбыз. Безнең тормыш төрле ялган, буталган, адашкан экстремизм юлларын белү өчен түгел, ә яхшы гамәлләр кылар өчен. Яхшы гамәл беркайчан да начарлыкка илтми. Дөньяга син нинди күзлектән карыйсың, шуны күрәсең. Экстремизм юлы – ул шәйтан юлы. Андый кешеләр белән аралашудан бик сакланырга кирәк.

Ә экстремизм каян килеп чыга соң? Соңгы вакытта бу сорау бик актуаль. Әмма шәйтан юлы бик күптәннән яши. Беренче хариҗилар Гали бине Әби Талиб заманында ук булалар. Алар Гали бине Әби Талиб радыяллаһу ганһенең фикерләре белән килешмиләр. Аңа кадәр шушындый ук фетнәчеләр Госман бине Гаффан радыяллаһу ганһенең тормышын өзәләр. Бу хакта Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм берничә тапкыр кисәтеп: «Аларның юлы – ул гыйлемсезлек юлы», – дип әйтә.

Ислам дине – тынычлык, матурлыкны күрсәтеп, гыйлемгә юнәлгән, кешеләрнең хокукларын яклар өчен иңгән дин. Иң беренче иңгән аятьләрдә үк Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә болай дип әйтә:

اقْرَأْ بِاسْمِ رَبِّكَ الَّذِي خَلَقَ ﴿١﴾

**«[Расүлем! Һәрнәрсәне юктан бар итеп] Яратучы Раббың исеме белән [башлап, Коръәнне] укы!»**

«Галәк», 96:1

Мөселман кешесе һәрвакыт үзен гыйлемгә багышларга тиеш. Алга үсәргә теләге булган мөселманга бернинди дә куркыныч идеяләр янамый, чөнки аның буш нәрсәләргә вакыты калмый.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Гыйлем эстәү – бишектән алып, ләхеткә кадәр фарыз», – дип әйткән. Ягъни наданлык ул шушы нык нигезле гыйлем булмау сәбәпле тарала. Өстәвенә, андый идеяләр хәзер интернет аша үтеп керә. Белемне теләсә нинди китаплардан, электрон форматта һәм иң мөһиме, ышанычсыз булган затлардан алмаска кирәк. Бу афәткә яшь кеше генә түгел, ә олы яки урта яшьтәге кеше дә бирелергә мөмкин. Моннан саклану юлларына килгәндә, безгә гыйлемне мәдрәсәләрдә рәсми имам, мөгаллимнәрдән алырга кирәк. Татар милләтенең рухи байлыгы, дини мирасы бик зур. Гәрчә күп кенә ялгыш юлдан китүчеләр бу хакыйкатьне инкяр итсәләр дә, бу факт һәм хактыр. Гасырлар буена кулланылган тәҗрибәле, традицион булган мәзһәбләр белән көрәшү – ул ахмаклык. Кызганыч, моны кайберәүләр аңламый. Үзен гыйлемле, калганнардан өстен итеп санау аларның күзләрен томалый. Гыйлем билгеле бер тәртиптә алына, иң мөһиме – ул остаз аша алынырга тиеш. Ике игътикади һәм 4 фикһи мәзһәб – алар бөтенесе хакыйкый булган юл, бөтенесе Коръән һәм Сөннәткә нигезләнгән.

Шәһәр һәм авылларны адашу юлларыннан саклар өчен гыйлем алу мөмкинлекләре булуы зарур, бездә исә мондый проблемалар юк, теләк кенә булсын. Безнең өчен дин юлы – бәхет юлы.

Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә :

وَمَا أَرْسَلْنَاكَ إِلَّا رَحْمَةً لِّلْعَالَمِينَ ﴿١٠٧﴾

**«[Расүлем!] Без сине [җеннәр, фәрештәләр, кяфер һәм мөселман барча кешеләрне кертеп] бөтен галәмнәр өчен бер рәхмәт итеп җибәрдек».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:107

Ягъни ислам дине безгә котылу, җәннәтле булу, кешеләрне сөендерү өчен килде, ә кешеләрне газаплап, интектереп, адашу юлына керү өчен түгел. Ихлас кеше чын күңелдән гыйбадәт кылып, гыйлем алып, тыйнаклыкка, әдәпкә өйрәнә икән, бу кешене Аллаһы Үзе бөтен бәлаләрдән саклый һәм яклый! Аллаһы Тәгалә безне бозык, дөрес булмаган, адашу юлларыннан саклап, дөрес юлга, мәгърифәт юлына ирештерсә иде. Аллаһы барчабыздан да разый булсын. Әәмин.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Алмаз хәзрәт Галимҗанов,*

*Саба районы имам-мөхтәсибенең яшьләр эшләре буенча ярдәмчесе,*

*Сатыш авылы имам-хатыйбы*

*25 сентябрь вәгазе,*

*Сафәр аеның 8 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Зыян китермә, сиңа да зыян булмас

Барчаларыбызны да юктан бар кылып, безне билгеле бер вакытка кадәр шушы сынау дөньясына урнаштырган; тирә-ягыбызда булган һәрнәрсәне безгә хезмәткә тапшырган; безгә күрү өчен – күз, ишетү өчен – колак, уйлау, фикерләү өчен аң-белем биргән; безгә нигъмәтләрнең иң югарыларын – иман, ислам, Коръән, намаз, гыйбадәт нигъмәтләре насыйп иткән; барча мәхлүкъларын Кыямәт көнендә Үз каршына китереп бастыручы; һәркайсына хисап кылып, гадел хөкем итүче; кемнедер җәннәтле, ә кемнедер җәһәннәмле итүче, бердәнбер гыйбадәткә лаек булган Зат Аллаһыга мең-мең шөкерләребез, мактау-олуглауларыбыз булсын.

Безгә шушы хак динебезне өйрәткән, җәннәт юлы белән сөендергән, җәһәннәм юлы белән кисәткән, үзенең кылган һәрбер эше белән, үзенең әдәбе-әхлагы белән, үзенең тормыш рәвеше белән һәркемгә үрнәк булган, безнең өчен газиз әткәй-әнкәйләребездән, бабай-әбиләребездән, кадерле бала-оныкларыбыздан һәм үз-үзебездән дә якын булган сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, Кыямәт көнендә, иншәАллаһ, шәфәгатьчебезгә күңел түрләребездән чыккан хәер догаларыбыз, Аллаһының сәламе һәм салаваты булсын!

Газиз кардәшләрем! Иң беренче чиратта, үземне, аннан соң сезне тәкъвалыкка чакырам. Аллаһының әмерләрен үтәгез, тыйганнарыннан ерак торыгыз! Һәм белегез: Адәм баласының бу дөньядагы бәхете дә һәм Кыяматтә Аллаһының рәхмәте белән җәннәткә керүе дә кешенең бу дөньяда булганда тәкъвалыгына кайтып кала. Аллаһының әмерләрен ничек үтәде?! Аллаһының харамнарыннан ничек тыелды?! Аның

дөньядагы һәм Ахирәттәге иминлеге шуның белән бәйле. Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйткән:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ حَقَّ تُقَاتِهِ وَلَا تَمُوتُنَّ إِلَّا وَأَنتُم مُّسْلِمُونَ ﴿١٠٢﴾

**«И, иман китерүчеләр! [Әмерләрен тотып, тыйганнарыннан тыелып] Аллаһыдан тиешенчә куркыгыз һәм мөселманнар булып кына үлегез!»**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:102

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кыска җөмләләр белән киң мәгънәгә ия булган хәдисләр сөйләгән. Менә шундый хәдисләрнең берсе: Әбү Сәгыйд Сәгъд бине Синән Ходри радыяллаһу ганһе әйтүенчә, Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: لا ضرر ولا ضرار [1] – дип әйткән, ягъни: «Исламда зарар кылу һәм (җавап итеп) зарарлык китерү юк»[2]. Игътибар итегез, нибары биш кенә сүз, ләкин нинди тирән мәгънәләре бар:

1. «Сәбәпсез (беренче башлап) зарар китерү дә, җавап итеп (сиңа зарар эшләүчегә үч итеп) зарар китерү дә тыела».

2. Зарар ителәчәк икәне алдан билгеле булса, туктату чарасын күрү; зарар инде эшләнгән булса, аның өчен җавап бирү (бәхилләп булса бәхилләү, штраф түләп булса – штрафын түләү, гафу сорау һ.б.)».

3. «Үзеңә һәм башкаларга зарар итмәү».

Бу хәдис үзе бик кыска гына булса да, үз эченә динебезнең төп кагыйдәләрен сыйдырган. Зарар кылу – хакны кысу, зыян китерү, үзеңнең яки башкаларның хакына кимчелек ясау. Болар барысы да тыелган нәрсәләр. Ислам дине – билгеле булганча, кешенең динен, сәламәтлеген,

---

[1] Транскрипциясе: «Ләә дарара вә ләә дыраар».

[2] Ибне Мәҗе хәдисләр җыентыгыннан.

гомерен, акылын һәм намусын саклый торган дин. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтүенчә: «(Чын) мөселман – кулыннан һәм теленнән башкалар иминлектә булган кеше»[1]. Һәм икенче бер хәдистә: «Үзегезгә теләгәнне кардәшләрегезгә теләмичә торып, берегез дә (камил) иманлы булмас»[2], – дип әйтелә. Димәк, чын мөселман һәм камил мөэмин дәрәҗәсенә ирешер өчен, кешеләргә зыян-зарар китерүдән сак булырга, үзебезгә теләмәгән нәрсәләрне бүтәннәргә дә теләмәскә кирәк. Нинди генә эш эшләсәң дә, ул эшеңне җиренә җиткереп, югары сыйфатта башкарырга тырыш. «Минем эшләгән эшемнән башкаларга зыян килмәсен иде», – дип эшлә.

## Үзеңә дә зарар китермәскә тиеш!

Кеше үзенә ничек зарар китерә ала? Бу ничектер сәеррәк яңгырый бит. Мәсәлән, хәзерге заманда үз-үзенә кул салучы кешеләр турында ишетергә туры килә. Аларның кайберләре бауга менә, кайберләре агу эчә, кайберләре үз-үзенә пычак кадый, ә кайберләре биеклектән сикереп, үз-үзләренә кул салалар. Бу күренеш олылар арасында гына түгел, ә хәтта мәктәптә укучы балалар арасында да, яшь кызлар һәм егетләр арасында да күзәтелә. Кешенең үз-үзенә кул салуының сәбәпләре төрле. Хәзерге вакытта шуларның иң киң таралганнары түбәндәгеләр: яраткан кеше белән аерылышу, гаиләдә ир белән хатын арасында даими ызгыш-талаш, эшсез калу, бурычка бату, эчкечелек һәм наркомания.

Үз-үзеңә кул салу – бик зур гөнаһ! Аллаһы Тәгалә бу гамәлне харам кылды. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйткән:

وَلَا تَقْتُلُوا أَنفُسَكُمْ ۚ إِنَّ اللَّهَ كَانَ بِكُمْ رَحِيمًا ﴿٢٩﴾

---

1 Имам Бохари һәм Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Бохари һәм Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

**«Үз-үзегезгә кул салып яки җаныгызны куркыныч астына куеп] Үзегезне үзегез үтермәгез**[1]**. [И, Мөхәммәд өммәте!] Аллаһы сезгә карата Рәхимле...»**

«Нисә / Хатыннар», 4:29

Ни өчен кеше үзен үтерергә дип карар кыла? Моңа аны нәрсә этәрә? Кешене үз-үзенә кул салуга, иң беренче чиратта, төшенкелеккә бирелү хисе ягъни Аллаһының рәхмәтеннән өметне өзү этәрә. Кеше төшенкелеккә бирелсә, аның бу дөньяда яшисе килми башлый. Ул бу дөньядагы проблемалардан үз-үзеңә кул салу юлы белән «җиңел генә» котылмакчы була. Үзе һәлак була, ә туганнарына, балаларына, әти-әниләренә күпме кайгы хәсрәт китерә...

Ә кайвакытта кешеләр үзләрен махсус булмаган рәвештә, ялгыш һәлакәткә дучар итәләр. Моның мисаллары күп төрле, мәсәлән: көн саен юл һәлакәтләре турында хәбәрләр килеп тора. Машинада йөргәндә, тизлекне арттырып, юл кагыйдәләрен бозып, күпме кешеләр һәлакәткә очрый, еш очракта анда үзе генә имгәнми, үзе генә үлми, үзе белән күпме кешене имгәтә, һәлак итә. Күпме зарар китерә.

Тагын да куркынычы Ахирәттә җәһәннәм газабына дучар була. Аллаһы Тәгалә һәр кешегә дә җанны әманәт итеп бирде. Әманәт – ул сакларга бирелгән әйбер. Җан – ул бик кадерле нәрсә. Кеше Аллаһы биргән җанны гомере буе сакларга тиеш. Җанны саклау ул үз-үзеңә зыян китерә һәм һәлакәткә алып бара торган бөтен нәрсәдән саклануны аңлата.

Җөндүб радыяллаһу ганһе пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән хәбәр итә: «Бер кеше җәрәхәт аркасында үз-үзен үтерде. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте: Колым үз-үзен үтереп Мине узды. Шуңа күрә Мин аңа җәннәтне харам кылдым»[2].

---

[1] Башкача әйткәндә: үз нәфесләрегез кебек булган мөэмин кардәшләрегезне үтермәгез.

[2] Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм шулай ук: «Кем дә кем таудан сикереп үз-үзен үтерсә, җәһәннәмдә мәңге калган хәлдә (таудан) сикерәчәк. Кем дә кем агу эчеп үз-үзен үтерсә, кулында агуын тотып, җәһәннәмдә мәңге калган хәлдә, агу эчәчәк. Кем дә кем тимер белән үз-үзен үтерсә, җәһәннәмдә мәңге калган хәлдә, кулындагы шул тимерен корсагына кертәчәк»[1].

Бу хәдистән аңлашылганча, кеше үз-үзенә берәр нәрсә белән кул салса, җәһәннәмдә дә шуның белән яки мәңге яки бик озак вакыт дәвамында газап күрәчәк.

Галимнәр әйтүенчә, үз-үзен үтергән мөселман кеше юыла, кәфенләнә. Аңа хәнифә һәм шәфигый мәзһәбләрендә җеназа намазын укыйлар. Башка кешеләргә сабак булсын өчен, сөннәт буенча аңа җеназа намазын имам яки галим кеше укымый. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә андый кешеләргә намаз укымый торган булган. Җәбир бине Сәмура хәбәр итә: «Бер вакытны Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына үз-үзен үткен нәрсә белән үтергән кешене алып килделәр, һәм ул аңа җеназа намазы укымады». Бу хәдисне галимнәр Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үз-үзен үтергән кешегә җеназа намазын, башкаларга дәрес, гыйбрәт булсын һәм башкалар бу гөнаһтан саклансыннар өчен, укымады, дип аңлаталар.

Үз-үзен үтергән кеше өчен Аллаһы Тәгаләдән җәһәннәм газабыннан коткаруны һәм җәннәткә кертүне сорап, дога кылырга ярый. Кыямәт көнендә бу кешенең хөкеме Аллаһының теләгенә бәйле. Әгәр дә Аллаһы Тәгалә теләсә, аны гафу итә, әгәр дә теләсә, аны газаплый.

Йә Раббым, һәммәбезне дә үз-үзебезгә карата һәм башкаларга да зарар китерүдән сакласаң иде!

---

1 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Гәбделкәрим хәзрәт Гыйззәтуллин*

*Әгерҗе районы мөхтәсибе*

*2 октябрь вәгазе,*

*Сафәр аеның 15 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Гаилә таркалуның балаларга йогынтысы

Ислам динендә гаилә коруга, ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләргә зур игътибар бирелә. Аллаһы Тәгалә, гаилә әһелләре арасындагы хокукларның гадел рәвештә үтәлүен таләп итеп, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә шәргый кануннарын иңдергән. Әгәр кеше Аллаһы Тәгалә тыйган әйберләрдән ерак торса, рөхсәт иткән нәрсәләрне үтәсә, ике дөньяда да бәхетле була ала. Бары Галәмнәрнең Раббысы гына адәм баласына нәрсә бәхет китерәчәген белә.

Кызганычка, гаилә кору сараена бәхетле кавышу мизгелләрен теркәү өчен генә түгел, ә аерылышу турында белешмә алу өчен дә еш мөрәҗәгать итәләр. Әлбәттә, гаилә таркалуга барып җитүнең төрледән-төрле сәбәпләре бар: аралар суыну, хыянәт, ике яр арасына өченче затларның кысылуы, акча мәсьәләсе... Бу исемлекне һәрбер аерылышкан пар үз сәбәбе белән тулыландыра аладыр, мөгаен. Әмма бүгенге вәгазь талак, аның төрләре, сәбәпләре хакында түгел. Сүзебез гаилә корабы комга терәлгәннән соң, тормыш ярында башларын аска иеп утырып калган ятим балалар хакында.

Хәзерге вәзгыятьтә мөселманнар арасында талак әйтү гадәти күренешкә әверелеп бара. Әле бер яктан, әле икенче яктан: «Теге гаилә таркалган икән, тегеләр бергә яшәмиләр, бу хатыннан башкага чыгып киткән, теге, ирен калдырып, әти-әнисе йортына кайткан икән,» – дигән хәбәрләр ишетелеп тора. Кайберсенә ихластан шаккатасың, икенчеләре табигый хәл булып кабул ителә.

Гаилә таркалуда гаебе булмаган бер генә тараф бар, ул – бала. Талакның иң көчле җимергеч дулкыны балалар өстенә төшә. «Ул әле кечкенә, аңламаячак, үскәч онытачак», – дип фикер йөртә өлкәннәр. Әмма бала – тере җан, ул сизә, тоя, ул ярата, ул тулы гаиләгә мохтаҗ, ул – ике яклы яратуга, назга сусаган бер чәчәк. Статистик мәгълүматларга карасак, һәрбер җиденче бала тулы булмаган гаиләдә тәрбияләнә.

Талак процессында ир белән хатын арасында төрле негатив вакыйгалар килеп чыга, һәм менә шул вакытта өченче зат – бала хакында онытырга кирәк түгел. Бала ничә генә яшьтә булмасын, ата белән ананың аерылышуы – аның өчен зур кайгы-хәсрәт.

Әйе, гаиләләр төрле була: кемдер бәхетле, ә кемдер бәхетсез. Бала өчен гаилә – ул зур бер әкияти сарай: әтисе – анда падишаһ, ә әнисе – патшабикә. Әмма бу фани дөнья камил түгел, һәм сарайлар да җимерелә, әкиятләр эреп юкка чыга.

Бик еш ата белән ана, үзләре дә сизмәстән, баланы бер-берсенә каршы салкын сугышта корал итеп кулланалар. Һәртөрле манипуляцияләр, баланы бер-берсеннән тартып алу өчен, янаулар, судлашулар – шушы исемлектән.

Бала күңелендә һәрвакыт әти белән әни яңадан кавышыр, бар да элеккегечә булыр дигән өмет яши. Икенче төрле вариантта – тулы өметсезлек: әти белән әни беркайчан да бер-берсен яратмаганнар, минем өчен генә кавышканнар, бөтен бәхетсезлекнең сәбәбе – мин. Бу ике сценарий да балада күпләгән психологик проблемалар – невротизм китереп чыгара. Балачакта алган психик яралар кешене гомер буе җибәрми, инде үз гаиләсен төзегән очракта да, балачак «яралары» әледән әле калкып, иректе, бәхетле тормыш корырга ирек бирми.

Хөрмәтле кардәшләрем! Балалар – ул Аллаһы Тәгалә тарафыннан безгә бирелгән әманәт. Күп кенә ир-атлар, аерылганнан соң, балаларын тәрбия һәм матди яктан кайгырту мәсьәләләрендә хатыннары җилкәсенә

аудара, алимент түләүдән качып, рәсми рәвештә эшкә урнашмыйча йөри, йортсыз-җирсез калдыра. Барыбызга да үрнәк булган Расүлебезгә карагыз. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең балаларга карата мәхәббәте үз балалары белән генә чикләнмәгән. Үсәмә бине Зәйдтән риваять ителгән хәдистә әйтелгән: «Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм мине һәм Хәсәнне (оныгын) алдына утыртып, каты итеп кочаклап, Аллаһы Тәгаләгә дога кыла иде: Йә Раббым, Үзеңнең рәхмәтеңне шушы балаларга насыйп ит, чөнки мин аларны шулкадәр нык яратам».[1] Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе сөйли: Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм Хәсән бине Галине үбеп алган вакытта, янында Әл-Әкра бине Хәбис Әт-Тәмими утыра иде. Әл-Әкра сүз алып, болай дип әйтте: «Минем ун балам бар һәм мин аларны бер дә иркәләп үпкәнем булмады». Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа күз карашын ташлап: «Кем дә кем башкаларга рәхмәтсез булса, үзенә карата да рәхмәт өмет итмәсен»,[2] – дип әйтте. Икенче бер хәдистә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Аллаһыдан куркыгыз һәм үз балаларыгызга гадел мөнәсәбәт кылыгыз».[3]

Әгәр дә без Мөхәммәд өммәтеннән икән, нигә талак әйткән вакытта, балаларыбызның киләчәк язмышы, сынган күңеле, түгеләчәк күз яшьләре турында уйлап та карамыйбыз? Бик еш хатынга карата ачуыбыз һәм күрә алмавыбыз балаларга да күчә. Сез аларны дөньяга кунак итеп чакыргансыз, Аллаһы Тәгалә сезгә аларны кадерле кунак итеп җибәргән, ни өчен сез аларны кадерсез, сөйкемсез, инде кирәкмәс бер зат итеп, тормышның «урамы читенә» атып калдырасыз?

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Чынлыкта, Кыямәт көненнән соң кеше лаек булмаган югары дәрәҗәдәге

[1] Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

[2] Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

[3] Имам Бохари һәм Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

җәннәт бакчасына күтәрелер. Ул аптырап болай дип сорар: «Бу миңа нәрсә өчен?» Аңа: «Синең гөнаһларыңны гафу итүен ялварып сораган балаңның догалары өчен»,[1] – дип әйтелер. Әгәр син балаларыңны, әманәтеңне ташлап аерылып чыгып киткәнсең икән, ничек итеп син аларны иман нурында тәрбия кыла алачаксың? Догачың кем булыр, кардәшем?

Габдулла бине Гамер радыяллаһу ганһүмәдән риваять итеlә, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Үзендә шушы дүрт сыйфатны тапкан кеше чын монафикъ булыр, ә кем үзендә шул дүрт сыйфатның берсен тапса, аннан котылганчыга кадәр монафикъ галәмәтендә булыр. Әлеге сыйфатлар белән аерыла торган кеше шундый: әманәтенә хыянәт итә, ялган сөйли, сүзендә тормый, кем беләндер дошманлык кылганда, гамәлләрендә чигеннән чыга».[2]

Үзегезнең балачакка әйләнеп кайтыгыз. Күз алдыгызга китерегез: иртәнге кояш нуры сезне уята, сезгә 4-5 яшьләр тирәсе. Өегездә җылы, рәхәт. Юрганны алып атып, аш бүлмәсенә йөгерәсез. Әниегез тәмле коймаклар пешерә, әтиегез кайнар чәй белән коймак ашый. Сезне күрүгә, әтиегез кочаклап, алдына утырта. Әниегез, хәерле иртә теләп, башыгыздан сыйпый.

Икенче күзаллау да бар. Уянасыз. Өйдә тын. Якшәмбе. Димәк, әни эштә түгел, өйдә. Торып, аш бүлмәсенә чыгасыз. Әниегез чәй эчеп утыра. Сезгә тонык кына караш ташлый да: «Әйдә, юын да чәй эч. Хәзер әтиең килеп алыр. Үзең киенеп аска төшәрсең», – ди. Атна-ун көнгә бер тапкыр сезнең әтиле көнегез дә бар, әмма әти һәм әниле түгел.

Кайсы күңелгә җылы һәм рәхәт? Ә кайсысы күңелне өшетә, җанны биздерә?

Үз балагызга сез кайсысын теләр идегез?..

---

[1] Ибне Мәҗе хәдисләр җыентыгыннан.

[2] Имам Бохари һәм Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Ирек хәзрәт Нуриев,*

*Менделеев районы мөхтәсибе*

# Фәтвалар

# Ахшам намазының ике рәкәгать сөннәте әүвәбин намазы саналамы?

**Сорау: Әссәләмү галәйкүм! Ахшам намазының ике рәкәгать сөннәте әүвәбин намазының бер өлеше саналамы?**

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм! Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләрендә ахшам намазыннан соң укыла торган алты рәкәгать намаз искә алына. Бу намазның саваплары турында төрле чыганакларда төрле фикерләр бар: намазның савабы 20 ел намаз уку савабына тиң, гөнаһлар кичерелә, бу намазны укучы гөнаһларыннан тәүбә итүчеләр рәтендә булыр һ.б.

«Әүвәбин» сүзе Аллаһыга «еш һәм күп тапкырлар кайту» мәгънәсендәге фигыльдән ясалган, ягъни Аллаһыга тәвәккәл кылып, Аннан гафу сорау мәгънәсендә.

Ахшам намазының ике рәкәгать сөннәте әүвәбин намазының алты рәкәгатенә керүе хакында хәнәфи мәзһәбе галимнәре арасында каршылыклар бар. Имам Шурунбуләли «Мәраки әл-Фәлакъ» хезмәтендә болай дип язган:

فتكون الست في المغرب غير الركعتين المؤكدتين

«Ахшамнан соңгы алты рәкәгатькә ахшамның ике рәкәгате керми».

Бу фикер буенча, башта ахшамның ике рәкәгать сөннәте, аннары алты рәкәгать әүвәбин намазы укылырга тиеш.

Башка фикер дә бар дидек. «Әд-Дурр әл-Мохтар» хезмәте авторы болай дип әйткән:

وهل تحسب المؤكدة من المستحب ويؤدي الكل بتسليمة واحدة اختار الكمال نعم

«Ике рәкәгать сөннәт муәккадә алты рәкәгать мөстәхәб өлеше саналамы? Аларны бер сәлам белән укырга ярыймы? Әл-Камәл (Ибне Хөмәм) – «Әйе» дигән фикердә».

Димәк, иң элек ахшам намазының ике рәкәгать муәккадә сөннәтен, аннары алты рәкәгать әүвәбин намазын уку хәерлерәк. Башка фикерләр дә барын исәпкә алып, дүрт рәкәгать әүвәбин намазын уку да ярый.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

## Намаздагы сүрәләрнең озынлыгы хакында

**Сорау: Әссәләмү галәйкүм! Намазның беренче рәкәгатендә кыска сүрә, ә икенчесендә озын сүрә укысаң, намаз дөрес буламы?**

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм! Намазның икенче рәкәгатендә «Фатиха» сүрәсеннән соң беренче рәкәгатьнекенә караганда кыскарак сүрәләр уку хәерлерәк.

«Әл-Фәтәва Әл-Хиндия» авторы болай дип яза:

وإطالة القراءة في الركعة الأولى على الثانية من الفجر مسنونة بالإجماع وقال محمد رحمه الله تعالى أحب إلي أن يطول الركعة الأولى على الثانية في الصلوات كلها وعليه الفتوى كذا في الزاهدي ومعراج الدراية وفي الحجة وهو المأخوذ للفتوى كذا في التتارخانية وعلى هذا الخلاف الجمعة والعيدان هكذا في البدائع.(الفتاوى الهندية ١/٧٨)

«Коръәнне беренче рәкәгатьтә икенчесенә караганда озынрак уку барлык галимнәр тарафыннан иртәнге намазның сөннәте булып санала. Имам Мөхәммәд рахимәһуллаһи: «Мин барлык намазларда да беренче рәкәгатьтә озынрак сүрә уку хәерле дип саныйм», – дип әйткән. Фәтва шушы фикердән чыгып бирелгән».

Намазның беренче рәкәгатендә икенчесенә караганда 3 аять яисә аннан күпкә кыскарак сүрә уку мәкруһ тәнзиһән хөкемендә. Әмма намаз дөрес була.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

# Тәсбих: фарыз яки сөннәт намаздан соңмы?

**Сорау: Әссәләмү галәйкүм! Берничә ел түбәндәге хәлне күзәтәм. Кайбер мөселман кардәшләребез фарыз намаздан соң ук тәсбих әйтергә тотына, гәрчә имам һәм мәчеткә йөрүче калган кешеләр тәсбихне сөннәт намаздан соң әйтсә дә. Элек бу хәлгә игътибар бирмәскә тырыштым. Алар башка мәзһәбкә иярүчеләр булырга мөмкин дип уйладым. Әмма, бервакыт, аларның берсе актив агитация алып бара башлады, имештер, имам дөрес эшләми, бу – бидгать, дип белдерде. Һәм алар кебек эшләргә, ягъни фарыз намаздан соң тәсбих әйтергә кирәк, диде. Мин бөтенләй буталып беттем. Зинһар өчен, бу мәсьәләгә ачыклык кертергә ярдәм итсәгез иде. Рәхмәт.**

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү!

Әйе, дөрестән дә, кызганыч ки, әмма мондый күренешләр булырга мөмкин. Гыйлем җитмәү һәм күп нәрсәләрне дөрес аңламау нәтиҗәсендә, кайбер кешеләр дини сорауларны үзләренчә аңлатырга тотына. Алай гына да түгел, алар өммәттә танылу алган чын галимнәр тапшырган белемнәрне кире кагып, абсолют хакыйкатькә дәгъва кыла башлый.

Әлеге сорауга җавап бирү өчен, сезне иң әүвәл галимнәребезнең методологиясе белән таныштырырга телибез. Аннары мөһим нәтиҗәләр чыгару мөмкин булачак.

Әлеге теманы тикшереп, имам Ибне Габидин рахимәһуллаһи: «Сөннәт намазы «Аллаһүммә...» сүзләрен әйтер өчен, таләп ителгән вакыт аралыгына калдырып торыла», – дип әйткән. Аның дәлиле Гайшә радыяллаһу ганһәдән тапшырылган хәдискә нигезләнә. Әлеге хәдис имам Мөслим һәм имам Тирмизи җыентыкларында урын алган. Бу

хакта Гайшә радыяллаһу ганһә түбәндәгеләрне әйткән: «Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм (сөннәт алдыннан фарыз намазны үтәгәннән соң) әлеге доганы («Аллаһүммә әнтәс-сәламү вә минкәс-сәлам табәрактә йә зәл-җәләли вәл-икрам») укыр өчен кирәк булган вакыттан да күбрәккә утырмаган.

Тәсбих фарыз намаздан соң кылыну турында хәбәр ителгән хәдисләргә килгәндә, бу гамәлнең сөннәтне үтәр алдыннан эшләнүе әйтелми. Мондый хәдисләрдән аңлашылган дөрес мәгънә шулдыр ки: тәсбих сөннәт намазны үтәгәннән соң башкарылган, чөнки сөннәт турыдан-туры фарыз намаз белән бәйле булып тора һәм аны тулыландыра. Сөннәт шулай ук фарыз намаздан аерым булып тормый. Шул сәбәпле, сөннәттән соң башкарыла торган барлык гамәлләр фарыздан соң килә торган гамәл булып тора. Моннан тыш, Гайшә радыяллаһу ганһә вакыт аралыгын да искә ала. Димәк, әлеге хәдистән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм (һәрвакыт) нәкъ менә шул сүзләрне әйтүе хакында белдерелми. Мөгаен, бу хәдис Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм (фарыз намазны үтәгәннән соң) әлеге сүзләрне әйтү өчен җитәрлек булган вакыт аралыгына игътибар юнәлтә. Шулай итеп, ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең һәрбер фарыз намазны үтәгәннән соң түбәндәге сүзләрне әйтүе хакында сахих хәдисләрнең ике җыентыгында килгән мәгълүматка берничек тә каршы килми:

لا إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ، لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ، اللَّهُمَّ لَا مَانِعَ لِمَا أَعْطَيْتَ وَلَا مُعْطِيَ لِمَا مَنَعْتَ وَلَا يَنْفَعُ ذَا الْجَدِّ مِنْكَ الْجَدُّ

Имам Зәфар Әхмәд Усмани рахимәһуллаһиның «Игълә Әссүнән» дип аталган хезмәттә әйткән сүзләреннән аңлашылганча, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең һәр намаздан соң зикернең кайсы да

булса бер төрен әйтүе ачык булып тора (алар хакында без югарыда сүз алып барган идек). Тапшыручыларның һәрберсе аңа ишетү насыйп булган зикер төре турында хәбәр иткән. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең һәрбер намаздан соң төрле хәдисләрдә телгә алынган барлык төр зикерләрне әйтеп чыгу ихтималы бик аз. Әлеге факт һичьюгы аз гына булса да аңларга теләге булган теләсә кем өчен ачык. Гайшә радыяллаһу ганһәдән килгән хәдистән аңлашыла торган мәгънә фарызны укыганнан соң сөннәтләре үтәлә торган намазларга күрсәтә (биредә фарызны укыганнан соң, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм, сәлам догасын уку өчен, кирәк булган вакыттан да күбрәк утырып тормыйча, сөннәтне үтәргә керешкән). Ә намаздан соң озак зикер кылу (хәбәр ителә торган хәдисләрдә) фарыздан соң сөннәтләре укылмый торган намазлар турында әйтелә. Әгәр фарыздан соң сөннәт булса, зикер сөннәттән соң әйтелә. Шулай итеп, барлык хәдисләр дә, берләштергәннән соң, бер мәгънәгә күрсәтә. Фикер каршылыкларының асылы шунда ки: сөннәт намаз турыдан-туры фарыз намазга бәйләнгән, ул фарыз намаз белән бергәлектә башкарыла, бәйлелек бар, сөннәтне үтәүгә ашыгу кирәклеге раслана. Димәк, мондый тәҗрибә (ягъни күрсәтелгән тема буенча барлык хәдисләрне куллану тәҗрибәсе) иң дөресе булачак, бу хакта без югарыда әйтеп уздык.

**Нәтиҗә:**

1. Нинди дә булса дини-хокукый мәсьәләне караганда, хәнәфи мәзһәбе нигезендә, аерым хәдисләрне генә түгел, ә Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә барып тоташкан барлык мәгълүматны да исәпкә алырга кирәк. Юкса, безнең хөкем (хокукый норма) эшләрнең чын торышын чагылдырмаячак.

2. Югарыда китерелгән хәдисләрдән аңлашылганча, фарыздан соң сөннәте булмаган намазларда, тәсбих фарыздан соң кылына. Ягъни,

иртәнге һәм икенде намазларыннан соң тәсбих фарыздан соң ук, имам «сәлам» догасын укыгач ук кылына. Ә фарыздан соң сөннәтләр укыла торган намазларда, без, фарыз намазны укыганнан соң, «сәлам» догасын укыйбыз, сөннәт намазны башкарабыз, ә аннары тәсбих әйтәбез. Мондыйларга өйлә, ахшам һәм ястү намазлары керә.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

*Булат хәзрәт Мөбарәков,*

*ТҖ МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе*

# Үрнәк затлар

# Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһе

## Исеме

Габдрахман бине Гауф – ислам динен беренчеләрдән булып кабул итүчеләрдән. Җаһилият заманында аның үз исеме Габделкәгъб (Кәгъбәтулла колы), башка риваятьләр буенча Габделәмер булган. Шулай ук ул Әбү Мөхәммәд куньясе белән дә танылган.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккә шәһәрендә Әркамә йортында сәхабәләре белән җыелышып очраша торган булган. Шул йортта Габделкәгъб ислам динен кабул иткән һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа Габдрахман дип исем биргән.

## Тууы

Габдрахман бине Гауф фил елы вакыйгаларыннан егерме ел үткәч, якынча 580 елда Мәккә шәһәрендә дөньяга килгән.

## Гаиләсе

Габдрахман бине Гауфның әнисе – Сыйфә бинте Гауф бинте Гадил-Харис бинте Зөһрә бинте Киләб. Әнисе, ислам динен кабул итеп, Хәбәшигә һиҗрәт кылган. Әтисе – Харис исемле, корәеш кабиләсенең Бәну Зөһрә нәселеннән.

## Һиҗрәт кылуы

Беренче мөселманнар кебек үк, Габдрахман бине Гауфка да авыр сынаулар аша үтәргә туры килгән. Алар кебек ул да диненә тугры булып, бу

сынауларга нык торган. Башка мөселманнар кебек ул да үз динен саклап калу максатыннан Хәбәшигә (Эфиопия) һиҗрәт кылган.

Аллаһы Тәгалә тарафыннан пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәм аның сәхабәләренә Мәдинәгә күчү рөхсәт ителгәч, Габдрахман бине Гауф Аллаһы ризалыгы өчен һиҗрәт кылучыларның алгы сафында булган. Мөселманнарга Мәдинәгә һиҗрәт кыларга әмер бирелгәч, Габдрахман бине Гауф башка мөселманнар белән беррәттән Мәдинә шәһәренә күчкән.

Мәдинәгә күчкәндә Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһенең һәм Сөхәйб Әр-Руминың мал-мөлкәте Мәккәдә калган булган. Мөшрикләр малларын шәһәрдән чыгарасылары килми. Шул сәбәпле, мөселманнар Мәдинәгә күчә алмый торалар, ләкин алар малга караганда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән бергә булуны өстенрәк күргәннәр. Шуңа да бөтен малларын Мәккә мөшрикләренә калдырып, Мәдинәгә күчкәннәр.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөһаҗирләр белән әнсарларны туганлаштыра башлагач, ул Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһене Сәгъд бине Әр-Раби Әл-Әнсари белән туганлаштыра. Сәгъд бине Әр-Раби Әл-Әнсари Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһегә: «Йә абыем минем! Мин – Мәдинәдәге иң эре милекче. Минем ике бакчам бар. Моннан тыш минем ике хатыным бар. Шушы ике бакчамның кайсы ошый, шунысын үзеңә ал. Хатыннарымның да кайсына күзең төшә, шуны үзеңә сайлый аласың. Мин аны аерып, син аңа өйләнерсең», – дип әйткән. Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһе: «Сиңа, синең якыннарыңа һәм малыңа Аллаһының рәхмәте булсын. Син миңа базарның кайда икәнлеген күрсәт әле», – дип әйткән. Сәгъд бине Әр-Раби Әл-Әнсари аңа базарның кайдалыгын күрсәткән һәм Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһе базарда сату итә башлаган. Товарларны сатып алган, саткан, үзенә керем туплаган. Габдрахман бине Гауф сәүдә

эшләрендә бик оста булган, шуңа да тиз арада кәсеп кылып, мал туплап мәһәр белән өйләнгән. Ислемайлар сибенеп, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килгән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм гаҗәпләнеп аннан: «Сиңа нәрсә булды?» – дип сораган. Ул: «Мин өйләндем», – дип җавап кайтарган. Шуннан соң Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм аннан кәләшкә күпме мәһәр бирүе турында кызыксынган. Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһе: «Мин аңа бер нават[1] алтын бирдем», – дип җавап кайтарган. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бер сарык белән булса да туй яса. Аллаһы Тәгалә сиңа рәхмәтен ирештерсен», – дип әйткән. Габдрахман бине Гауф: «Бу сүзләрдән соң минем тормышым алга китте. Теләсә нинди ташны күтәреп алсам да, мин шул таш астында йә алтын, йә көмеш табармын кебек тоела иде миңа», – дип искә алган.

## Юмартлыгы

Габдрахман бине Гауф Бәдер һәм Өхед сугышларында үзен аямыйча көрәшкән. Өхед сугышында башка гаскәриләр куркып калганда да, ул түземлек күрсәткән, нык торган. Бик нык яраланса да, авыртуларга түзгән.

Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһе бик ярдәмчел булган. Юмартлыгы бер яктан фәкыйрьләргә тисә, икенче яктан, хәрби әзерләнүләргә ярдәм иткән.

Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, гаскәрне хәрби поход өчен кирәк-яраклар белән тәэмин итү максатыннан, үзенең сәхабәләренә болай дип мөрәҗәгать иткән: «Мин хәрби экспедиция җибәрергә уйлыйм, мөмкинлеге булганнарыгыз үзенең ярдәмен күрсәтә ала». Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бу сүзләрен ишеткәч, өенә йөгергән һәм тиз арада килеп тә җиткән: «Йә Аллаһының Илчесе! Минем дүрт мең акчам бар. Мин

1 Нават – җимеш төше авырлыгындагы алтын коелмасы.

аның икесен Аллаһы юлында сарыф итәм, ә икесен балаларыма калдырдым», – дип әйткән. Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм аның бу гамәленнән риза булып: «Малыңны биргән өчен дә һәм үзеңә калдырганың өчен дә, Аллаһы Тәгалә сиңа Үзенең рәхмәтен ирештерсә иде», – дип әйткән.

Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәрби поход белән Табукъка барырга уйлагач, сугыш өчен кирәк-яракларның һәм гаскәриләрнең кытлыгы нык сизелгән. Византия армиясе күп санлы иде, ә Мәдинәдә ул елда нык корылык булган. Гаскәрләргә озын һәм авыр юл көтелә иде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына бер төркем мөселманнар килеп, походка барырга теләкләрен белдергәч, дөяләрнең аз булуы сәбәпле, Аллаһының Илчесе аларның үтенечләрен кире кагарга мәҗбүр булган. Әлеге мөселманнар ярдәм итә алмаганнарына бик нык күңелсезләнеп, елый-елый өйләренә таралышканнар. Бу вакыйгадан соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үз сәхабәләренә, Аллаһы ризалыгы өчен, ярдәм күрсәтергә әмер биргән. Барлык мөселманнар да бердәм булып, Аллаһы Илчесенең әмерен үтәргә тырышканнар. Беренчеләрдән булып Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһе 200 унция[1] алтын күләмендә үз өлешен керткән. Бу уңайдан Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Габдрахман кылган гамәл – гөнаһ. Ул туганнарына һәм якыннарына бернәрсә дә калдырмаган», – дип әйткән. Шуннан соң аннан: «Әй Габдрахман, син якыннарыңа берәр нәрсә калдырдыңмы?» – дип сораган. Габдрахман бине Гауф: «Әйе… мин аларга үзем сарыф иткәннән дә күбрәген һәм иң яхшысын калдырдым», – дип җавап кайтарган. Аллаһының Илчесе күпме калдырганлыгы турында кызыксынгач, ул: «Аллаһы Тәгалә һәм Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм тарафыннан вәгъдә ителгән Аллаһының барлык ризыгын, игелеген һәм бүләген», – дип әйткән.

[1] Унция – аптекаларда кулланыла торган үлчәү берәмлеге – 29,8 граммга тигез.

Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһенең юмартлыгына тагын бер мисал карап китик.

Бервакыт Шам җиреннән Мәдинәгә 700 дөягә төялгән мал белән Габдрахман бине Гауфның чираттагы кәрваны кайта. Дөяләрнең саны шулчаклы күп булган ки, кәрван Мәдинә җиренә килеп туктагач, җир тетрәп куйган. Шәһәр эчендә бик каты тавыш күтәрелгән. Гайшә радыяллаһу ганһә бу тавышны ишетеп: «Бу тетрәү нәрсәне аңлата, нинди тавыш бу?» – дип сораган. Аңа 700 дөягә төялгән Габдрахман бине Гауфның кәрваны турында хәбәр иткәннәр. Шулвакыт Гайшә радыяллаһу ганһә болай дип әйткән: «Мин Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Мин Габдрахман бине Гауфның ничек җәннәткә шуышып кергәнен күрдем», – дип әйткәнен ишеттем».

Кәрванның дөяләре җиргә тезләнгәнче үк хәбәр йөртүче Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһегә мөэминнәрнең анасы Гайшә радыяллаһу ганһәнең сүзләрен җиткергән. Бу шатлыклы хәбәрне ишеткән Габдрахман бине Гауф канатланып, Гайшә радыяллаһу ганһә янына йөгерә һәм аннан: «Йә, мөэминнәрнең анасы, син бу хәбәрне Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең үзеннән ишеттеңме?» – дип сораган. Гайшә радыяллаһу ганһә: «Әйе», – дип җавап кайтарган. Габдрахман бине Гауф моны белгәч, тагын да шатланып: «Әгәр булдыра алсам, мин җәннәткә үз аякларым белән атлап керәм», – дип әйткән һәм бөтен кәрванны фида кылган.

Бу шатлыклы хәбәрне ишеткән көннән соң, Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһе Аллаһы юлында хезмәт итүдә, садакалар бирүдә тагын да ныграк тырышлык күрсәткән. Иң элек ул кырык мең дирһәм көмеш, аннан кырык мең динар алтын, моннан тыш мөҗтәһидләр отряды өчен – 500 ат, икенче бер отряд өчен 1500 дөя садака кылган.

Үлеме алдыннан Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһе бик күп санда колларын азат иткән. Бәдер сугышында катнашып, исән калган

һәрбер сугышчыга 400 динар алтын васыять иткән һәм һәрбер сугышчы үзенә тиешле булган сумманы алган.

Үзеннән соң калган мирасы 1000 дөя, 100 ат, 3000 сарыктан гыйбарәт булган. Һәр дүрт хатыны да сиксән мең күләмендә үзенә тиешле булган мирасны алган. Габдрахман бине Гауфтан калган алтын, көмеш шулкадәр күп булган ки, варислары ул алтын, көмеш коелмаларны балталар белән бүлеп арып беткәннәр.

## Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм каршында өстенлекләре

Мөселманнар армиясе Табукъка походка чыккан. Әлеге походта Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһе бер мөселман да ирешә алмаган дәрәҗәгә ирешкән.

Бервакыт намаз вакыты җиткәч, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне таба алмаганнар. Шуңа да Габдрахман бине Гауф барлык мөселманнарны җыеп, үзе имам булып басып, җәмәгать намазын җитәкләгән. Беренче рәкәгать тәмамлангач, гыйбадәт кылучылар арасына Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә кушылган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһегә оеп, намаз укырга аның артыннан баскан. Соңра, җәмәгать намазы тәмамлангач, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә намазда үз өммәтенең изге кешесенә иярү тыелмаган».

Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең үлеменнән соң, Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһе мөэминнәрнең аналарын (Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хатыннары) кайгырткан, аларга малы белән ярдәм итә торган булган. Мөэминнәрнең аналарына карата юмартлыгы шул дәрәҗәдә булган ки, ул үзенең шәхси җирен 40 мең динарга сатып, акчасын Зөһрә кабиләсе кешеләренә, яр-

лылар һәм мөһаҗирләргә бүлгән. Бу акчадан мөэминнәрнең аналарына да өлеш чыккан. Гайшә радыяллаһу ганһә үзенә тиешле өлешен алгач: «Бу акчаларны кем җибәрде соң?» – дип сораган. Аңа: «Габдрахман бине Гауф», – дип әйткәннәр. Шуннан соң Гайшә радыяллаһу ганһә Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сүзләрен исенә төшереп: «Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән иде: «Миннән соң сезгә сабыр булганнар гына ярдәмләшер», – дип әйткән.

## Гадилеге

Габдрахман бине Гауф нинди генә байлыкларга ия булмасын, бу мал-мөлкәт аны бозмаган, үзгәртмәгән. Үз коллары арасында булган вакытында да ул тышкы кыяфәте белән алардан аерылмаган.

Көннәрнең берендә, ул уразада булган көнне, Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһегә ризык китергәннәр. Ул ризык китергән кешегә караган да болай дип әйткән: «Миннән күпкә яхшырак булган Мөсәб бине Гомәйр вафат булды, без кәфенлек эзләгәндә аның малы арасында бер кисәк тукымадан кала бернәрсә дә таба алмадык. Ул тукыма кисәге башын капласа, аяклары ачыла иде яки аяклары капланса, башы ачыла иде. Ә безгә Аллаһы Тәгалә барлык нигъмәтләрне биргән… Кыяматтәге әҗер-саваплар инде бу дөньяда бирелгән дип куркам мин…» Шуннан соң ул үксеп елап җибәргән.

## Габдрахман бине Гауф – мөхәддис

Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһе күп хәдисләр белгән, ләкин саклык ягыннан хәдисләр тапшырудан тыелган. Шулай да аңардан хәдисләрне Ибне Габбас радыяллаһу ганһе, Ибне Гомәр, Әнәс бине Мәлик, Габдрахман бине Гауфның балалары (Ибраһим, Гамр, Әбү Сәйид һ.б.) җиткергәннәр. Имам Бохари һәм имам Мөслим хәдисләр

җыентыкларында аннан ике хәдис китерелгән. «Мөснәд Бакый» китабында 65 хәдис аннан тапшырылган дип искә алына.

## Вафаты

Госман бине Гаффан радыяллаһу ганһе идарә иткән вакытта, Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһе инде олы яшьтә булган. Шул сәбәпле, тыныч һәм тыйнак тормыш рәвеше алып барган. Ул 652 елда, Мәдинә шәһәрендә вафат булган. Габдрахман бине Гауф радыялллаһу ганһенең табутын Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең абзасы Сәгъд бине Әби Вәккас алып барган. Җеназа намазын Госман бине Гаффан хәлифә укыган. Соңгы юлга озатучы Гали бине Әби Талиб: «Син төрле ялганнардан читләшеп, бу дөньяның асылына төшендең һәм аңладың. Аллаһы Тәгалә сиңа Үзенең рәхмәтен ирештерсен», – дип әйткән.

Габдрахман бине Гауф үләр алдыннан, Гайшә радыяллаһу ганһә аны Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, Әбү Бәкер һәм Гомәр радыяллаһу ганһүмәләр янына күмәргә тәкъдим иткән. Ләкин Габдрахман бине Гауф андый дәрәҗәдән оялып, үзен Госман бине Мәсъгүм янында күмәргә кушкан. Ул Әл-Бәкыйгъ зиратына күмелгән.

# «Нәрсә? Кайда? Кайчан?»

# Мөхтәрәм укучылар!

Сезнең игътибарга «Шура» журналында яңа сәхифә ачып җибәрелде. Ул сезгә Татарстан өммәте тормышыннан иң мөһим яңалыкларны белеп торырга һәм Диния нәзарәтенең эшчәнлегенә үзегезнең бәягезне бирергә мөмкинлек бирер. Шушы мәгълүматтан чыгып, мөфтиятнең хезмәтен камилләштерү буенча үзегездән тәкъдимнәр дә кабул итәргә шат булырбыз.

*Ихтирам белән, редакция*

**Февраль**

1. Диния нәзарәте канаты астында эшли торган «Хозур ТВ» телеканалы Татарстан массакүләм мәгълүмат чаралары арасында лидерлар рәтенә кертелде. Республика буенча иң алдынгы күрсәткечне ул YouTube-тагы язылучылар саны буенча яулады. Алар былтыр 800 000 гә якынлашты. «Хозур ТВ» телеканалын дөньяның теләсә кайсы почмагыннан торып кесә телефонында карарга мөмкин. Нәзарәтнең «Хозур» Нәшрият йорты IOS һәм Android платформалары өчен махсус «Хозур ТВ» мобиль кушымтасын эшләде. Шул рәвешле, теләгән һәркем «Хозур ТВ» телеканалын телефоннан карый һәм «Азан» радиосын тыңлый ала.

2. Казанда ир-атлар һәм хатын-кызлар арасында Мәрҗани кубогына джиу-джитсу буенча IV Бөтенроссия ярышлары үткәрелде. Әлеге ярышның төп бүләгенә – хаҗга юлламага – Дагыстаннан Кәрим Эльгәрәев лаек булды.

3. Нәзарәт журналистлар өчен «Динем – Ислам, милләтем – татар» дип исемләнгән иҗади бәйге игълан итте. Конкурс җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чараларының игътибарын Татарстанда игълан ителгән Туган тел елына, татар телен саклау, үстерү һәм өйрәнү

мәсьәләләренә, шулай ук милли үзенчәлекләрне саклауда Исламның роленә җәлеп итү өчен үткәрелә. Бәйгедә быелның 15 февраленнән 30 сентябренә кадәр дөнья күргән материаллар катнаша ала.

4. Төркиядә Татарстан мөфтияте әзерләгән Коръән басмасы чыкты. Аны тагын Үзбәкстанда бастырдылар һәм Белоруссиядә нәшер итәчәкләр.

5. 2019 елда Татарстан мөфтияте 200дән артык фәтва чыгарды. Дини карарлар Имам Әбү Хәнифә мәзһәбе кысаларында Диния нәзарәтенең «Даруль ифта» мөселман call-үзәгенә иң еш килә торган сораулар буенча шәригать белгечләре тарафыннан чыгарыла.

## Март

1. Казанда мөслимәләр өчен «Яшь килен» проекты икенче сезоны башланды. Проектның яңа сезоны онлайн форматта узуы белән дә катнашучыларны сөендерде.

2. Татарстан мөфтияте «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә» басмасының аудиоверсиясен әзерләп чыгарды. Халык арасында зур популярлык казанган хезмәт «Хозур» нәшрият йортының «Азан» радиосында тавыш белән яздырылды. 40 сәгатьлек аудиоязманы танылган телевидение алып баручысы Илдар Кыямов укыды. Хәзерге вакытта «Азан» радиосы командасы нәзарәтнең рус телендә дөнья күргән «Калям Шариф. Перевод смыслов» басмасының аудиоверсиясен дә әзерләү өстендә эшли.

## Апрель

1. Пандемия аркасында Диния нәзарәтенең яшьләр проектлары online форматка күчерелде. Ир-атлар өчен «I›MAN», мөслимәләр өчен «Яшь килен» проектлары, «Коръән укырга өйрәнәбез» курслары Zoom платформасында үткәрелде. «Лекторий» дәресләре ТР мөселманнары Диния

нәзарәте социаль бүлегенең Instagram-дагы рәсми битендә @ muslimmol алып барылды.

## Май

1. Казанда намаз укырга өйрәтү һәм Ислам нигезләре белән таныштыру буенча «Ислам. Беренче адымнар» дип исемләнгән кыскавакытлы курслар тәмамланды. Дәресләрдә 130 дан артык ир-ат һәм хатын-кыз катнашты. Алар 6 дәрестә намаз уку күнекмәләрен һәм ислам дине нигезләрен бушлай үзләштерде.

2. Татарстан мөфтие үзизоляция чорында авыл имамнарына матди ярдәм күрсәтү буенча карарлар кабул итте. Килеп туган вәзгыятьтә ярдәм күрсәтү максатыннан, аеруча авыр хәлдә калган район һәм авыл мәчетләренә һәм Татарстан имамнарына финанслар бүлеп биреләчәк.

3. Республика мәчетләрендә татар теле курслары тәмамланды. Быел аларны 436 тыңлаучы тәмамлады.

4. Татарстанда республикакүләм «Татар азаны» бәйгесе узды. Конкурс республикакүләм «Рухи моң» проекты кысаларында иң күркәм рәвештә әйтелгән татар азанын ачыклау максатыннан үткәрелде һәм Татарстанның төрле почмакларыннан 150 дән артык катнашучыны колачлады. Конкурс нәтиҗәләре буенча, балалар арасында абсолют җиңүче булып Теләче районыннан 12 яшьлек Данияр Нигъмәтҗанов танылды.

5. Рамазан аеның утыз көне дә нәтиҗәле узды. Нәзарәтнең «Даруль ифта» call-үзәге көндәлек эшчәнлеген көчәйтелгән режимда алып барды. Рамазан аеның беренче көнендә генә изге айны үткәрүне оештыру, ураза тоту, намаз вакытлары үзгәрү һәм башка мәсьәләләр буенча 100 дән артык мөселман мөрәҗәгать итте. Рамазан ае барышында шәригать белгечләре 1500 дән артык шалтырату һәм мөрәҗәгатьне эшкәртте.

6. Рамазан аеның бизәге Коръән хәтем кылу булды. Ул уразаның беренче көнендә Казан шәһәренең Галиев мәчетендә башланып китте

һәм ТР мөселманнары Диния нәзарәте сайты аша көн саен туры эфирда трансляцияләнде.

7. Быел «Рамазан – изге гамәлләр ае» хәйрия марафоны зур колач белән узды. Җыелган акчалар 12 авыру балага дәваланыр өчен түләргә, Ютазы районы Иске Каразирек авылында үз-үзеңне читләштерү режимы вакытында янган мәчетне торгызырга һәм 180 мең аз керемле кешегә азык-төлек ярдәме күрсәтергә тотылды. Өстәп, тагын 5,5 тонна ризык фитыр рәвешендә мохтаҗларга таратылды.

8. Ел саен рекордлар куя торган Республикакүләм ифтар быел да яңа үрләргә иреште һәм Рамазан аеның истә калырлык олы вакыйгасы булды: аның кысаларында Татарстанның 40 районына һәм Казанның 60 мәчетенә, 30 мең мохтаҗ кешегә тарату өчен, ифтар җыелмалары тапшырылды, 500дән артык ихтыярчы җәлеп ителде. Мөхтәсибәтләр тырышлыгы белән, тагын 90 мең кешегә азык-төлекләтә ярдәм күрсәтелде. «Ярдәм» мәчете тарафыннан тормышка ашырылган «Дорога жизни» акциясе шулай ук зур масштабта үткәрелеп, 60 мең мохтаҗ кешене ифтар җыелмалары белән тәэмин итте.

# Тарих

# Ни өчен Казахстанда татарлар күп яши?

Казахстанда беренче таш йортны татарлар төзегәнен белә идегезме? Ә Яушевлар династиясенең икътисадка гына түгел, ә үзләренең яңа ватаннарының мәдәни үсешенә дә йогынты ясаганын?

Ә казах җирлегендәге татар мәчетләренең үзенчәлекләрен беләсезме? Ә татарларның Казахстан территориясенә ничек эләгүе турында уйлап караганыгыз бармы? Белмисезме, алайса без сезгә татар халкы һәм аның туган республикабыз гына түгел, дөньяның башка илләре тормышында тоткан роле турында сөйләүне дәвам итәбез.

Тарихи риваятьләргә карасак, татарлар Казахстан җирләренә XVII йөз азагында күченә башлыйлар. Әмма тирәнрәк казып карасак, татарларның Даладагы (Казахстанда) тарихы, Алтын Урда оешканчы ук, X-XIII гасырларда ук башланган булуын белергә мөмкин. Һәм шушы озак еллар бергә яшәп, бу ике тугандаш республика халыклары якынайды һәм туганлашты.

## Татарлар һәм Дала

Нәкъ менә татарлар төркиләрдән беренчеләрдән булып утрак тормышка күчкәннәр. Безгә килеп җиткән тарихи язмалардан чыгып, XVII йөзнең беренче яртысында ук, Уральскида Татар бистәсе формалаша башлавын беләбез. Анда, казахлардан тыш, игенчелек, һөнәрчелек, сәүдә белән шөгыльләнүче татарлар килеп урнашалар.

XVII йөзнең икенче яртысында Әстерхандагы татар сәүдәгәрләре 1640 елда нигезләнгән Түбән Җаек шәһәрчегенә (хәзерге Атырау шәһәре) килә башлыйлар. XVIII йөзнең беренче яртысында татарларны, казах ханнарының язып баручы һәм тәрҗемәчеләре буларак, Даланың башка төбәкләрендә дә күреп була.

## XVIII гасырда Казахстанда татарлар барлыкка килү нәрсә белән аңлатыла соң?

Тикшеренүчеләр моның сәбәпләре күп дип сөйли, ләкин беренче чиратта, 1731 елда Кече һәм Урта Җүчинең Рәсәй империясенә кушылуы турында искә алырга кирәк. Шул вакыттан алып татарларның Казахстан җирендә яшәүчеләргә тормышның барлык өлкәләрендә дә: икътисадтан башлап, мәдәнияткә һәм мәгарифкә кадәр йогынтысы арту хисабын алып барырга мөмкин. Мәсәлән, татар халкы яшәү урыннарында беренче татар мәктәпләре, рәсми рәвештә күпкә соңрак теркәлгән булуларына карамастан, XVIII гасырда ук барлыкка килә.

XIX гасыр ахырында татар мәдрәсәләре Казахстанның барлык эре шәһәрләрендә һәм татар торак пунктларында диярлек эшләп килгән. Татар мәктәпләрендә татарлар гына түгел, казахлар да күпләп укый. Бу эштә ике халыкның телләре якынлыгы да, шулай ук татар халкының югары дәрәҗәдә белемле булуы да, җирле халыкка булган белемнәрне җиткерергә ашкыну да ярдәм итте.

Семипалатинскта, 60 нчы еллардан алып, XVIII йөзнең 90 нчы елларына кадәр, эшкуар татарлар Полковничье ярымутравындагы Меновой бистәсе территориясендә урнаша. Иртышның көчле ташкыннары аркасында 1798 елда бистә яңа урынга күчерелә, соңрак ул Татар бистәсе дип атала башлый, анда сәүдәгәрләр кунакханәләр һәм Казахстандагы Татар бистәсенең мәҗбүри атрибуты булган мәчетләр төзегәннәр. Тиздән бу бистә шәһәрдә иң зур бистәләрнең берсе булачак һәм нигездә рус халкы яшәгән крепость форштады белән көрәшәчәк.

XVIII-XIX гасырларда татарлар казах даласының бөтен территориясенә диярлек тарала. Аларның гомуми саны 50 меңнән артык кешегә җиткән.

## Татарлар һәм казахлар – ике тугандаш халык

Халыкның үз вакытлы матбугатыннан башка яшәвен күз алдына да китереп булмый. Безнең очракта да шулай булды. Нәшриятның югары ноктасы революция һәм революциядән соң чорга туры килде. XX гасыр башында казах даласында мөселманнар арасында театр хәрәкәте дә популярлаша башлый. Башта анда Казаннан килгән «Сәйяр», «Нур», «Ширкәт» труппалары гастрольләрдә булган, алар еш кына җирле татарларны зур булмаган рольләргә җәлеп иткәннәр, соңыннан алар Акмолинск, Петропавловск, Верный, Кустанай һәм Семипалатинск кебек шәһәрләрдә театр труппалары төзү инициаторлары булганнар.

Татар һәм казах халыкларының бәйләнышлары турында сөйләгәндә, ике тугандаш халыклар арасындагы элемтәләрне ныгытуга, мәгърифәтчелек эшчәнлегенә бар көчләрен керткән кешеләр турында искә төшермәү мөмкин түгел. Болар – татар шагыйре Нури Арсланов (1912-1991), публицист һәм драматург Әкрам Галимов (1892-1913), тарихчы Корбангали Халиди (1846-1913), журналист һәм җырчы Камил Мотыйгый (1883-1941), рәссам Макмун Сутюшев (1906-1990) һәм башкалар.

Шәһәрләр үсеше, Урта Азия ханлыклары һәм Кытай белән сәүдә итү аша Далада татар сәүдәгәрләренең саны шактый арта. Татар сәүдәгәрләре һәм сәнәгатьчеләре шәһәр үзидарәсендә актив катнашалар һәм даими рәвештә Дала шәһәрләренең шәһәр думасына сайланалар. Татар халкының шушы үзенчәлеге белән бәйле рәвештә XIX гасырда һәм XX гасыр башында казах даласында татар буржуазиясенең көчле катламы формалашуы гаҗәп түгел. Ул тиздән социаль ярдәмгә, рухи инфраструктураны төзүгә зур өлеш кертәчәк, шулай ук шәһәрләрнең иҗтимагый тормышына сизелерлек йогынты ясаячак.

*Ильмира Гафиятуллина*

# «Японияда Исламия Мәктәбе»: японлыларның мөселман-татарларына мөнәсәбәте




**Япон һәм татар телендә язучы «Исламия Мәктәбе» укучылары. Фото Япония матбугатыннан, 1938 ел**

Әлеге мәкаләдә без Япониядәге беренче мөселман уку йорты – «Исламия Мәктәбе» турында сөйләүне дәвам итәбез. Һәм мөселман-татар халкының җирле халык белән булган үзара мөнәсәбәтләренә тукталырбыз.

«Исламия Мәктәбе» Токиода башлангыч мөселман мәктәбе буларак ачыла. Төрки-татар җәмәгатьчелеге Япония хөкүмәтеннән уку йортын урта мәктәпкә, хәтта югары мәктәпкә хәтле җиткерергә рөхсәт сорый. Мәктәптә алты еллык башлангыч укытулар була. Моңа өстәп, соңрак, укытучылар әзерләү өчен, тагын ике сыйныф өстәлә. Шул рәвешле, мәктәп сигез класслы уку йортына әйләнә. Ул, күченеп килүче татар-мөселман халкының, Ерак Көнчыгыштагы иң яхшы мәктәпләренең берсенә әйләнә. Биредә күркәм рәвештә дини һәм милли темага дәресләр бирелә, япон, инглиз, рус телләре укытыла.




**Икееллык укытучылар курсларында белем алучылар. 1932 ел**

Мәктәп тарихы Идел һәм Урал якларыннан күченеп килүчеләрнең Япония башкаласының үзәгендә урнашкан Шин Оукобо районында өч зур булмаган бина арендалау белән башлана. Аннары уку йорты Оукобо һәм Касиваги районнарына күчә. Ниһаять, 1931 елның гыйнвар аенда, җәмәгатьчелек тарафыннан Йойоги Томигая районында төзелгән үзләренең шәхси биналарында төпләнәләр. Бинада аерым мәчет төзелгәнче җомга һәм бәйрәм намазлары биредә үтә.

Мәктәп бинасы Токионың иң дәрәҗәле районнарының берсендә салына. Ул император Мейдзи паркыннан ерак булмаган урында була. Әлеге районда югары дәрәҗәле хәрби хезмәткәрләр, дәүләт түрәләре төпләнә. Укучылар, гадәт буенча, җомга көнне һәм мөселманнарның

бәйрәм көннәрендә ял итә. Бу көннәрдә мәктәп мәчеткә әйләнә, ирләр имам белән берлектә җәмәгать намазларын башкара.

Укучылар үзләренең махсус мәктәп формасыннан һәм йолдыз белән көмеш ярымай тамгасы куелган түштамгадан йөри. Иртән японлылар ерактан ук, Токионың төрле районнарыннан килүче кечкенә мөселманнарны күреп таный торган була. Балаларның Аурупача тышкы кыяфәте, мәктәп формасы һәм үзенчәлекле значоклары аларның кемнәр икәнен ачыклауда авырлык тудырмый.




**Токиода «Исламия Мәктәбе» укучылары. 1937 ел**

Мәгариф һәм тимер юллар министрлыклары карары буенча укучылар юлда йөрүдә айлык яки еллык ташлама хокукына ия була. Шуңа күрә күп укучылар мәктәпкә трамвайда яки метрода килеп йөргән.

«Исламия Мәктәбе» укучылары бик еш төрле экскурсияләргә йөри, аларны Япониянең мәктәпләрендә үткәрелгән чараларга, бәйрәмнәргә чакыралар. Мәктәптә шулай ук чит шәһәрдән килгән укучылар да белем ала. Алар токияле мөселманнарның гаиләләрендә яши. Бары тик каникулларда гына ике атнага әти-әниләре янына кайталар. Бик еш японлыларның укучыларны туктатып, кайдан икәнлекләре: мөселманнар җәмәгатьчелегеннән булу-булмаулары турында сораштырып, балаларга карата ярату һәм хөрмәт хисләрен белдерүләрен күзәтергә туры килә.




**Мәктәп значоклары**

Японлылар «Исламия Мәктәбе» укучыларын фотога төшереп, үзләренең газета, журналларына, почта открыткаларына куллана торган булалар. Мәктәп, үзенең белем алучылары белән, бөтен Япониягә таны-

ла. Бик күп японияле балалардан, шул исәптән, Хоккайдо, Сахалин (1945 елга кадәр Сахалин утравының яртысы Япониянеке була) һәм Тайвани утрауларыннан «Исламия Мәктәбе» укучыларына хатлар килә башлый. Балалар үз хатларында дуслыкларын тәкъдим иткәннәр, мөселман балаларыннан Ислам турында сөйләүләрен сораганнар.

Мәктәптә оештырылган тантаналы табыннарда Япониянең танылган сәяси һәм иҗтимагый эшлеклеләре чыгыш ясый. Кунаклар арасында Япония министрлары, министрлык департаменты башлыклары, язучылар, хәрби кешеләр һ.б. була. Бу – япониялеләрнең татар-мөселман җәмәгатьчелегенә карата булган яхшы мөнәсәбәтенең ачык мисалы.

*Мөхсин Нурулла,*
*islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә*

# Мирас

# Ислам – безнең тарихыбызда һәм мәдәниятыбызда

Дистәләгән еллар дәвамында безнең тормышыбызда атеистик идеология хакимлек итте, һәм ул халкыбызның аңыннан ислам динен куу өчен бөтен тырышлыгын куйды. Шушы максатларда официаль пропаганда ислам диненең кануннарын бозып күрсәтергә тырышты, аңа пычрак атылды, аның барлыкка килүе, тарихы һәм җәмгыять тормышындагы роле бозып күрсәтелде. Бу пропаганданың асыл максаты ничек кенә булса да, исламны җәмгыять тормышында һичнинди позитив роль уйнамаган реакцион күренеш итеп күрсәтүгә кайтып кала иде. Бу пычрак пропаганда исламны, аның тарафдарларын сәяси эзәрлекләүләр белән беркетелде һәм көчәйтелде.

80 нче еллар азагында илдә җәелгән процесс дингә, шул хисаптан, исламга карата да яңача карау мөмкинлеге тудырды. Ислам – безнең тарихыбызга бик борынгыдан кергән һәм халкыбызның тормышында зур роль уйнаган идеологик юнәлеш. Бу мәкалә шушы тарихны һәм исламның мәдәни үсешебездә уйнаган ролен ачыклауга багышлана.

922 елда Идел буена Багдад хәлифәлегенең илчелеге килә һәм, шушы уңайдан үткәрелгән тантаналар вакытында, ислам – Аурупаның көнчыгышында формалашып килә торган яңа дәүләтнең — Идел-Кама Болгарстанының рәсми дине, дип игълан ителә. Бу акт безнең бабаларыбыз — болгарларның исламга күчү процессының йомгагы була. Ә процесс үзе күпкә алданрак башланды. Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр») дигән хезмәтендә болгарларның исламга бу актка кадәр үк тартыла башлаулары турында сөйли торган ышанычлы дәлилләр китерә һәм алар арасында дәвалаучылар кыяфәтендә дингә өндәүчеләр йөрүен әйтеп үтә. Ул болгарларның гарәпләр белән аралашулары гарәп-хәзәр су-

гышлары вакытында ук башлану мөмкинлегенә ишарә ясый. Шушы характердагы фактларны һәрьяклап тикшергәннән соң, ул болгарларның исламга күчә башлаулары Һарун Әр-Рәшид һәм Мәэмүн хәлифәләр идарә иткән чорларга туры килә дигән фикерне әйтә.[1] Бу хәлифәләрнең беренчесе – 786-809 елларда, ә икенчесе 813-833 елларда идарә иткән булалар. Димәк, болгарлар Исламга VIII гасырның азагында һәм IX гасырның башында ук күчә башлыйлар. IX гасырда болгарлар арасында ислам йолаларының яхшы ук киң таралуы турында археологик тикшеренүләр дә сөйли һәм, ниһаять, фарсы географы бине Рустәнең болгар авылларында мәчет-мәктәпләр булуы турында язып калдырган хәбәре. Бу хәбәр дә IX йөзнең ахырына карый.

Әлбәттә, инде IX гасырда ук бөтен болгар халкы мөселман була, дип әйтергә ярамас. IX йөздәге болгар зиратларында әле мөселманнар белән мәҗүсиләрнең каберләре аралашып ята. Бу турыда Е.А. Халикова үзенең «Мусульманские некрологи Волжской Булгарии» дигән хезмәтендә ачык дәлилләр китерә (Казань, 1986). Ш.Мәрҗани китергән һәм болгарларның исламга Һарун Әр-Рәшид һәм Мәэмүн хәлифәләр заманында күчүләре турында сөйләгән чыганаклар, мөгаен, болгарларның аерым төркемнәрен күздә тота булыр.

Русьның христианлыкны кабул итүенә багышлап чыгарылган бер мәкалә «Выбор князя Владимира» дип исемләнгән иде. Русьтан аермалы буларак, болгарларның исламны кабул итүе аларның патшасының шушы динне башлап сайлавы нәтиҗәсе түгел иде. Алар халык буларак үзләре акрынлап шушы дингә тартылдылар. Башта аларның бер группалары, соңыннан башкалары үзләре шушы динне кабул итте. Алмуш ханның исламны формалашып килә торган дәүләтнең официаль дине дип игълан итүе шушы тарихи агышның табигый йомгагы булды.

---

1 Мәрҗани Ш. «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар», т.1, Казан, 1897, 52-57 б.

Болгарларның исламны кабул итүенә алардагы социаль-экономик һәм рухи үсеш китерә. Шуның белән аларның нәкъ менә исламны кабул итүләрендә алар арасында мәҗүсилек заманында таралган ышанулар да үз ролен уйнадылар. Башка төрки халыклардагы кебек үк, болгарлар арасында да тәңре идеясе киң таралган була. Шушы идеологиянең үсеше, әйтергә кирәк, болгарларны бер илаһлык идеясен кабул итүгә турыдан-туры китерә дә. Ә бер илаһлык идеясе ислам догматикасының асылын тәшкил итә. Әле хәзер дә татарлар арасында тәңре төшенчәсенең ходай төшенчәсе белән беррәттән Аллаһының синонимы булып кала бирүе шуңа күрә очраклы хәл түгел.

Әйтелгәннәр – болгарларның нәкъ менә исламны кабул итүенең эчке сәбәпләреннән. Әмма моның тышкы сәбәпләре дә бар. Болгарларның якын күршеләре славяннар һәм угыр-фин кабиләләре бу вакытта мәҗүсилектә булалар. Христианлашкан Аурупада грек-рим чоры мирасы онытылган, ә кешеләрнең аңында схоластика сөреме киң таралган була. Ә гарәп-мөселман дөньясы исә IX-XI гасырларда үзенең чәчәк ату чорын кичерә. Бу чорда анда бик интенсив рәвештә антик дөнья калдырган мирасны үзләштерү процессы бара иде. Антик чорның Сократ, Платон, Аристотель, Плотин, Пифагор, Эвклид, Гиппократ кебек зур акыл ияләренең әсәрләре гарәп теленә тәрҗемә ителә. Фәлсәфә буенча зур-зур трактатлар, фәнни хезмәтләр языла, әдәбият һәм эстетик фикер үсә, шәһәр тормышы кайный. Гарәпләрнең бу казанышлары бабаларыбызның игътибарын үзенә җәлеп итми калмый һәм, исламны кабул итү өчен, билгеле бер алшарт тудырды.

Ислам болгарлар тормышында һәм аларның варислары Идел буе татарларның тарихи язмышында әһәмиятле һәм күпьяклы роль уйный. Бу турыда сүз алып барганда, беренче чиратта, идеологик система буларак, исламның үзенчәлекләрен күз алдына китерү зарур. Ислам – дөньякүләм таралган диннәрнең берсе. Башка диннәр кебек үк аңа үзенең

догматикасы, кагыйдәләре һәм символикасы хас. Әмма башка диннәрдән аермалы буларак, исламның эчтәлеге бу догматика, норма һәм символлар белән чикләнми. Исламның башка ягы да бар. Ул киң планлы һәм күпкырлы мәдәни-идеологик система, дөньяга карашның тулы бер формасы. Үзенчәлекле идеологик система буларак, ул үзенә, дини карашлар белән беррәттән, фәлсәфи төшенчәләр системасын да, социаль һәм этик концепцияләрне дә берләштерә. Ислам шулай ук – җәмгыятьнең тормышын, кешеләрнең көндәлек эш-гамәлдә үзләрен тотышларын, аларның үзара мөнәсәбәтләрен билгеләүче кодекс та. Мөселман дөньясында иҗтимагый-политик һәм фәлсәфи мәсьәләләрне хәл итү, аларның таралышы ислам билгеләгән тышчаларда бара.

Фикһ гыйлемен алып карыйк. Фикһ гыйлеме, гадәттә, исламның хокук тәгълиматы рәвешендә характерлана. Әмма фикһ чынлыкта бер хокук мәсьәләләре белән генә чикләнми. Ул үзендә җәмгыять теориясенә кагылышлы бик күп проблемаларны берләштерә. Хокук мәсьәләләре белән беррәттән ул шулай ук фәлсәфәне дә, илаһи тәгълиматны да, сәясәтне дә, әхлак мәсьәләләрен дә, мантыйкны да, тел гыйлемен дә тикшерә. Шәригать белән дә эш шулай тора. Гадәттә, соңгысын хокукый һәм әхлакый нормалар җыентыгы сыманрак күз алдына китерәләр. Әмма, киң планда алганда, шәригать үз алдына кеше яшәешенең бөтен якларын да яхшылык-яманлык күзлегеннән чыгып классификацияләү бурычын куя. Шуның белән бергә ул үз алдына кеше яшәешенең иң төп сәбәпләрен ачу, аның универсум белән бәйләнешен һәм табигатен өйрәнү вазифаларын да куя. Димәк, фикһ гыйлеме дә, шәригать тә иҗтимагый, фәлсәфи, хокукый һәм әхлакый проблемаларның барысы белән дә кызыксыналар һәм аларга җавап бирергә тырышалар. Исламның болгар-татар тарихында тоткан урыны аның шушы киң масштаблы мәдәни-идеологик система булуы белән билгеләнә дә.

Хәзер болгарларның исламны кабул итүләренең әһәмиятен күрсәткән кайбер факторларга тукталыйк.

Болгарларның Урта Иделдә ныклап тамыр җәюе Идел-Кама регионында Болгар дәүләтенең формалашуы белән янәшә бара һәм ислам бу дәүләтнең идеологик һәм хокукый нигезләре вазифасын үти. Болгарларның исламны кабул итүенең әһәмияте, беренче чиратта, шушының белән билгеләнә дә. Дәүләт дине дип игълан ителгәч, ул аерым кабиләләрнең мәҗүсилек белән бәйләнгән йолаларына каршы көрәшне уңышлырак башкара башлый һәм бу кабиләләрне бердәм дәүләт власте тирәсенә туплауга ярдәм итә.

Ислам шулай ук болгарларның, аларга якын башка төрки һәм төрки булмаган кабиләләрнең бердәм кавем-милләт булып берләшүенә идеологик алшарт була һәм болгарларның бу динне кабул итүенең икенче зур әһәмияте – шунда. Болгарларның элеккеге мәҗүсилек диннәре аларны берләштерү юлында ныклы терәк була алмый. Моның өчен аның идеологик нигезләре дә, оешмасы да булмый. Ислам исә, идеологик яктан да, оешу ягыннан да нык үскән дин буларак, болгарларда бердәм мәдәният формалашуга нигез ташлары сала һәм алар арасында барлыкка килгән милли үзаңның аерылгысыз компонентына әйләнә. Ул формалашып килүче бу халыкны идеологик яктан берләштерә, болгар җәмгыяте әгъзаларын бер-берсенә өзелмәслек җепләр белән бәйли һәм бу милләткә дәүләтләре юкка чыкканнан соң да, башка исем астында булса да, үзен саклау мөмкинлеген ача.

Исламны кабул итү болгар җәмәгатьчелеген ул вакытта дөньякүләм алдынгы позициядә торган гарәп-мөселман мәдәниятына якынайта. Болгарларның бу мәдәният белән танышлыгы әле исламның Урта Иделдә рәсми дин итеп игълан ителүенә кадәр үк, болгарлар арасына ислам үтеп керүнең беренче адымнарыннан ук башлана. Гарәп чыганакларында сакланып калган бер хәбәр шул турыда сөйли. Бу хәбәрне язып

калдырган автор гарәп-мөселман мәдәниятының күренекле вәкиле Әл-Җаһизны үзенең 200 биттән торган һәм болгар ханына адресланган хатында Аллаһының Китабы турында бер сүз дә әйтмәүдә гаепли. Бу факт болгарларның инде IX гасырның беренче яртысында ук (Әл-Җаһиз шул чорда иҗат итә) гарәп дөньясы белән дини бәйләнешләр белән генә калмыйча, мәдәният мәсьәләләре буенча да күпкырлы бәйләнешләргә кергән булулары турында сөйли. Ислам дәүләтнең официаль дине итеп игълан ителгәч, болгарлар белән Багдад хәлифәлеге арасында икътисад һәм сәүдә өлкәсендә дә, сәясәт һәм идеология өлкәсендә дә ныклы элемтәләр урнаша. Нәтиҗәдә, Идел буена ул заманда гарәп дөньясында үсеш алган фәнни-фәлсәфи идеяләр һәм әдәби әсәрләр үтеп керә.

Ислам кабул ителгәч, моңа кадәр болгарлар арасында таралган чөй (рун) язуы гарәп язуы белән алыштырыла һәм болгар язма әдәбиятының нигез ташлары салына. Гарәп телен һәм язуын белү Идел-Чулман буйларыннан чыккан төркиләргә гарәп телендә иҗат ителгән бай әдәби мирас белән танышу мөмкинлеген ача. Ә бу, үз нәүбәтендә, болгарларда фәнни-фәлсәфи фикер тууында, болгар мәдәниятының вә мәгрифәтенең үсүендә, әдәбият ядкәрләре иҗат итүдә мөһим роль уйный. Тарих безгә шәех Әхмәд Әл-Болгари, Әбү бине Идрис Әл-Болгари, Борһанетдин Ибраһим бине Йосыф Әл-Болгари, Әбү Мөхәммәд Садыр бине Галәветдин Әл-Болгари, Хуҗа Хәсән Әл-Болгари кебек олы галим вә фәлсәфәчеләрнең исемнәрен китереп җиткерә.[1] Бу мөтәфәккирләрнең хезмәтләре Болгарстанның үзендә дә, шулай ук аннан читтә дә киң таралган була.

Ягъкуб бине Ногъман Әл-Болгариның әле XI гасырда язылган «Тәварихе Болгария» исемле китабы турында, мәсәлән, гарәп сәяхәтчесе һәм укымышлысы Әбү Хәмид Әл-Гарнати һәм киң диапазонлы галим Зәкәрия Казвини бик җылы сүзләр язып калдыралар. Фәлсәфә, илаһият гыйльме (богословие), тарих, медицина һәм фармокологиядән тыш, бол-

1 Мәрҗани Ш. Мөстәфад ал-әхбар… т.1. Казан, 1897, 78-83 б.

гар галимнәре астрономия һ.б. бик күп фәннәр белән дә шөгыльләнәләр. Әл-Гарнати калдырган мәгълүматларга караганда, болгар галимнәре, күк җисемнәре турында тикшерүләр алып бару максатыннан төньякка бик еракларга барып җитә торган булалар. Әле монгол яуларына кадәр үк болгар әдәбиятының Кол Гали язган «Кыйссаи Йосыф» кебек гүзәл әсәрләре иҗат ителә.

Мәдәниятның мөһим өлешләреннән берсе – мәгърифәт. Ислам канаты астына тартылу болгар-татар мәдәниятының бу мөһим өлешенең нигез ташларын салуга да мөмкинлек тудыра. Исламны кабул иткәч үк болгарлар арасында уку-укыту эшендә билгеле бер система туа. Мәчетләр каршында яшәп килгән мәктәп-мәдрәсәләрдә, дин сабаклары белән беррәттән, дөньяви гыйлемнәр укытуга да әһәмият бирелә. Әл-Гарнатиның ерак Андалусиядән үзенең улын Болгарга укытырга алып килүе үзе генә дә бу илдә уку-укыту эшләренең яхшы ук югарылыкта торуы турында сөйли.

Уку-укыту эшләрендә Болгар чорында урнашкан бу традиция Алтын Урда дәверендә дә, Казан ханлыгында да дәвам итә. Ш.Мәрҗани ул вакытта Казанда зур мәдрәсә эшләве турында яза. Бу мәдрәсә шәкертләренең ул замандагы гыйлемнәрнең тулы комплексын өйрәнергә мөмкинлекләре була. Әле болгар чорында урнашкан традиция буенча һәр мәчет каршында мәктәп эшли. Уку йортлары Казан ханлыгының авылларында да күзәтелә. М.Худяков язуына караганда, ул вакытта Адай авылы мәдрәсәсе бик данлыклы була. 35 ел дәвамында аның мөдәррисе булып Иш-Мөхәммәд бине Туг-Мөхәммәд эшли. Бу мәдрәсә озак еллар яши һәм үзенә бик күп укучылар тарта.[1]

Ислам мәдәнияты – үзенең асылы белән шәһәр мәдәнияты. Ислам мәдәниятының бу үзенчәлеге Идел-Чулман Болгарстанында да үзен сиздерә. Биредә дә күп кенә шәһәрләр барлыкка килә һәм үсә. Бу шәһәрләр материаль һәм рухи мәдәният учакларына әйләнәләр. Идел-

1 Худяков М. «Очерки по истории Казанского ханства», Казань, 1923. С. 162.

Чулман Болгарстаны территориясендә археологлар тарафыннан 150 дән артык шәһәр калдыклары табыла.[1] Бер-бер артлы Болгар дәүләтенең башкалалары булып торган Болгар һәм Биләр шәһәрләре бигрәк тә нык үсәләр. Соңгысы, мәсәлән, үзендә яшәгән халыкның саны һәм территориясе буенча ул заманның иң эре шәһәрләреннән саналган Киев, Париж һәм Владимирны узып китә. Идел-Чулман Болгарстанының шәһәрләрендә мәһабәт архитектура корылмалары калкып чыга, сарайлар, мәчетләр, үзәк җылыту системасы булган таш пулатлар салына. Шәһәрләр үсеше исә рухи тормышның да үсүенә китерә.

Шәһәрләр үсеше белән, шулай ук, җитештерү көчләренең, кәсебчелекнең, һөнәрчелекнең, сәүдәнең үсүе дә бәйләнгән. Болгарстанда кара металлургия туа һәм камилләшә, чүлмәкчелек һәм күн эшкәртү һөнәре үзенең үсешендә яңа адымнар ясый, тимерчелек осталыгы яңа баскычлар яулый. Болгарлар инде XIV гасырда ук, Аурупада беренче булып, чуен кайната башлыйлар.

Ислам кабул итүнең, болгар сурәтләү сәнгате өчен, нәтиҗәләре үзенчәлекле һәм каршылыклы була. Ислам, билгеле булганча, кеше вә хайваннарның сурәтләрен ясауны хупламый. Шунлыктан, исламны кабул иткән болгарлар арасында кеше һәм хайван образларын сынлы сәнгать чаралары белән гәүдәләндерү туктый. Ә мондый сәнгать аларда ислам кабул иткәнче яхшы ук үскән була. Шул ук вакытта сәнгатьнең гамәли төрләре, мәсәлән, ювелирлык сәнгате, күнгә һәм тукымага чигү, бизәү сәнгате яңа үсеш ала. Кулъязма китаплар тарату бизәү сәнгатенең яңа төрләре, аерым әйткәндә, китап бизәү һәм каллиграфия язмалары тууга һәм үсүгә китерә. Гарәп-мөселман дөньясы белән алыш-биреш итү архитектура үсүенә дә яңа этәргеч ясый. Сәнгать иҗатының яңа төре — кабер ташларын бизәү барлыкка килә һәм зур үсеш ала. Төрки халыкларда таш

1 Р.Г.Фахрутдинов. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория. Казань, 1975, с.190-191.

һәм башка төрле билгеләр кую күптән килгән традиция. Орхон-Енисей һәйкәлләре һәм кыпчак далаларында очрый торган балбаллар шул турыда сөйли. Болгарларда бу традиция каберләр өстенә матур итеп бизәлгән ташлар кую рәвешендә үстерелә. Бу ташларда болгар бабаларыбызның яшәеш проблемасы тирәсендә кичергән әхлакый һәм эстетик фикерләре үзләренең чагылышларын таба.

Мәсьәләнең тагын бер аспекты – исламны кабул иткән болгарларның җәмгыять тормышының әхлакый нигезләренә булган карашларында үзгәрешләр. Диннәрдә теге яки бу рәвештә гомумкешелек әхлак нормалары үзләренең чагылышын таба. Алар гаделлек, мәрхәмәт, шәфкать, мәхәббәт, инсанилык (гуманизм), әхлакый камиллелек идеалларын алга сөрә. Бу исламга да кагыла. Болгарлар арасында тарала башлау белән, ислам иҗтимагый яшәеш мәсьәләсендә мәҗүсилек дәверендә урнашкан карашларга каршы эзлекле көрәш алып бара, кыргыйлыкны, шәфкатьсезлек һәм көчләү күренешләрен гаепли, яңа әхлакый принциплар таралуы өчен тырыша. Бу болгар-татарларның тормышына күпкырлы тәэсир ясый, аларны әхлакый үсештә яңа баскычларга күтәрә, тарихларына һәм тормыш-көнкүрешләренә яңа эз сала.

## Ислам кабул итүнең халыкның алдагы язмышында, үзен этник бердәмлек буларак саклый алуында уйнаган роле

XIII гасырдан башлап Идел-Чулман буйларына кабат-кабат биниһая авыр җәбер-золым ябырыла, ил өстеннән давыл-өермәләр үтә, халык коточкыч тетрәнүләр кичерүгә дучар ителә. Мондый дәһшәтләрнең беренчесен монгол яулары китерә. Бату хан гаскәрләре Болгарстан җирендә җимерелгән шәһәрләр, яндырылган авыллар, тапталган кырлар калдыралар, иксез-чиксез кеше каны коела. Шулай да Идел-Чулман Болгарстаны халкы үзен саклап кала ала. Соңыннан да Чыңгызхан токымнары Болгар

җиренә кабат-кабат ябырыла. Бу урыс князьләренең һәм Түбән Новгород ушкуйникларының – юлбасарларның һөҗүмнәре белән чиратлашып бара. Шушы һөҗүмнәр нәтиҗәсендә Болгар тәмам җимерелгәннән соң да, бу халык Чулманның төньягында яңа җир эшкәртү һәм һөнәрчелек үзәкләре тудыра, үзенең традицион мәдәниятын үстерә. Бу шартларда ислам халыкны берләштереп тотучы, аның этник бөтенлеген һәм үзенчәлеген саклауда хәлиткеч роль уйный торган куәтле бер көч була.

Ислам мәдәнияты вәкилләре буларак, болгарлар, Хәрәзем белән бергә, Алтын Урда мәдәниятының формалашуында да, ул биләгән киң далаларда яңа һөнәр һәм сәүдә үзәкләре барлыкка килүдә дә хәлиткеч роль уйныйлар. Ахыр чиктә бу далада яшәгән мәҗүси кабиләләр нәкъ менә Болгар һәм Хәрәзем тәэсирендә ислам кабул итәләр дә.

Казанның Явыз Иван тарафыннан яулап алынуы борынгы болгарлар токымы – инде рус чыганакларында татарлар дип атала башлаган халыкка яңа авыр сынаулар китерә. Рус тарихчысы М.Худяков бу яулап алу вакытында Казан халкы өстенә биниһая җәбер-золымнар төшүен, күп халыкның кырылуын, монда туган материаль һәм рухи мәдәният ядкәрләренең юкка чыгарылуын күрсәтеп үтә. «Чудовищное избиение жителей взятой Казани, – дип яза ул, – составляет одну из самых тяжелых страниц русской истории... Колосальною гекатомбою человеческих жертв закончился «крестовый поход» христолюбивого воинства против казанцев... Кроме огромного количества человеческих жизней, насильственно унесенных в могилу, кроме бесчисленных слез, страданий и горя, пережитых казанским народом, печальный день 2 октября (день покорения Иваном IV Казани в 1552 г. – Я.А.) знаменовал собою гибель материального благосостояния, накопленного целыми поколениями и утрату культурно-бытовых ценностей, которые теперь были – безжалостно извлечены из укромных уголков, где они бережно сохранялись, без сожаления

были изломаны, изуродованы, потеряны, уничтожены».[1] Икенче бер рус тарихчысы, Казан университеты профессоры Н.Н.Фирсов басып алынган халыкка карата патша самодержавиясенең сәясәтен тасвирлап болай дип яза: «С внедрением в Казанский край дворянства и монастырей начались систематические религиозные гонения. Эти гонения начал сам завоеватель Иван IV, находившийся под сильным влиянием православного духовенства, он разрушил татарские мечети и запретил их возобновлять, Московское духовенство выступила здесь настойчивой миссионерской ролью, стремясь увеличить количество пасомых – базы, эксплаутации».[2]

Нигезе Явыз Иван тарафыннан салынган бу милли кысу һәм эзәрлекләүләр патша хөкүмәте тарафыннан татарларга карата гасырлар буена үткәрелгән сәясәтнең үзәгендә ята. КПССның X съезды үзенең резолюциясендә «политика царизма, политика помещиков и буржуазии к нерусским народам состояла в том, чтобы убить среди них зачатки всякой государственности, калечить их культуру, стеснить язык, держать их в невежестве, и наконец, по возможности русифицировать их», – дип күрсәтеп үтә.[3]

Бу сәясәт Казан җирендә тулы чагылышын таба. Үзенең асылы белән ул ачыктан-ачык шовинистик характерда булды һәм болгарларның токымы булган татарларны мөстәкыйль халык буларак юкка чыгаруга юнәлдерелгән була. Бу максатта җирле халыкның теленә, диненә, мәдәниятына һәм гореф-гадәтләренә каршы көчле эзәрлекләү политикасы үткәрелә. Патша хөкүмәте һәм аның урындагы сатраплары татар халкына карата социаль, экономик, сәяси һәм хокукый басым режимы урнаштырдылар. Халык барысын да татый: нагайкасын да, төрмәсен дә,

1 Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. Казань, 1923. С. 153-154.

2 Фирсов Н.Н. Прошлое Татарии. Казань. 1926, с.26-27.

3 КПСС в резолюциях и решениях съездов, конференций и пленумов ЦК, часть 1, изд. 7-ое, Госполитиздат, 1953, с.558-559.

сөрген-себерләрен дә. Татарларга каршы хәрби командалар өстерелеп торыла, аларның җилкәсендә казак камчылары җитәрлек уйнаган, гыйбадәтханәләр һәм изге урыннар җимерелгән, милли хисләр һәм традицияләр мәсхәрәләнгән.

«Религиозные гонения, закрытие мечетей (один лишь епископ Казанской Лука Кашаневич в 1738-1755 гг. разрушил в Татарии 418 мечетей из 536) сопровождалось насильственным отбиранием детей мусульман в духовно-приходские школы».[1] Татарларның зиратларыннан кабер ташлары алынып, чиркәү һәм монастырьларның нигезенә салына, китапханәләр яндырыла, башка мәдәният учаклары һәм истәлекләре юкка чыгарыла. Шундый чаралар ярдәмендә патша самодержавиесе татарларның милли үзаңын юкка чыгарырга тырыша, аларның үз тарихларын, мәдәниятын, гореф-гадәтләрен онытуларына ирешергә тели.

Шундый җәбер-золымнарга карамастан, татар халкы үзен, үзенең милли үзенчәлекләрен, мәдәниятын, гореф-гадәтләрен, традицияләрен саклап кала ала. Бу очракта да без тулы ышаныч белән, халыкның милли аңының состав өлешенә әйләнгән ислам хәлиткеч роль уйнаган, дип әйтә алабыз. Халыкның милли мөстәкыйльлеген саклауда нәкъ менә ислам идеологик терәк вазифасын үти. Патша самодержавиесе һәм миссионерлар көчләп христианлык таккан бер чорда татарлар исламда үзләрен милләт буларак саклауда сыену урыны табалар, анда үзләренең этник, рухи һәм мәдәни бердәмлекләрен саклау чарасын күрәләр.

Татарларның милли үзенчәлекләрен саклауда мөселман мәктәпләре дә зур роль уйный. Идел буе татарлары, көчле эзәрлекләүләргә карамастан, уку-укыту мәсьәләләрендә әле Болгар чорында урнашкан традициягә тугрылыклы булып калалар, үзләренең барлы-юклы средстволары хакына мәктәпләр тоталар. Бу, үз чиратында, халыкта билгеле бер күләмдә укымышлылык тәэмин итә. Моны миссионерлар да танырга мәҗбур булалар.

[1] История гражданской войны в СССР, т.1, М.1935, с. 42.

«Православный благовестник» дигән журналда миссионерлардан берәү «сильно же магометанство прежде всего очень распространенной в магометанском населении грамотностью. Казанские татары — магометаны, почти все, за редькими исключениями, грамотны, очень ценят образование и заботятся о нем». Ахырда мәкаләнең авторы, шушының аркасында татарлар христианлаштырылуга бирелмиләр, дип зарлана.

Әйтелгәннәр исламның болгар-татар тарихында, самодержавиенең һәм миссионерларның басымына карамастан, этник бердәмлекләрен саклауда позитив роль уйнавы турында сөйлиләр. Әмма тормыш каршылыклы, иҗтимагый күренешләр дә күпкырлы. Тарихи агышның билгеле бер чорында берьяклы идеологик ориентация татар тормышында үзенең негатив якларын да күрсәтә башлый. Монда да патша хөкүмәтенең татарларга карата үткәрелгән сәясәте үзенең ролен уйный, бу политика татарлар арасында патриархаль мөнәсәбәтләрне консервацияләүгә, халыкны замана фәненнән һәм мәдәниятыннан ераклашуга этәрә, кешеләрне, милли бөтенлекне саклау өчен, тормышның инде артка калган формаларына һәм традицияләренә ябышып ятарга мәҗбүр итә, массалар арасында дин әһелләренең үткәнгә ябышып ятучы консерватив катламының тәэсирен көчәйтә.

Хәлне мөселман дөньясында соңгы гасырларда тамыр җәйгән күренешләр дә катлауландыра. Кайчандыр фән һәм мәдәният үсешенең алгы сызыгында торган бу дөнья тора-бара үзенең позицияләрен җуя. Кешеләрнең аңын тәкълидчелек сөреме биләп ала, үткән заманның бөекләре әйткәннәргә сукырларча ышану тамыр җәя, тәнкыйди фикер йөртү эзәрлекләнә башлый һәм хәзерге заман кешеләренең мөстәкыйль фикер йөртү мөмкинлекләре кире кагыла. Моңа фәнни-фәлсәфи эзләнүләрне тәкфирдә гаепләү өстәлә, догматизм, схоластика, фанатизм тамыр җәя. Бу күренешләр татарлар арасына да үтеп керә.

Акрынлап мөселманнарның үз араларыннан бу торгынлык һәм туңлык чиреннән арынуга, иҗтимагый яңарышка өндәүче көчләр үсеп чыга. Бу көчләрнең алдынгы сафында татар халкының уллары булалар. Габденнасыр Курсави (1776-1812) шуларның беренчеләреннән була. Ул ныклы дәлилләр белән тәкълидчеләргә каршы чыга, һәркемнең аек фикер йөртергә, иҗади эзләнүләргә хокукы барлыгын яклый. Г.Курсави эшен күренекле мәгърифәтчебез, тарихчы-галим һәм фәләсиф Шиһабетдин Мәрҗани (1818-1889) дәвам итә, тәкълид белән тәкфирне көчле тәнкыйть уты астында ала, кеше гакылына ирек даулый. Ш.Мәрҗанинның тәнкыйди методы халыкның тормыш юлында үткәннән калган киртәләргә каршы, аңа прогресска юл ачуга, аны фән, мәдәният, промышленность казанышларына якынайтуга юнәлдерелгән иде. Шул ук вакытта искәртеп үтәргә кирәк, Курсави да, Мәрҗани дә бу чыгышлары белән һич тә исламнан аерылмадылар, халык алдында туган проблемаларны дини позициядә торып анализладылар, үзләренең дәлилләрендә изге китапларга таяндылар.

Курсави белән Мәрҗани эшчәнлеге татар халкы тарихында тирән эз калдыра, үз халкы турында борчылучыларга, аның барыр юлларын ачыкларга тырышучыларга маяк вазифасын үти.

Үткәннән калган рухи мирасны яңадан бәяләүдә яңа адым җәдитчеләр тарафыннан ясый. Бу хәрәкәт безнең төбәктә узган гасырның соңгы чирегендә тамыр җәя һәм аның асылы Исмәгыйль бәй Гаспралы, Риза казый Фәхретдинов, Фатих Кәрими, Һади Максуди, Шәмсетдин Күлтәси, Рәшит казый Ибраһимов, Галимҗан Баруди, Муса Бигиев, Хәсән-Гата казый Габәши, Һади Атласи һ.б. эшчәнлегендә һәм иҗатында үзенең ачык чагылышын таба. Җәдитчеләр арасыннан татар революцион-демократиясенең Галиәсгар Камал һәм Гаяз Исхакый кебек вәкилләре, татар демократик мәдәниятының күренекле эшлеклеләре чыга.

Җәдитчелек асылда бик катлаулы иҗтимагый хәрәкәт була. Ул үзенә төрле тенденцияләрне һәм төсмерләрне туплаган була. Җәдитчелекнең эчтәлеге, аның вәкилләренең эшчәнлеге, алар үз алдына куйган бурычлар бу хәрәкәт үсешенең барлык баскычларында да бертөрле булып калмаган. Илдәге хәл үзгәрү белән бергә җәдитчеләр эшчәнлегенең эчтәлеге дә үзгәрә барган. Беренче адымнарында җәдитчеләр бары мөселман мәктәбенә һәм анда уку-укыту эшләренә үзгәрешләр кертү идеясе белән чыгалар. Җәдитчелек үзенең исемен дә мәктәптә яңа метод (ысулы җәдит) белән укытудан ала. Тора-бара җәдитчеләр иҗтимагый тормышның башка якларын үзгәртергә кирәклеген дә аңлый башлыйлар. Җәдитчелек үсешенең соңгы этабы инде чорның бөтен социаль һәм идеологик проблемаларын, шул хисаптан дини һәм илаһи тәгълимат мәсьәләләрен дә колачлый.

Җәдитчеләр эшчәнлеге нәтиҗәсендә татарлар арасында, дини әдәбият белән беррәттән, фәнни әдәбиятның номенклатурасы киң арта, татар телендә арифметика, география, физика, биология, гигиена, тарих һ.б. фәннәр буенча китаплар тарала башлый. Җәдитчелек хәрәкәте белән яңа, реалистик әдәбиятның беренче адымнары да, сәнгати фикердә тәнкыйди агым формалашу да, хатын-кызлар арасында эмансипация хәрәкәте дә нык бәйләнә.

Шулай да җәдитчеләр алдында торган проблемаларның иң мөһиме мәктәп мәсьәләсе, яшь буынны тәрбияләү мәсьәләсе була. Җәдитчеләр бу очракта милләтнең язмышы, аның киләчәге яшьләр кулында икәнлеген аңлап, яшь буынны ничек итеп тәрбияләүгә бәйләнгәнлеген күз алдында тотып эш итәләр. «Тәрәккыять заманыбызның иң зиядә дикъкать ителәчәк вә иң бөек гыйбрәт алыначак җәһәте дә, – дип яза Ш.Күлтәси, – ысул тәгълим вә тәдрис җәһәтедер... Шул ысул тегълим вә тәдрисләрне җиңеләйтү аркасында хәзерге заманның алга киткән мәмләкәтләре меңнәрчә галим-голәмә вә әдипләр, хакимнәр вә табиблар, йөзләрчә ин-

женер вә астрономнар, географлар вә тарихчылар, химия белгечләре һәм диңгезчеләр, сәясәтчеләр һәм яхшы хәзерлекле хәрбиләр, игенчелек һәм сәнагать белгечләре җитештерәләр».[1]

Мәктәп мәсьәләсендә җәдитчеләр белән кадимчеләр арасында бик кискен көрәш җәелә. Бу көрәш үз тирәсендә киң җәмәгатьчелек игътибарын да җәлеп итә. Кадимчеләр уку-укыту мәсьәләсендә иске тәртипләрне саклау тарафдарлары буларак чыгалар, ә бу эштә яңалык кертүне ислам кануннарыннан тайпылу дип саныйлар. Җәдитчеләр исә мәктәп эшендә реформа үткәрүне алга сөрәләр. Алар мәктәпләр эшенең мөселманлык таләпләренә нигезләнгән булырга тиешлегеннән һич кенә дә баш тартмыйлар. Әмма, мөселманлыкны саклау белән бергә, алар мәктәпне заман гыйлемен, фән казанышларын тарату учагына әйләндерү кирәклеген дә алга сөрәләр. Җәдит мәктәпләрендә дин сабаклары белән беррәттән татар һәм урыс телләре дә, математика да, тарих та, география дә, башка дөньяви фәннәр дә укытыла. Шулай итеп, җәдитчеләр, мөселманлыкка тугрылыкны саклаган хәлдә, татарлар алдында хәзерге заман фәнен һәм мәдәниятын үзләштерү юлын да ачалар.

Җәдиди мәктәпләрдә, дөньяви фәннәр белән бергә, дини дәресләр дә керүе революциягә кадәр татарлар арасында уку-укыту мәсьәләләре яктыртылган хезмәтләрдә, җәдитчелек бу өлкәдә бернәрсә дә бирмәде, җәдит мәктәпләре кадими мәктәпләрдән берни белән дә аерылмадылар, дигән уйдырма таратылуга бер сылтау була. Әмма мондый хезмәтләрнең авторлары җәдит мәктәпләреннән татарның Г.Тукай, Ф.Әмирхан, С.Рәмиев, Һ.Такташ кебек зур әдипләре, культура эшлеклеләре чыгуны, бу мәктәпләрнең гади халык балаларына җиңел ысул белән укырга-язарга өйрәнүгә, табигать һәм иҗтимагый фәннәр нигезләре белән танышуга мөмкинлек ачуын читләтеп үтәләр. Аннары шул типтагы мәдрәсәләрнең берсеннән зур язучыбыз һәм күпкырлы галимебез Г.Ибраһимов та чыккан

1 Күлтәси Ш. Һәйяте җәдидә. Казан, 1896, 5 б.

бит. Галим һәм язучы Нәкый Исәнбәт тә, халкыбызның вөҗданы Хәсән Туфан да – шул ук типтагы мәдрәсә шәкертләре.

Болгар-татарлар тарихында исламның тоткан роленә бирелгән бу кыскача характеристика, аны халкыбыз тарихыннан җиңел кул белән генә аерып алу – һич ни белән дә аклана алмый торган бернәрсә, дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Ул, күренүенчә, безнең милләт булып формалашуыбызда һәм үсешебездә хәлиткеч роль уйный, мәдәниятыбызның нигезендә ята. Халкыбыз өстенә төшкән һәм озакка сузылган җәберзолым елларында, кан коюлар, мыскыллаулар белән бәйләнгән христианлаштыру шартларында, аңа үз-үзен саклауда рухи таяныч була һәм бүген дә, әгәр киләчәккә үзебезне милләт буларак сакларга теләсәк, без аны күңелләребездә йөртергә, өйрәнергә, аның әхлакый идеалларын үзебезгә маяк итеп алырга тиешбез. Милләт буларак безнең киләчәгебез шуңа бәйләнгән.

*Яхъя Абдуллинның «Милләт язмышы: уйланулар» китабыннан*

# И, туган тел!

# Телебез – милләтебез язмышы

Тарих гомер-гомергә иң кызыклы фәннәрнең берсе булып кала бирә. Татар халкы да «Үткәнен белмәгәннең – киләчәге юк» дип юкка гына әйтмәгәндер. «Дин вә Мәгыйшәт» редакциясе дә тарихыбызда булган кайбер вакыйгалар белән кызыксынып, тарих фәннәре кандидаты Әскар Гатин белән әңгәмә корырга булды.

**– Рәсәйдә иң беренче тапкыр халык санын кайчан алалар? Татарларны беренче халык санын алуда кем дип язганнар?**

– Рәсәйдә урта гасырлар һәм яңа заманда халыкны төгәл санап тору бары тик XIX гасырның ахырында гына башлана. Аңа тикле алпавытлар һәм дәүләткә хезмәт итүче җирбиләүчеләр санын, дәүләт җирендә яшәүче халыкның санын кирәк булган вакытта гына теркәп барганнар. Шулай да, ул теркәү төгәл булмаган. XVIII-XIX гасырларда хөкүмәт ревизияләр үткәргән: алар күбесенчә ирләр санын исәпләр өчен үткәрелгән, чөнки ирләрнең санын белү – салым җыю һәм армиягә рекрутларны алыр өчен кирәк була. Ләкин анда аларның гаиләләре турында да мәгълүмат җыелган.

Инде капиталистик чорда, авыллардан шәһәрләргә күпләп күченү башлангач, халыкның тормышын статистик яктан төгәл өйрәнер өчен мөкинлекләр тугач, 1897 елда халык санын алу үткәрелә. Аңа әзерлек эше һәм аны үткәрү турындагы фикер 1870 елда ук әйтелә. Әлбәттә, бу халык санын алу Казан, Ырынбур, Өфе губернияләрендә яшәүче татарлар арасында каршылыклы фикер уята. Кайбер кешеләр бу халык санын үткәрү максатын аңламыйча, моны чукындыру белән бәйлиләр һәм аңа каршы имеш-мимешләр тарата башлыйлар. Ул вакытта урыс миссионерларыннан курку халыкта бик көчле була әле. Кайбер авылларда кешеләрне яздырып алуга каршы чыгу очраклары да теркәлгән. Шул вакытта халык

санын алуның максатларын аңлатыр өчен җирле муллаларны кулланырга тырышалар. Мәсәлән, Бөгелмә өязендә шундый хәл була: анда җирле имам һәм ахун Гыйльман Кәримовны бу эшкә тарталар.

**– Бүгенге көндә татар теле язмышына куркыныч янаганын исәптә тотып, телне саклап калу, алдагы буыннарга тапшыру өчен татар гаиләләре үз тарафларыннан нинди өлеш кертә ала?**

– Мин бу сорауны күбрәк фәлсәфи сорау буларак карыйм, чөнки гаилә төп яшәү формасы буларак юкка чыккан вакытта, гаиләдән артык күп нәрсә көтеп булмый. Без һаман гаилә дигәндә ниндидер бер иске тормышны күз алдыбызга китерәбез: берничә буын бергә бер өйдә яшәгән, ирле-хатынлы, бергә хуҗалык алып барган гаилә. Әйе, андый үрнәк булырлык гаиләләр бездә бар, аз да түгел, ләкин чынбарлыкта алардан башка без ни күрәбез: иреннән аерылышкан яисә баласын ялгыз тәрбияләүче хатын-кызлар бик күп, гаилә коручылар арасында хәзер аерылышулар бик күп, әле моңа тагын катнаш никахларны өстәп куйсак – менә сезгә катлаулы һәм камил булмаган бер чынбарлык. Бу бит иске тормыштан бөтенләй аерылып торган чынбарлык! Совет чорында безнең милләтебезгә өч бик яман сыйфат үтеп керде: беренчедән, Ислам дине юкка чыгып, милләтнең нигезе югалды; икенчедән, гаиләдә һәм җәмгыятьтә ирләр үз урынын югалтты, ирлек сыйфатлары бетте, ир балаларны ир булып тәрбияләү юкка чыкты; өченчедән, тормышыбыз нык үзгәрде, яңа техник җиһазлар һәм яңа яшәү шартлары барлыкка килде – борынгы йолалар, тормыш гадәтләре үзеннән-үзе юкка чыгып бара. Әйе, кемдер минем бу сүзләремне яратмас. Күпчелек кешеләрнең күңелләренә бу хуш килмәс! Безнең хәзерге вакытта тактик яктан ике генә котылу юлыбыз бар: беренчесе – ул хәзерге заман технологияләрен кулланып, татар телендә мәгълүмати мохит тудыру: электрон газеталар, хәбәрләр дөнья тормышын ТАТАРЧА яктыртырга тиеш, гел татарга татар турында гына сөйләп, язып утыру – ул үлемгә илтә торган юл; икенче юл авыррак

– телебезне мәдәният аркылы таныту, мәдәниятебезгә тирән тикшерү үткәрергә кирәк. Безнең элеккеге мәдәниятебез ислам мәдәнияте белән тыгыз бәйләнештә торган – бу бит үзе бер мирас! Язучыларыбыз арасында классик булган шәхесләр бар, ә алар язган әсәрләрдә бик тирән уйлар, фикерләр бар – шул әйткән фикерләрне күтәрергә кирәк.

**– Кызганычка, хәтта кайбер татар гаиләләрендә дә балаларның күбесенчә рус телендә сөйләшкәнен, үз ана телләрен начар белгәнен күрәбез. Әйтегез әле, биредә гаеп күбесенчә ата-аналардамы яки җәмгыятьтә, мәктәптәме?**

– Мәктәп балаларга тәрбия бирә алмый. Аның максатлары башка төрле. Әйе, безнең җәмгыятебез – Рәсәй элеккеге СССРдан чыккан кешеләр – һаман тәрбияне мәктәпкә борып калдыра. Ләкин читтәге бер укытучы ят балаларга нинди тәрбия бирә ала? Кызганычка, хәзерге вакытта балаларның хәле асралган өй мәчесенә охшаш: хуҗасы аны ашатаэчертә. Берәр нинди хәл булса, орышу белән бетә. Бар тәрбия шул. Әле гаилә тулы, ягъни ирле-хатынлы булсалар, андый гаиләләрдә күп ирләр тәрбиядән ерак тора: хатын-кыз өй эшен эшли, эшкә чаба, ә ире пешкән ризыкны көтеп утыра, телевизор янында вакытны үткәрә. Әлбәттә, бу хәл 90 нчы елларда гына барлыкка килмәгән, аның тамырлары совет чорындагы тәрбия системасында. Советлар дәүләте балаларны ата-анадан махсус аерган, чөнки яшь кешеләр эштә булырга тиеш, ә балаларны карау вазифасы балалар бакчасына, пионер аланнарына, мәктәпкә күчкән. Моны идеологик яктан бик матур итеп, күз буяп аңлата да алганнар: ата-ана яңа совет кешесен үстерер өчен тиешле тәрбияне һәм белемне бирә алмый. Әлбәттә, җәмгыятьне бөтенләй үзгәртеп корыр өчен белем системасы кулланылган. Ул дин белән көрәшү, яңа идеологияне яшь буыннарга сеңдерү эшендә бик актив эшләгән. Нәтиҗәдә, 1940-1960 елларда тоташ мәгариф системасы җәмгыять карашларын үзгәртә алган. Моңа тагын татар халкының борын-борыннан белемгә омтылуы да өстәлгән – гене-

тик тамырларыбызга сеңгән белем алуда тырышлык совет чорында менә дигән файдалы сыйфат була! Тик милләтебез өчен түгел, ә тормышны үзгәртеп коручы дәүләт кулында. Безнең халкыбыз совет чорында телен дә, мәдәниятен дә, йолаларын да, барысын югалтып бетерә! Инерция (сүлпәнлек, хәрәкәтсезлек, ред.) белән яшәгән авыл халкы гына татар телен саклап килгәнгә, халкыбызда бераз татар рухы калган, ләкин ул да бик нык какшаган. Рухи нигезен дә без югалттык. Бу, чынлыкта, бик зур фаҗига! Моны аңламыйча, уйламыйча, алга яшәү һәм котылу юлын эзләп булмый! Авыру үзенең авыру сәбәпләрен аңлаган хәлдә генә дәваны таба алыр. Сез биргән сорауга килгәндә, без хәзер беркемне дә гаепли алмыйбыз. Гаепләү безгә ни бирәчәк? Буш сүзләр генә. Әйе, ата-аналар гаепле, ләкин аларны шундый булдырган дәүләт юк инде. Мәктәп тә гаепле, ләкин ул мәктәпне үзгәртеп бетерү ни бирер? Яңа буынны алга алып баручы әйдәман кешеләр кирәк! Алар гына юлын күрсәтеп, шул юлга башкаларны күндереп милләтебез бара алыр. Без үзебезгә хәерле юлбашчыларны Аллаһыдан сорарга тиеш!

– Тирән эчтәлекле әңгәмә өчен рәхмәт сезгә!

*Әңгәмәне «Дин вә Мәгыйшәт» редакциясе әзерләде*

# Тәфсир

# Муса галәйһиссәлам кыйссасы

Мисыр фиргавенең кавеме исраиллеләрне коллар итеп тоткан була, җәберли, алардан иң авыр эшләрне эшләтә. Исраиллеләр кыптыйларның золымыннан бик арып, үз ата-бабалары җиренә – Фәләстыйнга кире кайтырга ният кылалар. Әмма фиргавен аларга Мисырны ташлап китәргә рөхсәт тә, мөмкинлек тә бирми.

Фиргавен исраиллеләрне сыйныфларга бүлә. Аларның бер өлеше пирамидалар төзүдә катнаша. Таудай биек ул пирамидаларны төзүгә меңләгән кеше җәлеп ителә. Исраиллеләрнең икенче бер өлеше йортларны сүтү һәм төзү эшләрен башкара, ә тагын бер өлеше таш чыгару белән мәшгуль була. Бу эш шулкадәр авыр була ки, хәтта бу авыр хезмәттән анда эшләгән кешеләрнең бөкреләре чыга. Ә эшләмәгән кешеләргә көндәлек салым салалар. Әгәр дә эшләрдә катнашмаган кеше кояш баеганчы шул салымны түләмәсә, аны бәйләп алып, бер айга төрмәгә утыртып куя торган булалар.

Хатын-кызлар исә йон эрләргә, тегү эшләренә җәлеп ителәләр. Бу коллык тәртибен тоту өчен кыптыйлар репрессияләр кулланалар, исраиллеләрне төрле газапларга, эзәрлекләүләргә дучар итәләр. Аннан тыш, фиргавен әмере буенча, кыптыйлар исраиллеләрнең һәр туган ир баласын үтереп бара башлыйлар. Кыз балаларны исән калдырсалар да, аларның тормышын яшәү дип әйтеп булмый. Исраиллеләрнең нәселен тулысынча юкка чыгарыр өчен, бу кызларны үсеп җиткәч тә, чит кешеләргә кияүгә бирәләр.

## Фиргавен күргән төш

Бервакыт фиргавен төш күрә: Фәләстыйн ягыннан зур ут килеп чыгып Мисырны чолгап ала да, андагы бар кыптыйларны яндырып бетерә. Тик бу ут, имеш, исраиллеләрнең берсенә дә тими.

Шуннан соң фиргавен бик нык куркып кала. Ул төрле юраучы, фалчы, сихерчеләрне чакырып, бу төшен юрата. Алар фиргавенгә:

– Исраиллеләрдә бер ир-бала туачак, синең әҗәлең һәм синең хакимлегеңнең чиге шул малай кулыннан булыр, – дип, төшнең мәгънәсен аңлаталар.

Моны ишеткәч, киңәшләшү өчен фиргавен барлык якыннарын җыя. Гомерен һәм хакимлеген саклап калу өчен, ул шундый коточкыч карарга килә: исраиллеләрдә туган һәр ир бала үтерелеп барырга тиеш, дип, әмер чыгара. Барлык кендек әбиләрен җыеп, болай дип әйтә:

– Әгәр дә ир-бала туып, сезнең кулда булса – аны шунда ук үтерегез, ә кыз-бала булса – исән калдырыгыз.

Кендек әбиләре аның бу әмерен төгәл үтәп баралар. Әгәр кем дә булса каршы килсә, шул кендек әбиен дә үтерәләр.

Фиргавен кешеләре бар ил буенча эшафотлар төзеп куялар, ул эшафотларда авырлы хатыннарны газаплыйлар. Бу сәбәпле күп хатыннарның балалары төшә. Шуңа да, мондый газаплаулардан котылу өчен, күп хатыннар үз ирекләре белән балаларын төшерәләр. Мондый җәзалауга да карамастан, бала табарга карар итеп, ир-бала тапкан хатыннарның балаларын шунда ук үтерәләр.

Шундый риваять тапшыралар: Муса галәйһиссәламнең дөньяга килүен булдырмый калу өчен, фиргавен әмере буенча, унике мең малай һәм яңа туган туксан мең ир-бала үтерелә. Тагын бер риваять буенча, Фиргавеннең бу әмерен үтәп, тугыз йөз туксан мең исраилле үтерелгән.

Мөхеддин бине Гарәби үзенең «Фусусел-Хикем» китабында: «Аллаһы Тәгалә Муса галәйһиссәламгә бар үтерелгән балаларның сәләт һәм көчен ирештергән. Шуңа да Муса галәйһиссәлам күрсәткән могҗизалар бик ачык булганнар», – дип яза.

Димәк, фиргавен һәр үтергән бала белән Муса галәйһиссәламгә яңа көч өстәп торган булып чыга. Шундый бер көн киләчәк: бар үтерелгән

балаларның көч һәм сәләтен үзенә алган Муса галәйһиссәлам фиргавеннең бар гаскәрләренә берүзе каршы тора алыр!

## Муса галәйһиссәламнең тууы

Яңа туган балаларны фиргавен фәрманы буенча үтереп бару белән бергә исраиллеләрнең өлкән яшьтәге кешеләре арасында да үлем-китем көчәеп китә. Шул сәбәпле, кыптыйлар фиргавенгә килеп, болай дип әйтәләр:

– Исраиллеләрнең олы яшьтәге кешеләре арасында да үлем ешайды, ә аларның балаларын сезнең әмер буенча үтереп баралар. Аларның нәселе юкка чыкса, бар авыр эшләрне дә безнең үзебезгә эшләргә туры киләчәк.

Фиргавен, аларның бу сүзләренә колак салып, якыннары белән киңәшләшкәч, тагын бер карарга килә. Бу карар буенча, яңа туган балаларны ел аралаш үтереп барырга тиеш булалар. Ягъни бер елны яңа туган бөтен ир-балаларны да үтерәләр, ә икенче елны – исән калдыралар. Әлбәттә, шундый явыз карарлар кабул итсәләр дә, фиргавен һәм аның якыннары Аллаһы Тәгалә билгеләгән тәкъдирне һич тә үзгәртә алмыйлар. Тәкъдирләренә язылганнар чынга аша – Муса галәйһиссәлам дөньяга яңа туган ир-балаларны үтереп барган елны килсә дә, исән кала. Җитмәсә, фиргавен сараенда, аның яклавы астында тәрбияләнеп тә үсә. Хакыйкатьтә, бар да Аллаһы көчендә бит! Ул язганны үзгәртергә беркемнең дә кодрәтеннән килми һәм Аның җәзасыннан да, рәхмәтеннән дә берәү дә котыла алмый.

Яңа туган ир-балаларны исән калдырган елны Муса галәйһиссәламнең әнисе Һарун белән йөкле була. Ә икенче елны, яңа туган ир-балаларны үтереп барганда, ул Муса галәйһиссәламне дөньяга тудыра.

Әлбәттә, ул фиргавен кешеләре аның улын үтерер дип бик курка. Алар бар җирне дә гел күзәтеп торалар, әгәр дә йөкле хатын очратсалар, шунда ук аның исемен язып та куялар. Бала табу вакыты җиткәч, мондый

хатыннарга кыптый кендек әбиләре килә. Әгәр дә кыз-бала тапсалар – аны исән калдыралар, әгәр дә инде бу хатын ир бала тапса, аның баласын үтерүче махсус кешеләргә тапшыралар. Ә алар балаларны үткен пычак белән чәнчеп үтерәләр.

Балага узгач, башка хатыннардан аермалы буларак, Муса галәйһиссәламнең әнисе йөкле булуын беркем сизмәгән, аның йөклелек билгеләре дә күзгә ачык күренмәгән, моны фиргавен хатыннары да күрми калган. Әмма, шуңа да карамастан, Муса галәйһиссәламнең әнисе гел борчуда һәм куркуда булган.

Бу хакта Коръәндә болай дип әйтелә:

وَأَوْحَيْنَا إِلَىٰ أُمِّ مُوسَىٰ أَنْ أَرْضِعِيهِ ۖ فَإِذَا خِفْتِ عَلَيْهِ فَأَلْقِيهِ فِي الْيَمِّ وَلَا تَخَافِي وَلَا تَحْزَنِي ۖ إِنَّا رَادُّوهُ إِلَيْكِ وَجَاعِلُوهُ مِنَ الْمُرْسَلِينَ ﴿٧﴾

**«Һәм Без Мусаның әнисенә: «Син аны имез, әмма әгәр аның өчен курыксаң, аны диңгезгә сал. Курыкма һәм кайгырма. Һичшиксез, Без аны сиңа кайтарачакбыз, һәм аны пәйгамбәрләрнең берсе итәчәкбез», – дип илһам иттек».**

«Касас / Хикәя», 28:7

Муса галәйһиссәламнең әнисенә иңдерелгән бу вәхи – пәйгамбәрлек вәхие түгел, ул аңа илһам (интуиция) яки төш күрү аша ирештерелгән.

Икенче бер аятьтә Аллаһы Тәгалә мондый сүзләр әйтә:

أَنِ اقْذِفِيهِ فِي التَّابُوتِ فَاقْذِفِيهِ فِي الْيَمِّ فَلْيُلْقِهِ الْيَمُّ بِالسَّاحِلِ يَأْخُذْهُ عَدُوٌّ لِّي وَعَدُوٌّ لَّهُ ۚ

**«Аны табутка сал, шуннан аны елгага җибәр, диңгез аны ярга чыгарсын. Минем дошманым һәм аның дошманы аны алсын».**

«Та Һа», 20:39

Муса галәйһиссәламнең әнисе өч ай буе аны күкрәк сөте белән туендыра. Бу вакытта ул зур куркуда була, фиргавен кешеләре аның өенә керерләр дип кайгыра. Алай булса, фиргавен кешеләре бу баланы табып, һичшиксез, үтергән булырлар иде.

Ә Муса галәйһиссәлам көннән-көн матурая, үсә төшә. Әнисенең бу баласына ияләшүе һәм аны яратуы да, аны югалтам дип борчылуы да көннән-көн көчәя, фиргавен кешеләре килеп, улын үтерерләр дип куркудан сабырлыгы бетә. Аның башка түзәр көче калмый. Шулай да Аллаһыдан алынган илһамны кулланма итеп алып, үз улын Нил елгасына салырга карар итә.

## Муса галәйһиссәлам фиргавен сараенда

Муса галәйһиссәламнең әнисе бер балта остасына агачтан тартма эшләргә куша. Тартманың эченә ул мамык түши, ә тышына, су үткәрмәсен өчен, сумала сылый. Улын тиешенчә туендыра да, Аллаһы Тәгаләгә тапшырып, баланы шул тартмага куеп, тартманы суга сала.

Аллаһы Тәгалә әмере белән, елга агымы тартманы фиргавен сараена кадәр алып килә дә, ярга чыгарып ташлый. Фиргавен хатынының хезмәтчеләре су алырга дип килгәч, тартманы табалар һәм аны алып кайтып, фиргавен хатынына бирәләр. Фиргавен хатыны тартманы ачып карагач, анда нур сирпеп торучы баланы күрә. Шунда аның күңелендә бу балага карата сөю уяна. Баланы күрүче башка кешеләр дә үзләрендә шундый ук хис тоялар. Хәтта фиргавен үзе дә соңыннан бу балага нык ияләшеп, аны ярата башлый. Аллаһы Тәгалә Коръәндә бу хакта болай дип әйткән:

وَأَلْقَيْتُ عَلَيْكَ مَحَبَّةً مِّنِّي وَلِتُصْنَعَ عَلَىٰ عَيْنِي ﴿٣٩﴾

**«Мин сиңа Үземнән бер сөю бирдем. (Кешеләрнең күңелләренә сиңа карата сөю орлыклары чәчкәнгә күрә, сине күргән берсе**

**синнән башка тора алмас хәлгә киләчәк). Син – Минем күзәтүем астында үстерелүең өчен».**

«Та Һа», 20:39

Шулай итеп, Аллаһы Тәгалә фиргавен сараеның бар кешеләре күңелләренә Муса галәйһиссәламгә карата сөю орлыгы сала. Әмма бераз вакыт үткәч, сарай кешеләре күңелләрендә: «Бу бала кем, ул каян килгән? Бәлки ул фиргавен хакимлегенә чик куяр өчен туган баладыр?» – дигән шик туа. Алар бу бала берәр исраилле баласыдыр дип шикләнәләр. Киңәшләшү өчен җыелган фиргавеннең якыннары бу баланы үтерергә карар кылалар. Әмма фиргавеннең хатыны Асия бинте Мөзәһим аларга каршы чыга һәм ирен балага тимәскә күндерә. Асия бинте Мөзәһим моның белән генә чикләнеп калмый, ул бар көче белән Муса галәйһиссәламне яклый, фиргавен бу баланы яратсын өчен бар көчен сала.

Бу хакта Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

وَقَالَتِ امْرَأَتُ فِرْعَوْنَ قُرَّتُ عَيْنٍ لِّي وَلَكَ ۖ لَا تَقْتُلُوهُ عَسَىٰٓ أَن يَنفَعَنَا أَوْ نَتَّخِذَهُ وَلَدًا وَهُمْ لَا يَشْعُرُونَ ﴿٩﴾

**«Фиргавеннең хатыны: «Менә минем дә, синең дә күз нурыбыз. Аны үтермәгез! Бәлки, ул безгә файда китерер яки без аны уллыкка алырбыз», – диде. Әмма алар белмиләр иде».**

«Касас / Хикәя», 28:9

Әнә шулай, Асия бинте Мөзәһим тырышлыгы белән фиргавен һәм аның якыннары Муса галәйһиссәламне үтерү уеннан кире кайталар. Бу бала аларның эзләгән дошманы булуы хакында хәтта башларына да килми.

Риваятьләрнең берсендә: «Асия фиргавенгә: «Менә минем өчен дә, синең өчен дә күз нурыбыз», – дип әйтте. Ә ул: «Синең өчен – шулай, ә миңа аның кирәге юк», – дип җавап бирде, дип әйтелә.

Соңыннан бу шулай булып чыга да. Аллаһы Тәгалә фиргавен хатынын хак юлга күндерә, ә фиргавеннең үзен Муса галәйһиссәлам үз кулы белән юк итә.

Муса галәйһиссәлам таягын бик зур еланга әйләндереп, могҗиза күрсәткәч, Асия бинте Мөзәһим иманга килә. Хатынының иманга килүен күреп, фиргавен аны каты җәзаларга тарта.

Әбү Һөрайра тапшырган риваятьтә болай дип әйтелә: фиргавен Асияне дүрт кадак белән җиргә кадаклап, аның өстенә авыр таш куярга дип әмер бирә. Шул вакытта Асия Аллаһыдан: «Раббым, Миңа җәннәттән, Үз яныңнан йорт-урын бир, мине фиргавеннән һәм аның (начар) эшләреннән коткар. Мине бу динсез халыктан арала!» – дип сорый.

Асия бинте Мөзәһим Аллаһы Тәгаләгә үзе өчен җәннәтел-мәвадан йорт-урын сорап ялвара. Җәзалау-газаплауларның барысын да сабырлык белән үтеп, ул үзе теләгән иң югары дәрәҗәдәге мәңгелек ялга лаек була.

Кайбер кыйссаларда фиргавен Асияне, кире үз диненә кайтарыр өчен, төрле газапларга дучар итә, дип тапшырыла. Тик шул вакыт эчке сиземләү аша аңа җәннәттәге урыны күрсәтелә. Һәм ул бернинди дә авырту сизмичә җан бирә. Аның тәненә куелган таш инде җансыз гәүдәгә салына. Асия бинте Мөзәһим иманда ныклык өлгесе булып тора, ул аны мәңгелек тәмуг утына дучар итәргә тырышкан фиргавенгә каршы чыга һәм аның иң изге хатын-кызы булып җәннәтнең иң югары дәрәҗәсенә ирешә.

Хәдистә Аллаһы Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Җәннәтнең иң изге хатын-кызлары – Хәдичә, Фатыйма, Мәрьям һәм Асия бинте Мөзәһим», – дигән сүзләре тапшырыла.

## Бала яңадан әнисенә кайта

Муса галәйһиссәламнең әнисенең хәле һәм аннан соң аның беләнниләр булганы турында Раббыбыз Коръәндә бу рәвешле бәян итә:

وَأَصْبَحَ فُؤَادُ أُمِّ مُوسَىٰ فَارِغًا ۖ إِن كَادَتْ لَتُبْدِي بِهِ لَوْلَا أَن رَّبَطْنَا عَلَىٰ قَلْبِهَا لِتَكُونَ مِنَ الْمُؤْمِنِينَ ﴿١٠﴾ وَقَالَتْ لِأُخْتِهِ قُصِّيهِ ۖ فَبَصُرَتْ بِهِ عَن جُنُبٍ وَهُمْ لَا يَشْعُرُونَ ﴿١١﴾

**«Мусаның әнисенең күңеле бушап калды. Ул (улын алып киткән сандыкның дулкыннар арасына кереп киткәнен күргәч, кычкырып) аны ачар дәрәҗәгә җитте. Әгәр дә Без ышанганнардан булуы өчен күңелен куәтләндермәгән булса идек. Аның (Мәрьям исемле) апасы: «Артыннан бар!» – диде. Һәм ул аны ерактан күзәтте. Әмма алар (фиргавеннең кешеләре аның баланы күзәткәнен) белмәделәр».**

«Касас / Хикәя», 28:10-11

Муса галәйһиссәламнең әнисе, баласын үлемнән коткарып калу өчен, аны сандыкка салып, Нил суы буйлап агызып җибәргән. Аның бар уйлары улы турында булган. Иртән, сандыкның фиргавен сараена эләгүен ишеткәч, ул чак акылдан язмаган. Фиргавен хәзер минем баламны үтерә инде дип, кычкырып-кычкырып елый башлаган. Шул вакытта аңа Аллаһыдан ярдәм килгән. Аллаһы Тәгалә илһам булып аңа элек вәгъдә иткәнен исенә төшергән. Шуннан соң Муса галәйһиссәламнең әнисе ныклап бу вәгъдәгә ышанып, аның нәтиҗәләрен көтә башлаган. Әгәр дә Аллаһы Тәгалә аңа түземлек һәм сабырлык ирештермәгән булса, ул кайгы-сагышыннан үзенең кем икәнлеген хәтереннән югалткан да булыр иде. Муса галәйһиссәламне дә үз улы дип әйтер иде. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

وَأَصْبَحَ فُؤَادُ أُمِّ مُوسَىٰ فَارِغًا ۖ إِن كَادَتْ لَتُبْدِي بِهِ لَوْلَا أَن رَّبَطْنَا عَلَىٰ قَلْبِهَا لِتَكُونَ مِنَ الْمُؤْمِنِينَ ﴿١٠﴾

**«Әгәр дә Без (сүзебезгә) ышанганнардан булуы өчен (сабырлык һәм ныклык биреп һәм янә тынычлык иңдереп) күңелен куәтләндермәгән булсак, (һичшиксез, ул «аһ, улым!» дип кычкырып, үзен фаш итәчәк иде».**

«Касас / Хикәя», 28:10

Аллаһы Тәгалә аның күңеленә улы кире кайтачак дигән ышаныч сала. Шунда йөрәге тынгы таба, улы белән ни булганын белер өчен ул кызын фиргавен сараена җибәрә. Кызы шунда хезмәт иткәч, аңа тиешле хәбәрне җиткереп тора. Ул үзен сиздерми, читтән генә Муса галәйһиссәлам артыннан күзәтеп йөри башлый, аның турында тиешле мәгълүмат җыя. Һәм фиргавеннең Муса галәйһиссәламне үтермәвен, аны уллыкка алуын белә. Моннан тыш, ул сарайда булган бар вакыйгалар турында да белеп бара һәм кайтып әнисенә сөйли.

Фиргавен һәм аның хатыны Муса галәйһиссәламне бик яраткач, алар аны үз уллары кебек үстерергә карар итәләр. Муса галәйһиссәламне туендыру өчен фиргавен хатыны, бала имезүче хатыннарны сарайга чакыртып ала. Ул алар арасыннан иң яхшысын сайлап алырга уйлый. Ләкин Муса галәйһиссәлам аларның берсен дә кабул итми. Шуннан соң фиргавен хатыны Муса галәйһиссәлам ачтан үләр дип бик курка. Бу вакыйга турындагы хәбәр тиз арада бар тирә-якка тарала. Мисырның бар җирләренә дә, яшь баланы имезүче хатын кирәк, дип игълан итүче сөрәнчеләр җибәрелә.

Аллаһы Тәгалә бу турыда Коръәндә болай дип әйтә:

وَحَرَّمْنَا عَلَيْهِ الْمَرَاضِعَ مِن قَبْلُ فَقَالَتْ هَلْ أَدُلُّكُمْ عَلَىٰ أَهْلِ بَيْتٍ يَكْفُلُونَهُ لَكُمْ وَهُمْ لَهُ نَاصِحُونَ ﴿١٢﴾

**«Без (апасының күзәтүеннән) алдан (бер могҗиза буларак) имезүче (сөт аналарыннан имүне) аңа тыйдык. Ул (апасы са-**

**райга китерелгән бер генә хатыннан имүне кабул итмәгән бала аркасында бик нык борчылган фиргавеннең гаиләсенә): «Сезнең өчен аны (имезеп үстерүне) өсләренә алган һәм аңа игелек теләгән бер йорт халкын сезгә күрсәтимме?» – диде».**

«Касас / Хикәя», 28:12

Муса галәйһиссәламнең апасы фиргавен сараенда бала имезүче хатын эзләүләрен һәм таба алмауларын белгәч, сарайга килеп: «Мин сезгә бер өйнең җәмәгатен күрсәтимме, ул хатын сезнең өчен баланы имезеп тәрбияләр һәм ул җәмәгать балага яхшы нәсыйхәт бирүчеләрдән булыр», – диде.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе болай дип сөйләгән:

Муса галәйһиссәламнең апасы шулай дип әйткәч, сүзләренең дөреслегеннән шикләнеп, аны сарай эченә алып кереп:

– Син әйткән гаилә балага карата яхшы мөнәсәбәттә булачагын син каян беләсең? – дип сорыйлар.

Муса галәйһиссәламнең апасы үзен фаш иттермәскә тырышып:

– Ул патша гаиләсендә сөт анасы булырга тели һәм моннан бернинди дә файда эзләмим, – дип җавап бирә.

Шуннан соң ул сөйләгән хатынны китерергә кешеләр җибәрәләр. Муса галәйһиссәламнең әнисе сарайга шунда ук килеп җитә. Әнисе баласын кулына алу белән үк, ул аның күкрәгенә сыенып имә башлый, елаудан туктый. Сарай әһелләре, иң беренче чиратта, Асия бинте Мөзәһим моңа бик шатланалар, Муса галәйһиссәламнең анасына күп бүләкләр бирәләр.

Ләкин фиргавенне тагын шик-шөбһәләр баса. Бераз уйлап торгач ул:

– Син бу балага кем буласың? Ул башка имезүчеләрдән баш тартты, ә сине кабул итте, – дип әйтә.

Муса галәйһиссәламнең әнисе аңа:

– Минем тәнем хуш исле һәм сөтем дә тәмле. Минем сөтне ошатмаган бер генә бала да юк, – дип җавап бирә.

Бу сүзләр фиргавенне ышандыра һәм туендырыр өчен Муса галәйһиссәламне әнисенә бирәләр. Моннан тыш алар аны яшәү чыганагы белән тәэмин итеп, күп бүләкләр тапшыралар. Муса галәйһиссәламнең әнисе моннан бик канәгать була һәм баласын алып өенә кайта.

Аллаһы Тәгалә аны куркудан азат итә һәм аңа башкалар арасында хөрмәт, югары дәрәҗә, муллык ирештерә. Күрәсез ки, һәр авырлыктан соң Аллаһы Тәгалә аннан чыгу юлын күрсәтә, җиңеллек бирә.

فَرَدَدْنَاهُ إِلَىٰ أُمِّهِ كَيْ تَقَرَّ عَيْنُهَا وَلَا تَحْزَنَ وَلِتَعْلَمَ أَنَّ وَعْدَ اللَّهِ حَقٌّ وَلَٰكِنَّ أَكْثَرَهُمْ لَا يَعْلَمُونَ ﴿١٣﴾

**«Күңеле тыныч булсын һәм (аерылу сәбәпле) сагышланмасын, янә, һичшиксез, Аллаһының вәгъдәсе хак булганын белсен өчен, Без аны әнисенә кайтардык, ләкин аларның күбесе (Аллаһының сүзе, һичшиксез, үтәләчәген) белмиләр».**

«Касас / Хикәя», 28:13

Хәдисләрнең берсендә Аллаһы Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шундый сүзләре тапшырыла: «Мусаның анасы изге ниятләр белән, Аллаһы Тәгаләдән генә саваплар алырга өмет итеп ниндидер гамәл кылучы кешеләргә үрнәк булып тора. Ул үз улын туендырды, аның өчен саваплы да булды».

## Ут һәм алтын белән сынау

Риваятьләрнең берсендә фиргавен, Муса галәйһиссәламнән бик нык курыкса да, аны яратып кочагына ала, дип тапшыралар. Шул рәвешле ул Муса галәйһиссәлам белән бераз уйнарга теләгән. Фиргавеннең кочагына эләккән бала аны сакалыннан тотып ала да, нык кына итеп шул

сакалыннан тарта. Шуның аркасында фиргавен башы белән мәрмәргә бәрелә. (Муса бик көчле була, чөнки аңа фиргавен әмере буенча үтерелгән бар балаларның көче бирелгән була). Фиргавен чак кына башын ярмый кала. Шуннан соң ул зур куркуга төшә һәм бик нык ачуы чыгып: «Бу бала мине үтерәчәк. Ул, күрәзәчеләр алдан әйтүенчә, минем хакимлеккә чик куячак бала», – дип кычкыра. Аннары ул бу баланы үтертү өчен җәлладны чакырырга куша. Ләкин Асия бинте Мөзәһим аңа каршы:

– Ул бит кечкенә бала гына. Аның бернинди дә начар ният һәм максатлары була алмый, – дип әйтә.

Ләкин фиргавен курку һәм гаҗәпләнүеннән, бу бала бәлки аның үлеменә сәбәпче булыр дип уйлап, бер ноктага карап торуын дәвам итә. Шуңа да ул Муса галәйһиссәламне үтерергә карар кыла. Әмма бернигә дә карамый Асия бинте Мөзәһим баланы яклавын дәвам итә һәм соңгы өмете белән:

– Әгәр дә син шулай уйлыйсың икән, без бу баланы сынап карыйк. Бу бала син уйлаганча акыллы, үзенең ни эшләгән аңлап эшли икән, син ул чакта аны үтерерсең. Әгәр дә алай булмаса, син аны үтерми калдырып миңа бирерсең, – дип әйтә.

Шуннан баланы сынап карар өчен фиргавен ут ягарга һәм алтын китерергә куша. Аннары, аларның кайсына үрелгәнен карар өчен, ут белән алтынны бала алдына куялар. Гади бала утның якты януына кызыгып, кулын пешерәсен аңламыйча утка үрелергә тиеш була. Әгәр дә Муса галәйһиссәлам кулын утка түгел, ә алтынга таба сузса, бу аның бик тә акыллы, барысын да аңлый торган гайре акыллы бала булуын һәм фиргавенне башы белән мәрмәргә махсус бәрүен аңлатырга тиеш була. Шул сәбәпле, бу баланың киләчәктә фиргавенне һәлак итәчәк һәм аның хакимлегенә чик куячак бала икәнлеге дә билгеле булачак иде.

Сез: «Муса галәйһиссәлам кайсына үрелгән соң?» – дип сорарсыз.

Әлбәттә, ул, бик тә акыллы бала буларак, алтынга үрелгән. Әмма шул вакытта Җәбраил галәйһиссәлам килеп, Муса галәйһиссәламнең кулын утка таба борган. Ул гына да түгел, ул утлы бер күмер кисәге алып авызына сузган, хәтта телен дә көйдереп өлгергән. Шуның аркасында ул сакау сөйләшә торган булып калган.

Ягъни, утка сузылып ул кулын һәм телен пешерсә дә, үзенең гомерен саклап калган, соңыннан сакаулыгыннан да котылган. Аллаһы Тәгалә билгеләгән вакыт җиткәч, Ул Муса галәйһиссәламгә:

«Фиргавенгә бар, ул рөхсәт ителгәннәрнең чиген үтеп китте», – дип әйткән.

Муса галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләдән бу әмерне алгач:

قَالَ رَبِّ اشْرَحْ لِي صَدْرِي ﴿٢٥﴾ وَيَسِّرْ لِي أَمْرِي ﴿٢٦﴾ وَاحْلُلْ عُقْدَةً مِّن لِّسَانِي ﴿٢٧﴾ يَفْقَهُوا قَوْلِي ﴿٢٨﴾

**«И Раббым! Минем күкрәгемне киң кыл! Эшемне миңа җиңел ит. Телемдәге төенне чиш»,** – дигән.

«Та Һа», 20:25-28

Аның бу үтенече кабул ителә, һәм ул тотлыкмый башлый.

Бик күп дәгъватчы һәм вәгазьчеләр дингә чакыруларын шушы дога белән башлый. Раббыбыз ярдәменнән башка без фикерләребезне һәм сүзләрне җыеп әйтә алыр идекмени? Ул безнең тел һәм зиһен ачкычларыбызны ачмаса, без көненә намаз вакытында 40 тапкыр укыла торган «Фәтихә» сүрәсен укыганда да хаталар җибәрер идек.

Фиргавен үзе нишли соң? Аның тәкәбберлеге, мин-минлеге чамасыз була, ул рөхсәт ителгәннәрнең бар чикләрен дә үтеп чыга һәм үзен Раббыга исәпли башлый. Ул башта «Мин сезнең Раббыгызмын», – ди, ә аннары:

فَقَالَ أَنَا رَبُّكُمُ الْأَعْلَىٰ ﴿٢٤﴾

**«Сезнең бөек Раббыгыз – мин!»** – дип әйтә.

«Нәзигат / Суыргучы», 79:24

Каян чыгып үзен Аллаһыга тиңли соң ул? Чынлыкта, Яратучы аңа күп хакимлек, байлык һәм озын гомер насыйп итә. Ул хәтта авыруны да белми. Нәтиҗәдә, ул үзен гади кешеләрдән аерыла, дип тоя. Моңа өстәп фиргавен янында булган вәзир-киңәшчеләр һәм хезмәтчеләр дә аңа куштанланып, «Син – гадәттән тыш кеше», дип ышандыра. Хакыйкатьтә, кешене мохит һәм яндагы иптәшләре һәлак итә ала. Киңәшче Хаман үзенең хөкемдарын һәлак иткән шикелле.

## Фиргавенгә кызыгырлык тәкъдим ясыйлар

Һаман исемле кеше фиргавеннең баш вәзире һәм төп киңәшчесе була. Фиргавеннең үзен Раббы дип игълан итүенең төп сәбәпчесе нәкъ менә ул була да инде.

Риваятьләрнең берсендә фиргавеннең бервакыт үзен Раббы дип раслаудан баш тартырга ниятләве турында тапшырыла. Ул иманга килү турында уйлана башлый, чөнки Муса галәйһиссәлам аңа шундый тәкъдим ясый:

– Әгәр дә син иманга килсәң, Аллаһы Тәгалә сиңа яшьлегеңне һәм элекке көчеңне кире кайтарыр. Ахирәттә дә син җәннәт әһеле булырсың, – дип әйтә.

Әлбәттә мондый тәкъдим фиргавенне бик тә кызыктыра. Һәм ул:

– Туктап тор, миңа бу турыда яхшылап уйларга кирәк, – дип әйтә.

Ул баш вәзирен чакырып ала һәм аның белән киңәшләшә. Ләкин Хаман моңа катгый рәвештә каршы чыга, ул фиргавенгә:

– Син үзеңнең ни әйткәнеңне аңлыйсыңмы? Моңа кадәр син кешеләргә «Мин сезнең Раббыгыз», – дип әйттең, ә хәзер инде икенче бер Раббының колы булырга телисеңме? Сиңа нәрсә вәгъдә итүләре мөһим түгел, Раббылыкка дәгъва итүдән баш тартсаң, кешеләр сине хөрмәт итми башлаячаклар һәм син җәмгыятьтә тоткан югары урыныңны югалтачаксың.

Шундый җавап ишеткәч, фиргавен кире чигенә һәм тау башыннан ычкынган зур таш кебек, аска, тәмугка таба тәгәрәвен дәвам итә.

*(Дәвамы киләсе санда)*

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*
*Татарстан Республикасы мөфтие*

## 80. Габәсә (Йөзен чытты) сүрәсе

Мәккә чоры, 42 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. [Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм] **Йөз чытты һәм читкә борылды.**
2. **Янына сукыр килде дип.**
3. [Расүлем!] **Син каян белә аласың? Бәлки, ул** [синең вәгазең аркасында бөтен гөнаһлардан] **арыныр иде.**
4. **Яки үгет алыр, һәм үгет аңа файда бирер иде.**
5. **Яки** [бай булуы сәбәпле] **үзен** [Аллаһыдан һәм иманнан] **ихтыяҗсыз дип санаган** [кеше].
6. **Син аңа юнәләсең** [һәм әһәмият бирәсең].
7. **Югыйсә аның** [Исламга кермичә] **арынмавында синең өстеңдә** [җавап тотарлык] **бернәрсә дә юк.**
8. **Әмма ашкынып сиңа килгән кеше.**
9. [Аллаһыдан һәм кяферләрнең җәфалауларыннан, юлда абынудан] **Курыккан хәлдә.**
10. **Син аны игътибарсыз калдырасың** [иманга килмәячәк берәүгә вәгазьләр сөйләп, вакытыңны бушка уздырасың].[1]
11. [Расүлем!] **Юк!** [Артык беркайчан да болай итмә!] **Һичшиксез, бу –** [укылган сүрә – зур бер] **үгет.**
12. **Теләгән кеше** [фикерләп] **үгет алыр!**
13. [Ул Коръән Аллаһыдан изге ителгән һәм Ләүһүл-Мәхфүздән алынган] **Кадерле сәхифәләрдә** [теркәлгән].
14. **Күтәрелгән һәм** [Аллаһының сүзеннән башка һәрнәрсәдән] **пакь кылынган.**
15. **Кятипләрнең** [язучы фәрештәләрнең] **кулларында ки.**
16. [Алар Аллаһы катында] **Шәрәфлеләр һәм итагатьлеләр.**
17. **Дөмексен** [инкяр итүче] **кеше!** [Шуның кадәр игелекләрне биргән Раббысына карата] **Ул нинди инкяр итүче!**

---

1 Риваятьтән күренгәнчә, беркөнне Расүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) Корәешнең олугларын Ислам диненә дәгъват иткән чакта, сукыр булган Габдулла бине Өмме Мәктум радыяллаһу ганһе аның янына килеп: «Я Расүлуллаһ! Аллаһы сиңа өйрәткән нәрсәләрдән миңа да бераз өйрәт әле!» – дип берничә мәртәбә әйткән. Бу вакытта ул Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мөшрикләр белән мәшгуль булганын белмәгән. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм, сүзе бүленүен ошатмыйча, мөбарәк йөзен чыткан һәм аңардан йөз чөергән. Бу аяте кәримәләр шуңа карата иңгән булып, аны кисәткәннәр. Бу вакыйгадан соң Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа бик хөрмәт белән караган һәм «Миңа Раббымнан шелтә алдырган кешегә мәрхаба!» – дия торган булган. Сәфәргә чыккан вакытларында ике мәртәбә аны Мәдинәдә хәлифә итеп калдырган (Алуси).

18. **Ул** [Раббысы] **аны нәрсәдән яратты?**
19. **Бер тамчыдан аны яратты, шуннан соң аңа** [бөтен әгъзаларын теләгәнечә һәм җиңел итеп яши алуы өчен иң кулай] **шәкел бирде.**
20. **Шуннан соң** [ана карынынннан чыгу] **юлын аңа җиңеләйтте.**
21. **Шуннан соң аны үтерде һәм аны** [ерткыч хайваннар кебек җир өстендә калдырмыйча] **кабергә куйдырды.**
22. **Соңыннан, теләгән чагында Ул аны** [үлгәненнән соң] **терелтер.**
23. **Юк!** [Кеше көферлекне калдырырга тиеш!] **Ул** [инкяр итүче кеше] **Ул** [Аллаһы Тәгалә] **аңа әмер иткән нәрсәләрне үтәми.**
24. **Кеше ризыгына** [бер] **карасын** [да, бераз уйлансын]**.**
25. **Без суны мул итеп коеп яудырдык.**
26. **Шуннан соң җирне яру белән ярдык.**
27. **Һәм анда** [бодай һәм арпа кебек] **иген үстердек.**
28. **Йөземнәр һәм тукранбашлар да.**
29. **Зәйтүнлекләр һәм хөрмәлекләр дә.**
30. **Куе бакчалар да.**
31. **Җимешләр һәм болыннар да.**
32. [Болар] **Сезнең һәм терлек-туарыгызның файдасына** [эшләнде]**.**
33. [Колакларны] **Саңгыраулатырлык** [вакыйга булган Кыямәт тавышы] **килгәч** [менә шулвакыт һәркем үзе турында гына уйлаячак]**.**
34. **Ул көнне кеше үзенең кардәшеннән качачак.**
35. **Анасыннан һәм атасыннан да.**
36. **Хатынынннан һәм улларыннан да** [ул көнне беркем беркемгә карый алмаячак]**.**
37. [Чөнки] **Ул көнне алардан һәркайсының** [башка берни дә уйлый алмаслык] **үз эше җитәрлек** [булачак]**.**
38. **Кайбер йөзләр** [дөньяда укыган тәһәҗҗедләр һәм алган тәһарәтләре сәбәпле] **ул көнне балкырлар.**
39. [Шаһит булган чиксез нигъмәтләр каршысында] **Көләрләр һәм сөенерләр.**
40. **Кайбер чырайларда исә ул көнне тузан булачак.**
41. **Аларны каралык һәм караңгылык каплаячак.**
42. **Алар –** [Аллаһының хаклыгын инкяр иткән] **кяферләр һәм** [кол хакларын санга сукмаган] **гөнаһлылар.**

## 81. Әт-Тәквир (Төрү) сүрәсе

Мәккә чоры, 29 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. **Кояш** [чалма шикелле] **төрелгәч** [һәм яктысы беткәч]**.**
2. **Йолдызлар** [күктәге урыннарыннан] **коелгач.**
3. **Таулар** [җир йөзеннән кубып, һавада] **йөртелгәч.**
4. [Гарәпләрнең иң кадерле малы булган] **Ун айлык буаз дөяләр** [хуҗаларының мәшәкатьләре аларда булмау сәбәпле] **караусыз калдырылгач.**
5. **Кыргый хайваннар** [кыйсас, өчен һәрьяктан] **җыелгач.**
6. **Диңгезләр** [учак кебек] **кызгач.**
7. **Рухлар** [тәннәренә кабат кайтарылып, алар белән] **кушылгач.**
8. **Тере килеш күмелгән кыз балалар** [«Гаепсезгә үтерелдем!» – җавабын бирсен һәм үтерүчесен күрсәтсен өчен] **соралгач.**
9. **«Ул нинди гөнаһ өчен үтерелде?»**
10. [Колларның гамәлләре язылган] **Сәхифәләр** [ияләре арасында] **таратылгач.**
11. [Хайванның тиресе туналган кебек] **Күк туналгач.**
12. [Кызган] **Ут дөрләтеп җибәрелгәч.**
13. **Җәннәт** [тәкъвалык иясе колларга] **якынайтылгач.**
14. [Менә шул вакытта] **Һәрбер җан** [яхшылыктан һәм начарлыктан] **нәрсә әзерләгәнен беләчәк.**
15. **Юк!** [Йолдызлыкларының ахырына җиткәннән соң] **Кире** [баштагы нокталарына] **кайтканнар** [планеталар] **белән ант итәмен!**
16. **Йөзеп йөрүчеләр,** [кояш яктысында] **яшеренә торганнар белән** [ант итәмен]**.**
17. **Караңгыланып килгән төн белән дә** [ант итәмен]**.**
18. **Сулыш алган чактагы таң белән дә** [ант итәмен]**.**
19. **Һичшиксез, бу** [Коръән] **–** [Җәбраил [галәйһиссәлам] кебек Аллаһ хозурында] **шәрәфле булган бер пәйгамбәрнең сүзе.**
20. **Гарешнең Иясе хозурында көче һәм мәртәбәсе булган.**
21. **Анда** [күкләрдә] **итагать ителгән һәм ышанычлы булган** [фәрештә]**.**
22. [Янә сыйфатлары белдерелгән планеталар белән ант итмәмен] **Сезнең юлдашыгыз** [булган Расүлем] **тиле түгел.**
23. **Ул** [Расүлем] **аны** [Җәбраилне [галәйһиссәлам] асыл сурәтендә] **ачык офыкта күрде.**

24. **Ул** [ирештергән] **гаибкә саран түгел.**
25. **Ул** [Коръән] **куылган шәйтанның да сүзе түгел.**
26. [Пәйгамбәрләр һәм Коръән хакында дөрес рәвештә инануны калдырып] **Кая барасыз?**
27. **Ул** [Коръән Аллаһы Тәгаләдән] **галәмнәр өчен** [җибәрелгән] **бер үгеттән башка түгел.**
28. **Арагыздан** [хакны эзләп] **туры юлда булырга теләгәннәр өчен.**
29. [Сез: «Теләсәк, туры юлда булырбыз!» – дип әйтәсез] **Әмма галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы теләмәсә, сез тели алмаячаксыз.** [Аллаһы исә туры юлны эзләячәген белгән кешеләрне генә һидаятенә ирештерер].

## 82. Әл-Инфитар (Ярылу) сүрәсе

Мәккә чоры, 19 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. **Күк ярылгач.**
2. **Йолдызлар коелгач.**
3. **Диңгезләр ташыгач.**
4. **Каберләр асты өскә әйләнгәч.**
5. **Һәрбер җан киләчәккә ни әзерләгәнен һәм үзеннән соң калдырган һәрнәрсәне** [үзенә ниләр казандырачагын һәм башына нинди бәлаләр китерәчәген] **беләчәк.**
6. **И,** [терелүне инкяр иткән] **кеше!** [Сиңа сансыз нигъмәтләр биргән] **Юмарт Раббыңа карата сине нәрсә алдый** [шәйтанның: «Теләгәнеңне эшлә, Раббың бик юмарт ул, шуңа күрә Ул беркемгә дә җәза бирмәс», – кебек сүзләренә алданасың]**?**
7. **Ул сине бар иткән, сине төзек** [әгъзаларыңны кимчелексез] **иткән һәм сине** [килешсез булган нәрсәләрдән саклап] **үлчәүле иткән.**
8. [Моның кадәр җан ияләре арасында сине] **Нинди шәкелдә** [бар итәргә] **теләгән** [һәм якыннарыңнан кемгә охшатуны максат иткән] **булса, сине шулай берләштергән.**
9. **Юк! Сез шул Җәза көнен ялган дип саныйсыз.**
10. **Югыйсә сезнең өстегездә** [гамәлләрегезне һәм сүзләрегезне күзәтеп торган] **сакчылар бар.**
11. [Безнең хозурыбызда] **Кадерле** [булган] **язып баручылар.**
12. **Сез кылган** [олы-кече] **нәрсәләрне** [бөтенесен] **беләләр.**

13. **Һичшиксез,** [иманлы һәм] **тәкъва коллар – нигъмәт эчендә.**
14. [Кяфер һәм] **Гөнаһлылар ут эчендә.**
15. **Алар** [үзләре инкяр иткән] **Җәза көнендә анда керәчәкләр.**
16. **Алар аңардан качып котыла алмаслар.**
17. [Расүлем!] **Җәза көненең ни икәнен син каян белә аласың?**
18. **Әйе, Җәза көненең ни икәнен син каян белә аласың?**
19. **Бер җанның да бер җанга да берни эшли алмаган көнне** [җәзаландырылачаклар] **ки, ул көнне әмер – Аллаһыныкы гына.**

## 83. Әл-Мутаффифин (Киметеп үлчәүчеләр) сүрәсе

Мәккә чоры, 36 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. **Киметеп үлчәүчеләргә ни үкенеч!**
2. **Алар** [үзләре өчен] **кешеләрдән үлчәткән вакытларында, тулысынча алалар.**
3. **Ләкин аларга үлчәгәндә яки** [бизмәнгә салып үлчи торган нәрсәләрнең] **авырлыгын билгеләгәндә, киметәләр.**
4. **Алар терелтеләчәк дип уйламыйлармы?**
5. **Бөек көн өчен.**
6. **Бөтен кешеләрнең галәмнәр Раббысы** [булган Аллаһы Тәгаләнең хөкеме һәм җәзасы] **өчен** [каберләреннән] **кубарылган көнне** [күз уңында тотам]**.**
7. **Юк!** [Терелүдән һәм хисаптан шулкадәр гафил булмагыз!] **Һичшиксез,** [тартынмыйча гөнаһ эшләгән] **гөнаһлыларның** [кылган начар гамәлләре теркәлгән] **китабы – Сиҗҗинә.**
8. **Сиҗҗиннең ни икәнен син каян белә аласың?**
9. **Язуы ачык булган бер китап.**
10. **Ялганда гаепләүчеләргә ул көнне ни үкенеч!**
11. **Алар Җәза көнен ялган дип саныйлар.**
12. **Аны чиктән ашкан һәм гөнаһ кылганнар гына ялган дип саный.**
13. [Ул Җәза көнен белдергән Коръәнне ялган дип санаган кеше хактан шулкадәр йөз чөергән ки] **Аңа Безнең аятьләребез укылган чакта, ул: «Әүвәлгеләрнең** [уйлап чыгарып] **язган хикәяләре генә», – дип әйтә.**
14. **Юк!** [Бу бозык бәндәнең сүзе һич дөрес түгел!] **Кылган** [начар] **нәрсәләре** [һәм рәттән эшләгән гөнаһлары] **аларның йөрәкләрен**

[мәгънәви бер] **тутык белән каплаган.**
15. **Юк!** [Йөрәкне каплап ала торган мондый гамәлләрне ташлагыз!] **Һичшиксез, ул** [мөэминнәр Аллаһы Тәгаләне күрәчәк] **көнне Раббыларыннан пәрдәләнерләр.**
16. **Шуннан соң алар Утка керәчәкләр** [һәм аның чыдап булмаслык эссесенә түзәргә мәҗбүр ителәчәкләр].
17. **Шуннан соң: «Сез** [дөньяда чакта] **ялган дип санаган нәрсә менә бу!» – дип әйтеләчәк.**
18. **Юк! Һичшиксез, изгеләрнең** [кылган яхшы гамәлләре теркәлгән] **китабы – Гыйльлийүнә.**
19. **Гыйльлийүннең ни икәнен син каян белә аласың?** [Аның нәрсәлеген беркем дә белми бит, Мин генә беләм, менә Мин сиңа белдерәмен].
20. **Язуы ачык булган бер китап.**
21. [Аллаһы Тәгаләгә бик] **Якынайтылганнар аның янында.**
22. **Һичшиксез, изге коллар нигъмәт эчендәләр.**
23. [Кыйммәтле пәрдәләр белән капланган гөмбәзләр астындагы] **Ятакларда** [үзләре теләгән җәннәт манзараларына] **караячаклар.**
24. **Син аларның йөзендә нигъмәтләнү балкышын күрерсең.**
25. **Аларга тамгалы шәраб эчерәчәкләр.**
26. [Дөнья шәраблары балчык кебек нәрсәләр белән тамгаланса] **Аның тамгасы – миск. Омтылучылар** [гыйбадәтләргә ашыгып] **моңа омтылсын.**
27. **Аңа Тәснимнәм** [эчемлек] **кушылган.**
28. **Ул** [Тәсним исә] **– чишмә, аңардан** [Аллаһы Тәгаләгә] **якынайтылганнар эчәчәк.**
29. **Гөнаһ кылганнар иман китергәннәрдән көлделәр.**
30. **Алар** [мөселманнар] **яннарыннан узганда, болар** [кяферләр] **бербersенә күз кысышалар иде.**
31. [Кяферләр мәҗлесләрдән] **Гаиләләренә кайтканда,** [мөэминнәргә кылган мыскыллаулары сәбәпле] **ләззәтләнеп кайталар иде.**
32. **Аларны күргән чакларында исә: «Һичшиксез, болар –** [мөселманнар, Мөхәммәднең хәйләсенә эләгеп, Ахирәтне көтә-көтә, булган ләззәтләрне калдырып] **адашкан кешеләр!» – дияләр иде.**
33. **Әмма алар** [мөселманнарның ни эшләгәннәрен күзәтеп йөрергә] **сакчылар итеп аларга җибәрелмәгәннәр иде.**
34. [Дөньяда мөшрикләр мөэминнәрдән көлгәннәре кебек] **Ул көндә**

**иман китерүчеләр кяферләрдән көләчәкләр.**
35. [Кыйммәтле пәрдәләр белән капланган гөмбәзләр астындагы] **Ятакларда** [үзләренең җәннәттәге нигъмәтләренә] **караячаклар.**
36. [Мөэминнәрдән мыскыл итеп көлгән] **Кяферләр** [дөньяда] **кылганнарының җәзасын алдылармы?**

## 84. Әл-Иншикак (Ярылу) сүрәсе

Мәккә чоры, 25 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. **Күк** [ак болыт белән] **ярылгач.**
2. [Күк Аллаһы Тәгаләнең әмерендәге бер барлык булганлыктан һәм тәүге яратылышында итагать вәгъдәсен бирүен исәпкә алып, сүз тыңларга] **Тиеш булганча Раббысын тыңлап, итагать иткәч.**
3. [Тауларның юк булуы белән] **Җир түшәлеп, төз хәлгә килгәч.**
4. **Эчендәгеләрне** [туфрак өстенә] **чыгаргач һәм бушагач.**
5. [Җирнең дә] **Тиеш булганча Раббысын тыңлап, итагать иткәч** [адәм баласы кылган гамәлләре белән очрашачак]**.**
6. **И, кеше! Һичшиксез, син Раббыңа таба** [яхшы яки яман юлда] **омтылачаксың һәм, нәтиҗәдә, Аның** [сиңа бирәчәк савап яки җәзасы] **белән очрашачаксың.**
7. **Кемгә китабы уң кулына бирелә.**
8. **Җиңел хисапка тартылачак.**
9. [Мөэмин булган] **Гаиләсенә сөенечле хәлдә кайтачак.**
10. **Кемгә исә китабы арка ягыннан** [сул кулына] **бирелә.**
11. **Ул** [«И, үлем! Кил!» – дип] **һәлакәтне чакырачак.**
12. **Һәм** [охшашы күрелмәгән] **Утка керәчәк.**
13. **Чөнки ул** [дөньяда чакта] **гаиләсе арасында** [Ахирәтне һич уйламыйча] **сөенечле хәлдә иде.**
14. **Ул бит** [Раббысына] **кайтмаячак дип саный иде.**
15. **Юк! Һичшиксез, Раббысы аны күреп тора.**
16. [Кояш баеганнан соң офыкта күренә торган кызыллыктан гыйбарәт] **Шәфәкъ белән ант итәмен.**
17. **Төн һәм ул** [караңгылыгы өчен] **туплаган нәрсәләр белән дә** [ант итәмен]**.**
18. **Тулган ай белән дә** [ант итәмен]**.**
19. **Сез** [үлем һәм аңардан соң] **бер хәлдән икенче хәлгә күчәчәксез**

[һәм бер-бер артлы бик читен вакыйгалар белән очрашачаксыз]**.**
20. **Ни өчен соң алар** [Кыямәт көненә] **ышанмыйлар?**
21. **Һәм Коръән укылган чакта сәҗдә кылмыйлар?**
22. **Кяферләр** [терелүне дә, Коръәнне дә] **ялган дип саныйлар.**
23. **Ләкин Аллаһы** [көферлек белән] **нәрсә саклаганнарын яхшырак белә.**
24. **Аларны тилмерткеч бер газап белән сөендер.**
25. **Әгәр** [Коръәнгә] **иман китергән һәм** [намаз, ураза, хаҗ, зәкят кебек] **изге гамәлләр кылган булмасалар гына. Аларга бетмәс-төкәнмәс әҗер** [әзерләп куелган]**.**

## 85. Әл-Бүруҗ (Йолдызлыклар) сүрәсе

Мәккә чоры, 22 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. **Йолдызлыклар иясе булган күк белән ант итәмен.**
2. **Вәгъдә ителгән Көн белән дә** [ант итәмен]**.**
3. [Ул көнне] **Шаһитлык кылачак һәм шаһитлык кылыначак белән дә.**[1]
4. **Һәлак булсын чокыр ияләре!**
5. **Ягыла торган нәрсәләргә ия** [эченә ыргытылган утыннар һәм кешеләр белән тулы] **булган ут** [ияләре]**.**
6. **Менә алар аның тирәсендә утыралар.**
7. **Алар – мөэминнәргә кылган нәрсәгә** [хөкемдарның хозурында бер-берләренә] **шаһитлар.**
8. **Алар** [кяферләр], **Бөек һәм Мактаулы булган Аллаһыга иман китергәннәре өчен, боларны** [мөселманнарны] **яман күрделәр ки.**
9. **Күкләрнең һәм җирнең хөкемдарлыгы – Аныкы гына. Аллаһы – һәрнәрсәгә шаһит.**
10. **Иман китергән ирләр белән иман китергән хатыннарны** [диннәре аркасында төрле җәфалаулар белән] **газаплаучыларга, тәүбә итмәгәннәре өчен, җәһәннәм газабы, Ут газабы** [әзерләп куелган]**.**

1 Әгәр дә «шаһит» дигәннән күз уңында Аллаһы Тәгалә тотылса, «мәшһүд (шаһитлык кылынган)» дигәне бөтен барлыклар була. Әгәр дә «шаһит» дигәннән күз уңында Расүлуллаһ (саллаллаһу галәйһи вә сәлләм) тотылса, «мәшһүд» – ахырзаман өммәте. Әгәр дә җомга көне булса – җомга әһеле, хәҗәре әсвәд булса, аның хакында сорашучылар була. Әгәр дә «шаһит» көннәр һәм төннәр буларак тәфсир ителсә, бөтен кешеләр «мәшһүд» булып кабул ителә.

11. **Һичшиксез, иман китергән һәм изге гамәлләр кылганнар өчен** [агачларының] **асларыннан елгалар агып торган җәннәтләр** [әзерләп куелган]**. Бу – олы бер котылу.**[1]
12. **Һичшиксез, синең Раббыңның җәзасы бик каты!**
13. **Һичшиксез, Ул** [бөтен җан ияләрен] **баштан яраткан,** [үлемнәреннән соң терелтеп] **кабат кайтарыр.**
14. **Ул –** [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче,** [Үзенең иманлы колларын] **Яратучы.**
15. **Гарешнең Иясе,** [Заты һәм сыйфатлары бик зур булган] **Иң хөрмәтле.**
16. **Теләгән һәрнәрсәне кылучы.**
17. [Расүлем! Пәйгамбәрләренә каршы берләшкән бозык] **Гаскәрләрнең хәбәре сиңа ирештеме?**
18. **Фиргавеннең һәм сәмудның?**
19. **Әйе!** [Синең кавемеңнән] **Инкяр итүчеләр** [аларны газапка сөйрәп илтәчәк] **ялган эчендәләр.**

---

1 Суһәб радыяллаһу ганһедән риваять ителгән бер хәдис-шәрифтә бәян ителгәнчә, элекке өммәттә бер хөкемдар, сихерчесенең картайганын күреп, аның сихер осталыгына өйрәнү өчен, янына бер бала җибәргән. Ул бала аңа килеп-китеп йөргән чакта юлда очраткан бер галимнең вәгазьләреннән тәэсирләнеп сихерчене ташлаган да шул галимнең өйрәткәннәре белән гамәл кыла башлаган һәм шулкадәр алга киткән ки, догасы белән сукырлар, авырулар төзәлә башлаган. Хөкемдарның якыннарыннан сукыр булган бер кеше бу хакта хәбәр алып, аңа бик кыйммәтле бүләкләр китергән һәм үзенә шифа бирүен сораган. Ләкин бала шифаны бары тик Аллаһы кына бирүен белдереп, Аллаһыга иман шарты белән аңа дога кыла алачагын әйткән. Әлеге кеше иман китергәч, баланың догасы белән күзләре ачылган. Бу хәлне күргән мәлик күзләрен кем ачуын сораган. Ул: «Раббым», – дигәч, хөкемдар: «Синең миннән башка Раббың бармы?» – дигән. Ул: «Синең дә, минем дә Раббым – Аллаһы!» – дигәч, аны җәфалый-җәфалый, баланың догасы белән төзәлгәнен белгән. Шуннан баланы китертеп, аңардан да шул ук җавапларны алгач, аңардан теге галимнең кемлеген белгән. Тиз арада галимне дә, күзе ачылган якынын да үзе янына алдырган, тегеләр диннәреннән кайту тәкъдимен кабул итмәгәч, аларны тимер пычкы белән җәзалап үтерткән. Шуннан соң балага да шул ук тәкъдимне ясаган, ләкин кире җавап алгач, аны кешеләренә тапшырып, аларга аны бер тауның түбәсеннән аска ыргытырга әмер иткән. Бу вакытта, бала догасы белән тау тетрәп, һәркем үлгән. Ә бала котылып, хөкемдар янына кайткан һәм: «Синең кешеләреңә каршы миңа Аллаһы җитәрлек булды!» – дигән. Хөкемдар кешеләренә аны бер көймә белән ачык диңгезгә чыгарып, калдырып китәргә әмер иткән, ләкин ул янә дога кылгач, көймә кире кайткан. Шулай итеп ул, котылып, хөкемдарга килгән һәм Аллаһының аңа җитәрлек булганын әйткәннән соң: «Син нишләсәң дә мине үтерә алмассың, ләкин бөтен кешеләреңне туплап мине бер хөрмә агачына бәйләсәң, шуннан соң капчыгымнан бер ук алып: «Бу баланың Раббысы булган Аллаһының исеме белән!» – дип атсаң, менә шулвакыт мине үтерә алырсың», – дигән. Хөкемдар шулай иткән дә, ләкин бала теләгенә ирешкән, чөнки бу вакыйгадан соң кешеләр аның Раббысы булган Аллаһыга иман китергәннәр. Курыккан нәрсәсенең башына төшкәнен күргән хөкемдар, бик борчылып, юл башларында зур-зур чокырлар казыткан һәм эчләрен ут белән тутырткан, диненнән кайтмаганнарны шул утка ыргытырга әмер биргән. Бу вакытта кочагындагы баласы белән килгән бер хатын, утка эләкмәс өчен, туктап калган, баласы телгә килеп: «Әнием! Сабыр ит, чөнки син хак юлдасың!» – дигән (Мөслим, Зүһд: 17, № 3005, 4/2301; Тирмизи, Тәфсир: 77, № 3340, 5/437). Риваятьтән күренгәнчә, бу вакытта ут көчәеп киткән һәм янган мөэминнәрне карап торган хөкемдар һәм аның кешеләрен дә эченә алып һәлак иткән (Җәләләйн, Бәйдави, Нәсәфи).

20. **Аллаһы исә** [аларны] **арка якларыннан уратып алучы** [уратып алынган нәрсә үзен уратып алучыдан котыла алмаганы кебек, алар да Аллаһы Тәгаләнең гыйлем һәм кодрәт даирәсеннән читтә кала алмаслар һәм Аны берничек тә гаҗиз калдыра алмаслар]**.**
21. **Әйе, ул –** [алар инкяр иткән китап] **шәрәфле Коръән.**
22. **Ләүһүл-Мәхфүздә.**[1]

## 86. Әт-Тарик (Төнге юлчы) сүрәсе

Мәккә чоры, 17 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. **Күк һәм төнге юлчы белән ант итәмен!**
2. **Төнге юлчының ни икәнен син каян белә аласың?**
3. [Ул – яктысы белән караңгылыкны] **Тишеп үтә торган йолдыз.**
4. **Янында** [гамәлләрен күзәтеп торган] **сакчы булмаган бер генә җан да юк.** [Кеше янында аның кылган бар эшен язып баручы һәм аны тәкъдирендә булмаган хәвеф-хәтәрдән саклаучы төрле фәрештәләр бар].
5. **Кеше нәрсәдән яратылганлыгына карасын.**
6. **Ул атылып чыккан судан яратылды.**
7. **Ул** [су атаның] **бил сөяге белән** [ананың] **күкрәк сөякләре арасыннан чыга.**
8. **Һичшиксез, Ул** [Аллаһы Тәгалә] **аны** [юктан бар итүеннән соң, үтереп, туфрак иткәннән соң, кабат җанын тәненә] **кайтарырга** [көче җиткән] **Кодрәтле.**
9. **Серләр ачыласы көнне** [Раббысы аны терелтәчәк]**.**
10. **Аның ни көче, ни ярдәмчесе юк.**
11. [Ел саен бер үк фасылларда яңгырлар] **Кайтару иясе булган күк белән ант итәмен!**
12. [Үләннәр, агачлар белән] **Ярылган җир белән ант итәмен!**
13. **Һичшиксез, бу –** [Коръәни Кәрим хак белән хаксызлыкны] **аерган бер сүз.**
14. **Ул һич шаярту түгел.**
15. **Һичшиксез, алар** [Коръәннең нурын сүндерү мәсьәләсендә] **хәйлә коралар.**

1 Риваятьтән күренгәнчә, Ләүһүл-Мәхфүз ап-ак энҗедән булып, озынлыгы – җир белән күк арасы, иңе исә көнчыгыш белән көнбатыш арасы кадәр. Аның чит-читләре энҗе һәм якут, каләме исә – нур. Гарешкә бәйле булган бу ләүхәгә Аллаһы Тәгалә көн саен өч йөз алтмыш мәртәбә күренә (Алуси).

16. **Мин дә** [аларны әкрен-әкрен газапка таба тартып] **моның өчен җавап бирәчәкмен.**
17. [Расүлем!] **Син кяферләргә мөмкинлек бир, аларны** [җәзалауны] **бераз кичектер.**

## 87. Әл-Әгъләә (Иң өстен) сүрәсе

Мәккә чоры, 19 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. **Бөек булган Раббыңның исемен тәсбих ит.**
2. **Ул** [һәрнәрсәне] **яратты һәм төзек итте.**
3. **Ул** [барлыкларның җенесләрен, төрләрен үлчәп] **тәкъдир итте һәм** [яратылыш максатына] **юнәлдерде.**
4. **Ул** [терлекләргә] **утлауларны чыгарды.**
5. **Шуннан** [аның яшел хәленнән] **соң аны кап-кара чүпкә әйләндерә.**
6. [Расүлем!] **Без сиңа укытачакбыз, һәм син** [Коръәнне] **онытмаячаксың.**
7. **Мәгәр Аллаһы** [хөкемен һәм укылуын нәсех итүне] **теләмәгән булса. Һичшиксез, Ул ачык булганны да, яшерен булганны да белә.**
8. **Без сине җиңел булганга ирештерәбез.**
9. **Шулай булгач, син** [Коръән белән] **үгет бир, ул үгет файда бирсә** [бәгырьләре каткан кешеләргә файда бирмәгәне билгеле]**.**
10. [Аллаһыдан] **Курыккан кеше, һичшиксез, үгет алачак.**
11. **Әмма начар кеше аңардан ераклашыр.**
12. **Ул зур Утка керәчәк.**
13. **Шуннан соң ул анда үлә дә алмаячак,** [рәхәтлектә] **яши дә алмаячак.**
14. [Гөнаһлардан] **Арынган кеше уңышка ирешер.**
15. [Намазга ниятләнеп] **Раббысының исемен зикер иткән һәм шуннан соң** [биш вакыт] **намаз укыган.**
16. [И, коллар!] **Сез дөнья тормышын өстен куясыз.**
17. **Югыйсә Ахирәт** [фани дөньядан] **яхшырак һәм дәвамлырак.**
18. **Һичшиксез, бу әүвәлге сәхифәләрдә** [дә] **бар иде.**
19. **Ибраһимның һәм Мусаның** [галәйһимәссәләм] **сәхифәләрендә.**

# Хаж

# Хаҗ кылуга кагылышлы мәсьәләләр

**С.:** Хаҗның телдәге һәм шәригатьтәге мәгънәсе нәрсәне аңлата?

**Җ.:** Телдә «хаҗ» – «бөеклеккә омтылу», шәригатьтә - махсус урынга махсус вакытта махсус гамәлләр белән зиярәт кылудыр.

**С.:** Исламда хаҗның хөкеме нинди?

**Җ.:** Хаҗ – Ислам әркәннәренең берсе. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйткән: **«Көче җиткән кешеләргә Аллаһыга гыйбадәт өчен хаҗ кылу – фарыз».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:97

**С.:** Хаҗ кылу кемгә вәҗиб?

**Җ.:** Хаҗ кылу – азат, акыллы, балигълыкка ирешкән мөселманга сәфәре тәмамланганчы транспорт белән тәэмин итә алырлык һәм шул ук вакытта гаиләсенең яшәешенә җитәрлек малы булган бай кешегә фарыз була. Хатын-кызны озатып баручы мәхрамы, ягъни әтисе, туган абыйсы яки ире булырга тиеш. Әгәр Мәккәгә бару юлы бер намаз вакыты кадәр яки аннан да артыграк вакытны алса, мәхрам кирәк була.

## Хаҗның фарызлары, вәҗибләре һәм сөннәтләре

**С.:** Хаҗның фарызлары ничә?

**Җ.:** Хаҗның 3 фарызы бар:

1. Ихрам кию;
2. Гарәфәт тавында басып тору;
3. Тәваф кылу.

**С.:** Вәҗибләре нинди?

**Җ.:** 1. Корбан гаетенең таңы атканда Мөздәлифә үзәнлегендә басып тору;

2. Сафа һәм Мәрва таулары арасында йөгерү;

3. Таш ату;

4. Саубуллашу тәвафы;

5. Чәчне кыскарту яки бөтенләй кыру;

6. Кояш баеганчы Гарәфәт тавында басып тору;

7. Кыйран һәм тәмәттүгъ өчен корбан чалу;

8. Мөфриднең тәртибе болай: баштан таш ата, аннан соң чәчен кыра яисә кисә. Кыйран вә тәмәттүгънең тәртибе: баштан таш ата, аннары корбан чала, ахырдан чәчен кыра яисә кисә;

9. Зиярәт тәвафын корбан көннәренең берсендә үтәү;

10. Чәч кыру яисә кисү изге Әл-Харам территориясендә булырга тиеш;

11. Корбан көннәрендә хаҗ кылу.

## Хаҗның сөннәтләре

1. Карин һәмерактан килүченең (мөфрид) килеп җитү тәвафы (Тәвафе кодум);

2. Тәваф өчен ихрам кигәннән соң, Сафа һәм Мәрва таулары арасында йөгерергә ниятләү;

3. Зөлхиҗҗәнең 8 нче көнендә Минага барып куну;

4. Гарәфә көнендә (зөлхиҗҗәнең 9 нчы көне) кояш чыкканнан соң Минадан Гарәфәт тавына чыгу;

5. Корбан чалу көнендә Мөздәлифәдә куну;

6. Гарәфәт тавында госел алу;

7. Корбан чалуның калган көннәрендә Минада куну.

## Микатлар

*(хаҗ яки гомрә кылу өчен Мәккәгә кергәндә ихрам кигән хәлдә керергә кирәк булган урыннар)*

**С.:** Ихрам хәлендә генә үтәргә мөмкин булган урыннарны әйтегез?

**Җ.:** Алар бишәү:

1. Мәдинә әһелләре һәм шул яктан килүчеләр өчен ул урын – Зөл-Хүләйфә;

2. Гыйрак ягыннан килүчеләргә – Зәтү-Гыйрак;

3. Сүрия һәм Ливан ягыннан килүчеләргә – Әл-Җүхфә;

4. Нәҗдә ягыннан килүчеләргә – Карнүл-Мәнәзил;

5. Йәмән ягыннан килүчеләргә – Яләмләм.

**С.:** Әл-Харамда яшәүчеләрнең микаты кайда?

**Җ.:** Аларга Әл-Хил (микат һәм Әл-Харам арасында булган җирлек) дип аталган урын микат булып тора. Гомрәгә килгәндә – Әл-Хил, ә хаҗга килгәндә – Әл-Харам дигән урын микат булып санала.

**С.:** Микатка кадәр ихрам кияргә ярыймы?

**Җ.:** Әйе, әгәр кеше хаҗ айларында берәр тыелган нәрсәне бозудан курыкмаса, ихрам киюе әйбәтрәк.

**С.:** Мәккәгә киткән кеше юлында микат тапмаса, аңа нишләргә?

**Җ.:** Микатлар арасындагы сызыкны кисеп үткәндә, ихрамга керергә кирәк.

**С.:** Әгәр ихрам микаттан соң гына киелсә, нишләргә?

**Җ.:** Бу хәл ярамый, әгәр болай эшләнелсә, корбан чалдырырга кирәк.

**С.:** Нәрсә ул ихрам?

**Җ.:** Ихрам – ул Аллаһыны сәламләп, хаҗ яки гомрә кылырга ниятләү.

**С.:** Ихрамны билгеле бер сөннәт буенча үтәү юлы бармы?

**Җ.:** Әйе, әгәр кеше ихрамга керергә ниятләсә, аңа госел яки тәһарәт алырга, тегелгән җире булмаган ике кисәк пакь булган материал белән

үзен чорнарга (бер кисәге белән билдән чорнап, икенчесен уң җилкә аша ташлап, гәүдәне чорнарга), әгәр булса, ислемай сөртергә, ябык баш белән 2 рәкәгать намаз укырга кирәк, аннан соң баш киемен салып, хаҗ кылуга ниятләү сүзләре әйтелә:

اَللّٰهُمَّ إِنِّى أُرِيدُ الْحَجَّ فَيَسِّرْهُ لِى وَتَقَبَّلْهُ مِنِّى

*«Аллаһүммә иннии үриидуль-хәҗҗә фәйәссирһү лии вә тәкаббәлһү миннии» («Йә Аллаһы, мин хаҗ кылырга ниятләдем, миңа аны җиңеләйт һәм миннән кабул ит»).*

Аннан соң Аллаһыны сәламләү сүзләре әйтелә:

لَبَّيْكَ اَللّٰهُمَّ لَبَّيْكَ لَبَّيْكَ لَا شَرِيكَ لَكَ لَبَّيْكَ إِنَّ الْحَمْدَ وَالنِّعْمَةَ لَكَ وَالْمُلْكَ لَا شَرِيكَ لَكَ

*«Ләббәйкәл-лааһүммә, ләббәйкә, ләббәйкә ләә шәриикә ләкә ләббәйкә, иннәл-хәмдә үән-нигъмәтә ләкә үәл-мүлкә, ләә шәриикә ләк» («Мин Синең каршыңда, йә Аллаһы, мин Синең каршыңда, мин Синең каршыңда. Дөреслектә, хәмед Сиңадыр, нигъмәт һәм куәт Синдәдер, Сиңа тиңдәшләр юктыр!»)*

Һәрбер гыйбарәгә нәрсә дә булса өстәргә мөмкин, ләкин башка сүзләр белән бутарга ярамый. Ошбу сүзләрне әйткәннән соң, кеше ихрамга керә һәм аңа билгеле булган тыелулар йөкләнелә.

**С.:** Әгәр хатын-кызның хәез яки нифас вакыты булса, аңа ихрамга керергә мөмкинме?

**Җ.:** Әйе, мөмкин. Хәез тәмамланганны көтмичә, урын тапса, госел алырга һәм чәчен тарарга, соңра ике рәкәгать ихрам намазын укымыйча, хаҗга яки гомрәгә ният кыларга һәм Аллаһыны сәламләү сүзләрен әйтергә тиеш. Мәккәгә килеп җиткәннән соң, кан агуы беткәнен көтәр, аннары, госел алып, тәваф кылыр.

## Ихрамның тыелулары

1. Буш сүз сөйләшү;

2. Җимагъ кылу;

3. Бәхәсләшү, тарткалашу;

4. Җирдә йөри торган хайваннарны, кошларны үтерү;

5. Ауга чыгу;

6. Ауда хайванның яшеренгән урынын әйтеп, аучыга ярдәм итү;

7. Тегелгән һәм гәүдә формасын күрсәтә торган кием кию;

8. Пирчәткә һәм аяк киеме кию (башмаклары булмаган очракта аяк киеменең тубыкка кадәр булган өлешен кисәргә кирәк);

9. Башны яки битне каплау;

10. Ислемай сөртү;

11. Кырыну, чәч кыскарту яки тәндәге төкләрдән арыну;

12. Тырнакларны кисү;

13. Ислемай сөртелгән һәм бизәлгән, юылмаган кием кию.

Бу тыюлар хаҗда һәм гомрәдә дә бер үк төрле тәэсир итә.

**С.:** Иргә һәм хатын-кызга да бер үк булган яки хатын-кыз өчен генә искәрмә булып килгән тыелулар бармы?

**Җ.:** Киемгә кагылышлы булганнары бар: хатын-кыз ихрам кими, ә үзенең гадәти кийемендә, башы капланган хәлдә кала, ләкин йөзе ачык булырга тиеш.

**С.:** Мөхримгә (ихрам кигән кешегә) гөсел алырга мөмкинме?

**Җ.:** Әйе, ләкин, мәсәлән, башын һәм сакалын юу өчен сабын яки шампунь кулланырга, тәндәге пычракны юып төшерергә ярамый.

**С.:** Мәчет, палатка, машина күләгәсендә торырга ярыймы?

**Җ.:** Әйе, ярый.

**С.:** Хаҗ кылганда сәламләү (тәлбия) сүзләрен күп әйтүнең хөкеме нинди?

**Җ.:** Намаздан соң иртә белән уянганда һәм йокларга ятканда, шулай ук кешеләр белән транспортта очрашканда тәлбия әйтү – мөстәхәб һәм мәндүб.

## Мәккәгә керү һәм Тәвафе кодум

*(килеп җитү тәвафы)*

**С.:** Хаҗи Әл-Мөфрид Мәккәгә кергәннән соң нәрсәдән башларга тиеш?

**Җ.:** Беренче, тәһарәт алып, Әл-Харам мәчетенә юнәлә. Мәчетне күрүгә тәкбир, тәһлил (*«Ләә иләһә илләл-лааһ» сүзләрен*) әйтергә, аннан соң тәваф кыларга (Кәгъбәне 7 мәртәбә әйләнергә) тиеш. Бу гамәл микатларга, чит җирләрдән килүче кешеләргә – сөннәт, һәм ул «Тәвафе кодум» дип атала. Мәккә әһелләренә, микатларга, аның тирә-ягыннан килүчеләргә Тәвафе кодум кылу кирәкми.

**С.:** Тәваф ничек кылына?

**Җ.:** Тәваф Кәгъбәнең тыштагы почмагында булган Кара таштан башлана. Аңа йөз белән борылып, ике кулны күтәреп, тәкбир һәм тәһлил әйтергә, әгәр мөмкинлек булса, уң кул белән ташка кагылырга яки үбәргә; әгәр мөмкинлек булмаса, бер әйбер белән ташка кагылып, шул әйберне үбәргә; әгәр бу да мөмкин булмаса, Кара ташка каршы басып, тәкбир вакытында кебек кулны колакка кадәр күтәреп, аннан соң ташка тигән кебек ишарәләп, кулларны үбәргә кирәк. Аннан сул кул як белән Кәгъбәгә борылып һәм аның ишеге ягына юнәлеп, тәваф кылына. Әл-Хәтыйм стенасы артыннан үтеп (бу стена Кәгъбәнең бер кисәге тирәсендә), аннан соң Әр-Рөкнел Йәмәни почмагын үткәндә почмакка һәм таш янынннан үткән саен, ташка кагылып үтәргә кирәк. Бу тәваф 7 мәртәбә кабатлана һәм һәрбер тәваф ташка кагылудан башлап, ташка кагылу белән тәмамлана.

## Тукыма чорнау

Сафа һәм Мәрва арасында йөгергән вакытта гәүдәгә тукыма чорнау – сөннәт. Шулай ук таулар арасында беренче өч мәртәбә йөгерү, сул җилкә аша тукыманы ыргыту һәм 7 мәртәбә Әр-Рәмел кылу – сөннәт.

**С.:** Сөннәт буенча Әр-Рәмел ничек кылына?

**Җ.:** Җилкәләрне артка җибәреп, горур баручы сугышчы кебек, тиз барырга кирәк.

**С.:** Тукыманы сул җилкә аша ничек ташларга?

**Җ.:** Тукыманы әүвәл гәүдә тирәли чорнарга, ә ахыргы өлешен сул җилкә аша ташларга.

**С.:** Кеше тәвафтан соң берәр нәрсә эшләргә тиешме?

**Җ.:** Әйе, 2 рәкәгать намаз укырга тиеш.

## Тәвафтан соң намаз

**С.:** Тәвафтан соң 2 рәкәгать намаз кайда укыла?

**Җ.:** Ибраһим мәкамы дип аталган урында уку әйбәтрәк, ул урын Кәгъбә белән намаз укучылар арасында була. Әмма мәчетнең башка бер җирендә дә укырга ярый.

**С.:** Бу намазда нинди сүрәләр укысаң әйбәтрәк?

**Җ.:** Җәбир радыяллаһу ганһедән: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу намазда «Кәфирун» һәм «Ихлас» сүрәләрен укыган», – дип риваять ителә [1].

## Сәгый

*(Сафа белән Мәрва арасында йөгерү)*

**С.:** Сафа белән Мәрва арасында йөгерү ничек булырга тиеш?

[1] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

**Җ.:** Тәвафның ике рәкәгать намазыннан соң, кара таш ягына борылып, аңа кагылырга, аннан соң Сафага азрак күтәрелеп: «Иннәс-Сафа вәл Мәрватә миншәгәириллән» аятен укырга кирәк. Аннан соң Кәгъбә тарафына борылып, тәкбир, тәһлил әйтергә һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтергә, үз хаҗәтләреңне сорап дога кыларга һәм 3 мәртәбә:

*«Ләә иләһә илләл-лаһу вәхдәһу ләә шәрикә ләһ, ләһүл мүлкү үә ләһүл хәмдү үә һүә галә күлли шәй ин кадиир, садака Аллаһу уәгдәһу уә нәсара габдәһу уә һәзәмәл әхзәбә уәхдәһу»,* – дип әйтергә кирәк (мәгънәсе: *«Аллаһыдан башка бөек көч юк, Аңа шәриклек итүчеләр юк, мөлкәт Аныкы гына һәм хәмед-мактаулар Аңа гына, һәм Ул һәрнәрсәдән дә кодрәтлерәк, Аллаһы Үзенең вәгъдәсен тотты һәм Үзенең колына җиңү бирде һәм бер Үзе гаскәрне тар-мар итте»).*

Аннан соң Мәрва тарафына омтылырга һәм яшел баганага якынайгач, икенче баганага кадәр йөгерә башларга кирәк. Һәм бу вакытта:

*«Рабби-гъфир ли үәр-хәм вә әнтәл-әгаззуль-әкраму вә тәҗәуәз гаммә тәгләм» (мәгънәсе: «Раббым, гафу ит һәм рәхимле бул, Син – иң бөек һәм юмарт, бөтен-бөтен гөнаһларыбызны гафу кыл»).*

Икенче баганадан соң йөгерү атлауга күчә. Мәрвага менгәч, Сафада нәрсә эшләнелсә, монда да шул ук гамәлләр кылына. Һәм шулай 7 мәртәбә кабатлана, ягъни Сәгый Сафадан башланып, Мәрвада тәмамлана. Сәгый вакытында Аллаһыны зикер итәргә, Коръән укырга, ике яшел багана арасында йөргәндә һәрберсендә йөрешне тизләтергә кирәк. Хатын-кызларга йөгерергә кирәкми.

## Мина үзәнлегенә, аннан соң Гарәфәт тавына килү

**С.:** Хаҗи Тәвафе кодум һәм Сафа белән Мәрва арасындагы сәгыйне тәмамлагач, нишләргә тиеш?

**Җ.:** Харам мәчетендә, җәмәгатьтән аерылмыйча, биш вакыт намаз укырга тиеш, чөнки бу мәчеттә намаз уку башка мәчеттә 100 мең намаз укудан да әйбәтрәк.

Тәрвия көне туу белән, ягъни зөлхиҗҗәнең 8 нче көнендә Минага барып, зөлхиҗҗәнең 9 нчы көненең кояшы чыкканчыга кадәр анда калырга тиеш. Һәм шунда, җәмәгатьтән аерылмыйча, биш вакыт намаз укый.

Кояш чыкканнан соң, Гарәфәт тавына барып, кояш баеганчыга кадәр анда калырга кирәк. Өйләдән соң имам җәмәгать белән бергә өйлә һәм икенде намазларын укый, алар алдыннан намаз уку, Гарәфәт тавында басып тору, Мөздәлифәгә килү, ташларны дөрес ату, корбан чалу, кырыну һәм тәваф кылу рәвеше хакында ике вәгазь сөйли. Аннан соң югарыда искә алынган 2 рәкәгать намазны өйлә вакытында бер азан вә ике камәт белән укыйлар. Әбү Хәнифә хаҗ өчен ихрам кигән хәлдә һәм хаҗда имамның булуын шарт итеп куя. Әгәр берәү, үзе генә яки имам белән хаҗ өчен булмаган намазын укыса, аңа һәрбер намазын аерым укырга кирәк.

**С.:** Намаздан соң нәрсә эшләргә кирәк?

**Җ.:** Гарәфәт тавына килеп госел алырга вә кояш батканчыга кадәр гыйбадәттә булырга кирәк. «Рәхмәт» тавына якын басып торып дога кылу – мөстәхәб гамәл.

Имамга Гарәфәт тавында үз дөясендә булып дога кылырга вә хаҗ тәртипләрен өйрәтү – мөстәхәб.

## Мөздәлифә үзәнлегенә килү

**С.:** Хаҗи Гарәфә көнне кояш батканнан соң нишләргә тиеш?

**Җ.:** Кояш батканнан соң Мөздәлифә үзәнлегенә китәргә һәм шунда азан вә камәт белән, имамга ияреп, ахшам һәм ястү намазларын укырга тиеш (ахшам намазы Гарәфәттә дә, Мөздәлифәгә бару юлында да укылмас).

**С.:** Әгәр дә намазны ялгыз укысаң, бу ике намаз бергә кушылып укыламы?

**Җ.:** Әйе, кушылып укыла, чөнки имам белән уку монда шарт түгел.

**С.:** Әгәр дә ахшам намазын Гарәфәттә яисә Мөздәлифәгә бару юлында укысаң, хөкеме нинди булыр?

**Җ.:** Болай уку ярамас, әгәр шулай укыган булса, намаз яңадан укылыр.

**С.:** Бу намазларны укыгач нишләргә?

**Җ.:** Мөздәлифә үзәнлегендә таң атканчы төн уздырырга, таң җиткәч, иртәнге намазны укырга вә кояш чыкканчыга кадәр Аллаһыга догада булырга кирәк. «Бәтыйн Мәхсәр» дигән урыннан кала, Мөздәлифәнең теләсә кайсы җирендә булырга мөмкин.

## Минага бару, таш ату, корбан чалу һәм чәч кисү

**С.:** Мөздәлифәдә булганнан соң, хаҗи нишләргә тиеш?

**Җ.:** Кояш чыгарга берничә минут калгач, Мина үзәнлегенә барырга кирәк. Барып җитүче таш атарга тотына. Баганага борчактан зур булмаган 7 таш атарга кирәк. Һәрбер таш атканда *«Бисмилләһи, Аллаһу әкбәр, ридаән ли рахмәни вә рагъмән лиш-шәйтани»,* – дип әйтергә кирәк. Тәрҗемәсе: *«Аллаһы исеме белән, Аллаһы бөек, Аллаһы ризалыгы өчен вә шәйтанга каршы».* Таш атканнан соң, баганадан шул минутта ук китәргә кирәк.

**С.:** Хаҗига корбан чалырга кирәкме?

**Җ.:** Хаҗи-мөфрид корбан чалмаса да була, чалса – мөстәхәб.

**С.:** Аннан соң нишләргә?

**Җ.:** Хаҗи-мөфрид корбан көнендә таш атканнан соң, чәчен кыра йә кыскарта. Бу эшләрне эшләгәннән соң, ихрамнан чыккан дип санала һәм якынлык кылудан башка бөтен тыелулар өстеннән төшә. Хаҗи-мөтәмәттигъ һәм карин таш атканнан соң корбан чалалар.

**С.:** Әгәр дә хаҗи-мөфрид корбан чалырга теләсә, кайчан чәчен кыра йә кыскарта ала?

**Җ.:** Корбан чалганчы яисә корбан чалгач кырырга яки кыскартырга мөмкин, тик корбан чалганнан соң – әйбәтрәк.

**С.:** Чәч кайда кырыла яисә кыскартыла?

**Җ.:** Әл-Харам җирлегендә. Әмма башка урыннарда кырылса, корбан чалу лязем була.

## Тәвафе зиярат (Зиярәт тәвафы)

**С.:** Корбан көнендә чәч кырудан тыш тагын үтәлергә тиешле башка йолалар каламы?

**Җ.:** Әйе, ул әле зиярәт тәвафын кылырга тиеш вә бу тәваф фарыз гамәлләрдән санала. Аның вакыты – 3 көн, ягъни корбан көненнән алып, кояш чыкканнан соң, 12 нче зөлхиҗҗәнең кояшы батканчыга кадәр. Әмма корбан көнендә кылу әйбәтрәк. Чәчне кырганнан яки кыскарткannan соң, Мәккәгә барып җиде мәртәбә тәваф кылына. Зиярәт тәвафы кылганнан соң хаҗига хатыны хәләл була.

**С.:** Бу тәвафта рәмел (таш ату) вә идтыйба (ихрамны сул як җилкәгә ташлау) кирәкме?

**Җ.:** Әгәр Тәвафе кодумнан соң хаҗи сәгый кылмаган булса, бу тәвафтан соң сәгый кылырга кирәк. Тик бу вакытта идтыйба кылынмый.

**С.:** Әгәр дә зиярәт тәвафы әйтелгән өч көндә үтәлмәсә, хөкеме нинди?

**Җ.:** Әгәр дә зиярәт тәвафы әйтелгән көннәрдә үтәлмәсә, Әбү Хәнифә фикеренчә, корбан чалу вәҗиб була. Ә аның укучылары уенча, соңга калучылар өстенә бернәрсә дә төшми.

## Корбан көннәреннән соң өч көн эчендә өч таш ату

**С.:** Зиярәт тәвафыннан соң нишләргә?

**Җ.:** Минага кайтырга вә киләсе ике көндә дә өч баганага зәвәл вакытыннан соң таш атарга кирәк. Таш башта кечкенә баганага, аннан соң уртанчысына, ахырдан «җөмрател гъакабә» дигән зур баганага атыла. Һәр атканда тәкбир вә тәһлил әйтелә, кечкенә вә уртача таш атканнан соң, таш аткан урыннан уң тарафка юнәлеп, басып дога кылына. Җөмрәте көбра янында басып дога кылынмый, ә юлда булганда дога кылына.

**С.:** Зәвәлгә кадәр бу көннәрдә таш ату рөхсәт ителәме?

**Җ.:** Таш фәкать зәвәлдән соң гына атыла, әгәр зәвәлгә кадәр эшләнгән булса, зәвәлдән соң яңадан кабатлый.

**С.:** Әгәр хаҗи таш атмаса, аңа нишләргә?

Ул моны зөлхиҗҗәнең 13 нче көнендә эшли ала. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

**«Берәү хаҗ кылганда Минадан ашыгып, икенче көнне Мәккәгә кайтса, аңа гөнаһ юк, берәү кичегеп, өченче көнгә калса, аңа да гөнаһ юктыр, гөнаһтан куркучылар өчен!»**

«Әл-Бәкара» / «Сыер», 2:203

Ләкин кояш баткач, 13 нче көндә таш атмыйча торып, Мәккәдән чыгу – мәкруһ. Әгәр дә 13 нче көннең таңы атса һәм ул Минада булса, бу көндә дә аңа таш ату вәҗиб була.

**С.:** Таш атарга соңга калучы 13 нче көнне таш атарга теләсә, аңа моны кайчан эшләргә кирәк?

**Җ.:** Зәвәлдән соң атар, һәм бу – сөннәт гамәл. Таш ату вакыты кояш батканчы дәвам итә, кояш батканнан соң дөрес булмый. Зәвәлгә кадәр таш ату Әбү Хәнифә фикеренчә, рөхсәт ителә, сөннәткә каршы булу сәбәпле – мәкруһ. Ә укучылары зәвәлгә кадәр таш ату рөхсәт ителми, диләр.

**С.:** Үзе Минада калып, багажны Мәккәгә күчерергә рөхсәт ителәме?

**Җ.:** Бу эш – мәкруһ.

## Видәгъ (саубуллашу) тәвафы

**С.:** Ташлар атып, Мәккәгә кайткач, хаҗига нишләргә?

**Җ.:** Таш атудан соң, видәгъ тәвафы кыларга кала, аны тагын икенче төрле «Тәвафе садер» дип тә әйтәләр. Бу тәваф монда яшәмәүчеләргә – вәҗиб. Мәккәгә кайтканнан соң, видәгъ тәвафы кыларга кирәк, шуннан соң үз ватанына кайтып китсә дә ярый.

**С.:** Бу тәвафта таш ату вә идтыйба эшләргә кирәкме?

**Җ.:** Бу тәвафта таш ату да, идтыйбагъ да юк, чөнки сәгый дә юк.

*Мөхәммәд Гашыйкның «Әт-тәсһил әз-зарури ли мәсәил әл-кудури» китабыннан*

# Корбан чалу

# Корбан чалуның мәгънәсе һәм тарихы

«Корбан» сүзе изге Коръән китабыннан алынган. Аның тамыры гарәп теленең «карубә» – «якынаю» фигыленә барып тоташа. Шулай итеп, «корбан» – нәрсәгә дә булса якынаю, дигән мәгънәне аңлата булып чыга. Диндә бу «якынаю»дан максат бер генә – Аллаһының рәхмәтенә ирешү. Моның өчен мөселман кешесенә үзен, малын вә җанын Хак Тәгаләгә багышлау шарт. Аның корбан чалуы да, ахыр чиктә, Раббысының боерыгын үтәү максаты белән генә булыр. Корбан бәйрәменең асылын адәм баласының Аллаһы әмеренә буйсынуын ихлас гамәл белән исбатлавы тәшкил итә. Корбан итеп китерелергә тиешле әйберне дә Аллаһы Тәгалә Үзе билгеләп куйган, ул да булса – махсус шартларга ия булган хайван. Бөек Раббыбыз Үзенең сөекле бәндәсе Ибраһим пәйгамбәр галәйһиссәламнең буйсыну вә итагатен сынавы буларак, корбан ителергә тиешле булган газиз улын махсус хайванга – куй тәкәгә алыштырган. Бу кыйсса барчаларыбызга да яхшы мәгълүм. Ибраһим пәйгамбәр галәйһиссәламне Раббысы тугрылык сынавы аша уздырырга карар кыла. Башта ул малы белән сынала: Аллаһы Тәгалә аңа «Аллаһы» сүзен әйткән һәрбер кешегә байлыгын өләшергә боера. Шул рәвешле, Ибраһим пәйгамбәр галәйһиссәлам тора-бара кулындагы барча мөлкәтне таратып бетерә, ләкин ахырдан Аллаһы Тәгалә аңа малын бик күп мәртәбәләр арттырып кайтарып бирә. Соңыннан Хак Тәгаләнең бу тугры бәндәсе үз җаны белән имтиханга тартыла. Ул бу юлы да Раббысы хакына мәҗүси кавемдәшләре ташлаган учакта янып үләргә әзер булуын исбатлый. Аллаһы Тәгалә аның бу фидакарьлеген дә кабул итә һәм дөрләп янган ялкын телләрен хуш исле гөлбакчага әвереләдерә. Ниһаять, шәфкатьле пәйгамбәрнең тугрылыгы үз якыннары аркылы сынала. Картаймыш көнендә Раббысы аңа бер угыл бирә. Ибраһим галәйһиссәлам аны үз җаныннан да артык күрә. Улы да бу мәхәббәткә хөрмәт һәм олы-

лау белән җавап кайтара. Ләкин хак төшләр аркылы Раббысы Ибраһим пәйгамбәр галәйһиссәламгә бәгырь җимешен корбан итәргә кирәклеген белдерә. Йокыдан торуга, мәрхәмәтле ата төшен улына сөйләп бирә. Улы исә, атасының сөйләвен сабыр гына тыңлап бетергәннән соң, итагать вә тәслимиятнең иң камил үрнәген күрсәтә. Изге Китабыбыз Коръәндә бу хакта болай дип әйтелә:

فَلَمَّا بَلَغَ مَعَهُ السَّعْيَ قَالَ يَا بُنَيَّ إِنِّي أَرَىٰ فِي الْمَنَامِ أَنِّي أَذْبَحُكَ فَانظُرْ مَاذَا تَرَىٰ ۚ قَالَ يَا أَبَتِ افْعَلْ مَا تُؤْمَرُ ۖ سَتَجِدُنِي إِن شَاءَ اللَّهُ مِنَ الصَّابِرِينَ ﴿١٠٢﴾

**«Ул аның белән бергә (эшләрендә) тырышлык куюга (мөмкинлек биргән унөч яшьләргә) җиткәч (атасы аңа): «И улым! Һичшиксез, мин (берничә төн рәттән) төшемдә сине чалганымны күрдем. Син ни уйлаганыңны кара», – диде. Ул: «И әтием! Сиңа әмер ителгән нәрсәне (һич уйлап тормыйча) үтә. ИншәАллаһ, мине сабыр итүчеләрдән табачаксың», – диде».**

«Саффат / Сафта торучылар», 37:102

Ата белән угыл билгеләнгән урынга килеп җиткәннән соң, Ибраһим галәйһиссәлам улын корбан китерү нияте белән җиргә яткыра. Коръәндә бу хакта түбәндәгеләр язылган:

فَلَمَّا أَسْلَمَا وَتَلَّهُ لِلْجَبِينِ ﴿١٠٣﴾ وَنَادَيْنَاهُ أَن يَا إِبْرَاهِيمُ ﴿١٠٤﴾ قَدْ صَدَّقْتَ الرُّؤْيَا ۚ إِنَّا كَذَٰلِكَ نَجْزِي الْمُحْسِنِينَ ﴿١٠٥﴾ إِنَّ هَٰذَا لَهُوَ الْبَلَاءُ الْمُبِينُ ﴿١٠٦﴾ وَفَدَيْنَاهُ بِذِبْحٍ عَظِيمٍ ﴿١٠٧﴾

**«Ул икәү (Аллаһы Тәгаләнең хөкеменә тулысынча) буйсынгач, ул аны яны белән (җиргә) яткырды. Без аңа дәштек: «И, Ибраһим (галәйһиссәлам)! Син төшне акладың». (Шулвакыт**

**Без аларга бик күп итеп савап бирдек) Һичшиксез, (Ибраһим һәм Исмәгыйль (галәйһимәссәлам) кебек) игелек кылучыларга Без шулай әҗерләрен бирәбез. Һичшиксез, бу – ап-ачык бер сынау. Без аңа фидия итеп зур (кыйммәткә һәм гәүдәгә ия булган) бер корбанлык (сарык тәкәсе) бирдек».**

«Саффат / Сафта торучылар», 37:103–107

Шул рәвешле, Аллаһы Тәгалә аның тугрылыгын кабул итә һәм улы урынына корбан итәргә дип күкләрдән бер тәкә индерә. Бәс, безнең дә чалган корбаннарыбыз Хак Тәгаләгә тугрылыгыбызның бер дәлиле вә исбатыдыр. Корбан – үзең өчен аеруча кадерле булган нәрсәне Аллаһыга багышлаудыр. Раббыбыз ошбу корбанны итен мохтаҗларга тарату мөстәхәб булган хайван белән алыштырган. Моның хикмәтен бигрәк тә авыл җирендә яшәүчеләр, тырышып-кадерләп үстергән малларын Аллаһы ризалыгы өчен чалган тәкъва мөселманнар яхшы аңлый булса кирәк. Кызгану хисе күңелен биләп алса да, ул Аллаһы Тәгалә әмеренә хилафлык кылмас. Хак Тәгалә «Корбан чал!» дип боерган икән, адәм баласы бу әмергә буйсынып, үзе өчен кадерле булган әйберен корбан итәргә тиеш, чөнки Аллаһының фәрманы бар нәрсәдән өстендер.

Корбан чалу – бик борынгы заманнардан килгән гыйбадәт. Аллаһыга якынайта торган гыйбадәт буларак, корбан чалу төшенчәсе булмаган бер генә дин дә юктыр, мөгаен. Аның башы Адәм галәйһиссәлам чорына ук барып тоташа. Изге Коръәндә Адәм пәйгамбәрнең ике улы Кабил белән Һабилнең корбан чалу кыйссасы бәян ителә:

وَاتْلُ عَلَيْهِمْ نَبَأَ ابْنَيْ آدَمَ بِالْحَقِّ إِذْ قَرَّبَا قُرْبَانًا فَتُقُبِّلَ مِنْ أَحَدِهِمَا وَلَمْ يُتَقَبَّلْ
مِنَ الْآخَرِ قَالَ لَأَقْتُلَنَّكَ ۖ قَالَ إِنَّمَا يَتَقَبَّلُ اللَّهُ مِنَ الْمُتَّقِينَ ﴿٢٧﴾

**«Аларга Адәмнең (Һабил белән Кабил исемле) ике улының хәбәрен хак (бер бәян) белән укы. Менә ул икәү берәр корбан тәкъдим иттеләр; аларның берсеннән (бу корбаны) кабул ителде, икенчесеннән исә кабул ителмәде. Ул (корбаны кабул ителмәгән Кабил Һабилгә): «Мин сине, һичшиксез, үтерәчәкмен», – диде. Ул исә: «Аллаһы тәкъвалык ияләреннән генә (корбаннарын) кабул итә», – дип әйтте.**

«Мәидә / Аш табыны», 5:27

Бу вакыйганың асылы шуннан гыйбарәт: ике бертуган арасында гауга кубып, мәсьәләнең хәл ителүе өчен икесеннән дә корбан китерү сорала. Кемнеке Аллаһы тарафыннан кабул кылынса, шул – хаклы. Көтү көтеп көн күргән Һабил корбанлыкка иң кадерле малын – симез тәкәне куя. Иген игеп, шактый мая тупларга өлгергән Кабил исә, корбанга дип сәләмә генә бер бодай көлтәсен китереп сала. Кабилнең корбаны кабул ителми...

## Корбанның хикмәте һәм файдалары

1. Халык арасында бердәмлек һәм ярдәмләшү хисләрен көчәйтә. Динебездә килгән барча гыйбадәтләрдә аерым-аерым һәрбер кеше өчен дә, гомумән җәмгыять өчен дә олы файдалар бар. Мисалга намазны алыйк. Бу гыйбадәт, бер яктан, адәм баласына Аллаһыга кол булуның асыл мәгънәсенә төшенергә ярдәм итсә, икенче яктан, Коръән сүзләре белән әйткәндә, кешене һәртөрле бозыклык вә тыелган эшләрдән саклап тора. Шулай ук, гыйбадәтнең башка төрләре дә, әйтик, ураза, зәкят, хаҗ кебекләр, кеше шәхсиятенә бихисап фазыйләтләр өстәү белән бергә, җәмгыятьтә тотрыклылык һәм бердәмлек булдырырга ярдәм итәләр. Мөселманнарның төп ике бәйрәменең берсе булган Корбан гаете көннәрендә чалынган хайваннар нәкъ менә шул максатка юнәлгән. Кор-

бан чалган кеше гыйбадәт савабы алу өстенә, мескен-фәкыйрьләргә дә ярдәм итеп, җәмгыятьнең бердәмлеген куәтләүгә үзеннән өлеш кертә.

2. Корбан гыйбадәте адәм баласын Раббысына якынайта.

Кеше бик тә онытучан һәм гафиллеккә тартым итеп яратылган. Шуңа да ул малы, балалары, гомумән, бу фани дөньядагы барча мөлкәтенең асыл хуҗасы булган Затны еш кына онытып җибәрә. Бу исә, үз чиратында, анда тәкәбберлек һәм масаючанлык кебек сыйфатларның уянуына китерә. Корбан исә адәм баласына барча мәхлүкатның асыл хуҗасы кем икәнлеген искәртә. Шулай ук аңа бирелгән гомум нигъмәтләрнең Аллаһының рәхмәт әсәре булуын аңларга мәҗбүр итә. Мондый кешенең тора-бара йөрәгендә Раббысына карата шөкер хисләре уяна. Аллаһы ризалыгына илтә торган юл да шуннан башлана.

3. Корбан чалу – кешенең тәкъвалыгы билгесе.

Корбан кешенең илаһи әмерләрне үтәүдәге ихласлыгын чагылдырып, аның тәкъвалык дәрәҗәсен күрсәтеп килә. Корбан гыйбадәте ярдәмендә Аллаһы Тәгалә колларының тәкъвалык мәртәбәсен сыный, илаһи әмерләрне үтәүгә әзерлек дәрәҗәләрен имтихан кыла. Коръәндә бу хакта болай дип әйтелгән:

لَن يَنَالَ اللَّهَ لُحُومُهَا وَلَا دِمَاؤُهَا وَلَـٰكِن يَنَالُهُ التَّقْوَىٰ مِنكُمْ ۚ كَذَٰلِكَ
سَخَّرَهَا لَكُمْ لِتُكَبِّرُوا اللَّهَ عَلَىٰ مَا هَدَاكُمْ ۗ وَبَشِّرِ الْمُحْسِنِينَ ﴿٣٧﴾

**«Аларның итләре дә, каннары да Аллаһыга ирешәчәк түгел. Аңа сездән бары тәкъвалыгыгыз гына ирешә. Сезне һидаятькә ирештерде дип («Аллаһу әкбәр» дип) Аллаһыга тәкбир әйтүегез өчен Ул аларны сезгә буйсындырды. (Расүлем!) Күркәм гамәл ияләрен сөендер».**

«Хаҗ», 22:37

Икенче бер аятьтә исә болай дип әйтелгән:

ذَٰلِكَ وَمَن يُعَظِّمْ شَعَائِرَ اللَّهِ فَإِنَّهَا مِن تَقْوَى الْقُلُوبِ ﴿٣٢﴾

**«Менә шулай! Кем дә кем (Сафа-Мәрвә кебек) Аллаһының (диненең) билгеләрен (бигрәк тә корбанлык хайваннарын) олыласа, һичшиксез, ул – күңелләрнең (Аллаһы Тәгаләгә карата булган) тәкъвалыгыннан».**

«Хаҗ», 22:32

4. Корбан гыйбадәте безгә Аллаһы боерыгына буйсынуның Ибраһим һәм Исмәгыйль галәйһимуссәлам тормышында дастани югарылыкка ирешкән мисалын искәртә. Алдарак искәртелгәнчә, күп гасырлар буена яшәп килгән бу күркәм йоланың чишмә башында Аллаһының бөек илчесе вә расүле булган Ибраһим галәйһиссәлам торганын күрәбез.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе сүзләренә караганда, хәзрәти Ибраһим иң бөек биш пәйгамбәр җөмләсеннән. Изге Коръәндә килгән кыйссадан[1], без Ибраһим галәйһиссәламнең үткен зиһенле, мөшрикләргә каршы торудан гаҗәеп чыдам һәм кыю, хөр вә какшамас иманлы, көферлекнең иң кечкенә галәмәтләреннән дә пакь кеше булуын укып беләбез.

Әлеге кыйсса могътәбәр галимнәребезнең тәфсир китапларында болайрак тасвир кылына: пәйгамбәрлек вазифасын үтәү барышында, Ибраһим пәйгамбәр галәйһиссәлам мөшрикләрне ялгыш инануларыннан кире чигенергә, барча мәхлүкатны юктан бар кылган һәм тәрбия кылып торган Аллаһыдан гайре кемне яки нәрсәне дә булса илаһ итеп тотудан тыелырга чакыра. Ул аларның акылларына мөрәҗәгать итеп, «үзе дә юктан бар кылынган нәрсә ничек инде илаһ була алсын?» дигән сорау куя. Берсендә ул җем-җем килеп торган йолдызга ишарәләп: «Шушымы инде минем Раббым?» – дип оран сала. Ә бу йолдыз сүнеп, күк гөмбәзендә күренмәс булуга, үз соравына үзе җавап биргәндәй: «Үзгәреп,

[1] «Әнгәм / Терлек», 6:76.

алышынып торган нәрсә һичничек илаһ була алмый, чөнки үзгәреп тору – мәхлукатка хас сыйфат. Ә Аллаһы исә – мәңгелек, Аның сыйфатлары да мәңге үзгәрешсез», – дип нәтиҗә ясый.

Коръәндә Аллаһы Тәгалә Үзенең сөекле илчесе Ибраһим галәйһиссәламгә туры юлны[1] күрсәтүе һәм аның мөшрикләр җөмләсеннән булмавы[2] хакында бәян итә.

Хак Тәгалә Ибраһим галәйһиссәламнең иманын куәтләр өчен, аңа сынау арты сынау җибәреп тора. Шәфкатьле пәйгамбәр, илаһи фәрманга буйсынып, үз улы Исмәгыйльне корбан итәргә тиеш була. Бу боерыкны җиренә җиткереп үтәү ниятеннән, Ибраһим галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләгә буйсынуның тиңсез үрнәген күрсәтә. Сабый баланың каны түгелүне теләмәгән Раббыбыз Ибраһим галәйһиссәламнең корбанын ниятенә карап кабул итә, ә корбанга Исмәгыйль урынына куй тәкәсе чалына.

5. Корбан чалу – Аллаһы биргән исәп-хисапсыз нигъмәтләргә шөкер итү билгесе.

Аллаһы Тәгалә безне иге-чиге булмаган нигъмәтләр белән уратып алган, аларның барысы да бездән шөкер итүне сорый. Корбан гыйбадәте исә шөкернең иң ачык чагылышларының берсе. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип бәян итә:

وَالْبُدْنَ جَعَلْنَاهَا لَكُم مِّن شَعَائِرِ اللَّهِ لَكُمْ فِيهَا خَيْرٌ ۖ فَاذْكُرُوا اسْمَ اللَّهِ عَلَيْهَا صَوَافَّ ۖ فَإِذَا وَجَبَتْ جُنُوبُهَا فَكُلُوا مِنْهَا وَأَطْعِمُوا الْقَانِعَ وَالْمُعْتَرَّ ۚ كَذَٰلِكَ سَخَّرْنَاهَا لَكُمْ لَعَلَّكُمْ تَشْكُرُونَ ﴿٣٦﴾

**«Зур башлы хайваннарны (дөяләрне) Без сезнең өчен Аллаһының билгеләреннән иттек, аларда сезнең өчен файда бар. Инде**

[1] «Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:51.

[2] «Әл-Бәкара / Сыер», 2:135.

**(дөяләрне ятып торганда түгел, аякларын) сузган хәлендә чакта (корбан итегез һәм чалган вакытта) алар өстендә Аллаһының исемен искә алыгыз. (Җаннары чыгып) Яннарына аугач, (теләсәгез) алардан ашагыз, канәгатьле булганга да, (сораныр өчен юлыгызга аркылы төшкән) теләнчегә дә ашатыгыз. Без шулай итеп аларны сезгә итагать иттердек (шуңа аларны бәйләп бугазлый аласыз). Бәлки, сез шөкер итәрсез».**

«Хаҗ», 22:36

6. Корбан чалу – гөнаһлардан арыну һәм гыйбадәтне кимчелекләрдән пакьләү чарасы:

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм кызы Фатыймага эндәшеп, болай дигән: «Әй Фатыйма! Чалган корбанлыгың янында басып тор. Шуны бел: аның җиргә тамган беренче тамчы каны белән үк синең гөнаһларың ярлыканыр».

*«Хозур» нәшриятының «Корбан» китабыннан*

# Нәсыйхәт

# Олы гөнаһлар

## Ялган шаһитлык китерү

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَالَّذِينَ لَا يَشْهَدُونَ الزُّورَ

**«[Рахманның сайлап алынган коллары] Янә ялганга шаһит булмыйлар...»**

«Фуркан / Аеручы», 25:72

Ибне Хөзәймә һәм Ибне Хиббәннән болай дип тапшырыла:
«Ялган шаһитлык китерү Аллаһыга ширек китерү белән бер».
Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

ذَٰلِكَ وَمَن يُعَظِّمْ حُرُمَاتِ اللَّهِ فَهُوَ خَيْرٌ لَّهُ عِندَ رَبِّهِ ۗ وَأُحِلَّتْ لَكُمُ الْأَنْعَامُ إِلَّا مَا يُتْلَىٰ عَلَيْكُمْ ۖ فَاجْتَنِبُوا الرِّجْسَ مِنَ الْأَوْثَانِ وَاجْتَنِبُوا قَوْلَ الزُّورِ ﴿٣٠﴾

**«Шулай [бу әмерләрне тотыгыз]! Кем Аллаһы хөрмәтле кылган нәрсәләрне олыласа, менә бу аның өчен Раббысы хозурында хәерлерәк. [Харамлыклары] Сезгә бер-бер артлы укылып торганнардан [үләксә һәм бисмилләһсез суелган хайваннардан тыш, дөя, сыер, сарык һәм кәҗә кебек] терлекләр сезгә хәләл кылынды. Моннан соң [матди нәҗесләрдән сакланганыгыз кебек, рухи] нәҗес булган потлардан да сакланыгыз, ялган сүздән дә [һәм ялган шаһитлыктан да] качыгыз».**

«Хаҗ», 22:30

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер хәдисендә:

«Ялган ант китерүче өчен җәһәннәмгә керү тиеш булганчыга кадәр аның аяклары да урыныннан кузгалмас», – дип әйтелә[1].

Ялган шаһитлык бирүче кеше бер үк вакытта берничә башка гөнаһ та кыла:

1. Ялган һәм яла ягу.

إِنَّ اللَّهَ لَا يَهْدِي مَنْ هُوَ مُسْرِفٌ كَذَّابٌ ﴿٢٨﴾

**«Һичшиксез, Аллаһы чиктән ашкан һәм ялганчы булган кешене һидаять итми».**

«Мөэмин», 40:28

Хәдистә болай дип әйтелә: «Мөселманнарда, ялган һәм хыянәттән тыш, холыкның теләсә нинди сыйфатлары булырга мөмкин».

2. Ялган шаһитлык кылып, кешенең мөлкәтен, намусын һәм җанын югалтуга китерә.

3. Кешегә зыян китерү, яла ягудан табыш алу, чөнки бу кеше үзенә тыелган (анык булмаган) милекнең хуҗасы булачак һәм шуның аркасында җәза итеп җәһәннәмдә газап алачак.

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр дә мин бер кешенең милкен икенчесенә тапшыру турында гадел булмаган карар чыгарсам, икенчесе аны алмасын. Бу адым белән мин аның өчен уттан кием әзерләячәкмен».

4. Аллаһы Тәгалә билгеләгән мөлкәтнең, канның һәм намусның кагылгысызлыгын һәм тыелуы турындагы нигезләмәләрне юкка чыгару. Бу уңайдан Аллаһы Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Теләсә кайсы мөселман кешесенең намусы, милке һәм каны башка мөселман кешесе өчен изге булып тора»[2].

---

1 Хәким, Мөстәдрәк, Китаб Әл-Әхкәм, 4/98. Имам Зәһәби бу хәдисне дә дөрес дип саный: «Аллаһы Тәгалә ялган шәһадәт бирүченең урынын җәһәннәм итеп билгеләгәнче, аякларын да урыныннан кузгалта алмас».

2 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан: Китаб Әл-Әдәб», 665;

[Шулай ук тагын бер хәдистә болай дип әйтелгән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм:] «Иң авыр гөнаһларны сезгә әйтимме? Ул:

– күпаллалык (ширек);

– ата-анага каршы килү, тыңламау;

– ялган шаһитлык китерү.

Сәхабәләр Аллаһы Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бу сүзләрне бик күп кабатлаганга күрә: «Әгәр дә ул туктаса иде!» – дип әйтергә мәҗбүр булганнар[1].

## Инсафлы хатын-кызга яла ягу

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

إِنَّ الَّذِينَ يَرْمُونَ الْمُحْصَنَاتِ الْغَافِلَاتِ الْمُؤْمِنَاتِ لُعِنُوا فِي الدُّنْيَا وَالْآخِرَةِ وَلَهُمْ عَذَابٌ عَظِيمٌ ﴿٢٣﴾

**«[Зинадан] Сакланган һәм [гаепләнгән нәрсәләрдән] хәбәрсез булган иманлы хатыннарга [зина кылу гаебе] ташлаган кешеләр [тәүбә итми торып] дөньяда һәм Ахирәттә ләгънәтләнгәннәр. Алар өчен бик каты газап бар».**

«Нур», 24:23

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

الزَّانِي لَا يَنكِحُ إِلَّا زَانِيَةً أَوْ مُشْرِكَةً وَالزَّانِيَةُ لَا يَنكِحُهَا إِلَّا زَانٍ أَوْ مُشْرِكٌ ۚ وَحُرِّمَ ذَٰلِكَ عَلَى الْمُؤْمِنِينَ ﴿٣﴾

**«[Зинадан] Сакланган [намуслы, кол булмаган, мөселман һәм мөкәлләф] хатыннарга [«Фахишә, зиначы, азгын хатын» кебек сүзләр белән яла ягып] гаеп ташлаган, шуннан соң дүрт шаһит китермәгән кешеләрне сиксән мәртәбә [камчы белән] суктыры-**

1 Имам Бохари һәм Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

**гыз һәм беркайчан да аларның шаһитлыкларын кабул итмәгез. Алар – [итагатебездән чыккан] фасыйклар».**

«Нур», 24:4

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Җиде һәлакәткә китерә торган гөнаһтан сакланыгыз», – диде һәм алар арасында (зина турында уйлап та карамаган) инсафлы мөселман хатын-кызларына яла ягуны да искә алды.

Бер кеше Пәйгамбәребез янына килеп: «Мөселманнарның иң хәерлесе кем булыр», – дип сораган. «Кулыннан һәм теленнән калганнар имин булганы»[1], – дип әйтте.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَالَّذِينَ يُؤْذُونَ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ بِغَيْرِ مَا اكْتَسَبُوا فَقَدِ احْتَمَلُوا بُهْتَانًا وَإِثْمًا مُّبِينًا ﴿٥٨﴾

**«[Кылган бер гөнаһ сәбәпле] Казанган нәрсәләре булмыйча, иманлы ирләрне һәм иманлы хатыннарны рәнҗеткән кешеләр өсләренә бик әшәке эш һәм ап-ачык гөнаһ йөклиләр».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:58

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Үз колын (әлбәттә, ул кол чыннан да зина кылмаучы булса гына) зина кылуда гаепләгән кешене Кыямәт көнендә җәзага тартачаклар»[2].

Коръән аятьләрендә дәлил була торып та, Гайшә радыяллаһу ганһәне гаепләгән кеше дә имансыз булыр, чөнки ул Коръәнгә каршы килә.

*Имам Әз-Зәһәбинең «Әл-Кәбаир» китабыннан*

---

1 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан: «Китаб-әл-Иман», 10. Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан: «Китаб әл-Иман», 40.

2 Имам Бохари һәм Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.